ЦЕНТРАЛЬНОЕ ДУХОВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ МУСУЛЬМАН РОССИИ
РОССИЙСКИЙ ИСЛАМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ

# НАУКА И ИСКУССТВО ПРОПОВЕДИ

## Сборник

Печатается по решению
редакционно-издательского совета
Российского исламского университета (г. Уфа)

Автор Т.С. Таджуддинов, составитель Р.А. Раев.

Наука и искусство проповеди. Сборник. Таджуддинов Т. С. – Уфа: Издательский отдел
Российского исламского университета, 2011. – 100 ст р.

Книга составлена на основе авторских вагазов Верховного муфтия России, Шейх уль Ислам Талгат Сафа Таджутдина и представляет собой практический курс пятничных проповедей для студентов высших учебных заведений и широкого круга читателей. Книга составлена в порядке содержащем минимум знаний, которыми должен обладать каждый мусульманин по вероубеждению и канонам поклонения.

© Издательский отдел Российского исламского университета ЦДУМ России, 2011

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГАТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп. Һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау ологлауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәләмнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреpгә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһдан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә, тиңдәше юкка гуаһлык бирәм җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле гәмәлләребез белән гөмеребез буена яңартып яшәүләребезне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.

**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе икәнлеккә гуаһлык бирәм. җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне Росуль Әкрам с.г.в. сөннәтенә,ияpүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып үтүләребезне мәһшәр майданында да өммәте булып кубарылырга насыйп әйләсен.

**Бергәләшеп иман кәлимәләрен** яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын,белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**

Ерак-якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сайдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назараты һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, Җөмга бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөньядагы сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

## *1- нче вәгаз*

## *Аллаһның исемнәре, Аллаһның зикере.*

Аллаһы Рабулль Гыйззә Көрән Кәримендә:
**Мине зикер итегез!. Мин дә сезне зикер итермен. Миңа шөкерана кылыгыз көфран нигъмәттә була күрмәгез**. Аллаһ Рабулль Гыйззә әйтә:"Мине искә алыгыз. Зикер итү дигән сүз, искә алу. Мине искә төшерсәгез, мин дә сезне искә төшерермен! Миңа шөкерана кылыгыз, биргән нигъмәтләремә. Онытa күрмәгез, кеферлектә була күрмәгез,"- ди. Аллаһ Рабуль Гыйззә.
Аллаһның зикере олы бер эш. Хәтта намаз укыган вакытларыбызда да. Аллаһ Рабулль Гыйззә нәрсәгә укыганлыкны аңлата. Аңлатып утырмасада да булыр иде. Гәрәпчә....Намазны укыгыз, Мине истә тотыр өчен - Мине искә алыр өчен ди, Аллаһ Рабулль Гыйззә. Дөнья мәшәкатләре арасыда чабышып эштә дә, базарда да ризык табырга, чапкан вакытта да бөтен мәшәкатләре арасында үзен дә кем икәнлегeн онытy мөмкин. Шуның өчен Әдәм баласына Аллаһ Рабулль Гыйззә биш вакыт намазын куйды һәм ул намазны да **үтәгез, торгызыгыз намазны, Мине истә тотыр өчен мине зикер** итер өчен дип әйткән иде Аллаһ зикерне үзе өйрәтә.
Карыйбыз Г.С.К. Күл гәрәбчә..... Пәйгәмбәр с.г.в. безгә дә өйрәтә. **Әйт, йә Мөхәммәд с.г.в.: хуҗалыкның, бөтен байлыкның да, байлык кына түгел Мөлк дигән суз хуҗалыкта, мөлкәттә бөтен барлыкка өстен булу, шуларның бөтенесенә хуҗа булган Раббым Аллаһ. Син байлыкны да, мөлкәтне дә теләгәненә бирәсең. Вәтәнзигу - телегән бәндәдән аласың, берәүне баетасың, берәүне фәкыйрь итәсең. Теләгән бәндәңне кадерле кыласың кеше арасында да, бәндә алдында да, теләгән бәндәне хур итәсең, аунап ята торган итәсең койма төпләре астында, кеше алдында сүзләре дә үтмәс иттереп кадерсез кыласың. Синең кодрәт кулыңда,бөтен изгелек, бөтен хәер, дөреслектә Син хәр нигә көчең, көдрәтең житүче.Төнне көнгә кертәсең, ялгап җибәрәсең, көнне дә төнгә ялгап җибәрәсең бер берсенә. Терене үлектән дә чыгарасың, үлекне дә тередән чыгарасың. Теләгән бәндәгә ризикны да исәпсез иттереп бирәсең, чамаламыйча бирәсең дип.** Әле Гыймран сүрәсендә өйрәтә. Бу дога, нәрсә сорады монда Аллаһтан, нәрсә сорарга өйрәтә? Син хужада, теләгән бәндәгә малны бирәсең, теләгәнеңнән аласың, теләгәнеңне кадерле итәсең, теләгәнеңне хур итәсең. Төнне көнгә дә ялгыйсың Үзең. Һәр нигә дә көчең-куәтең житүче, мәетне тередән дә чыгаручы дигән вакытта Нәрсә сорады бу кеше?. Нәрсә сорарга Аллаһ Рабуль Гыйззә куша бу догада иманның тулысы бар. Мал сорамый бу кеше, мал сорарга дип өйрәтми. Малны сорарсың, бирердә шуның астында күмелеп тә калырсың. Ул мал астында кая куерга белмичә исрафларга куеп, харам юлларга куеп, аннары кыямәт көнендә соравы гына булыр Аллаһ Рабуль Гыйззә ахырында әйтеп куярга куша. Хәер үзеңнең кулыңда, шуның өчен дә Пәйгәмбәр с.г.в.әйтә:
قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: **نِعْمَ الْمَالُ الصَّالِحُ لِعَبْدِ الصَّالِحِ .**

**Никадәр хуш мал ул. Хәләл мал булса, изге хәерле мал булса, изге хәерле бәндәсенә.**
Хәләл мал булып та, хәерсез бер кешегә эләкте икән, атасыннан мирас булып калдымы? Монда көтүләп дуслары белән эчеп утырырга, гулять итүләренә, тотты икән Аллаһ каршында үзенә дә, атасына да, гонаһ шомлыгы тия торган була. Булмады икән җавабы юк!

Шуның өчен дә бирү дә, алуында да,түгел кадерле, кадерсез булуында да түгел, дөньяда караган вакытта берәүне күрерсең койма төбендә егылып калган, ләкин Аллаһ каршында ул сиңа караган вакытта мең кат артыгракта булууы мөмкин. Пәйгәмбәр с.г.в. әйтте:

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم **إِنَّمَا الأَعْمَالُ بِالخَوَاتِمِ.**

**Һәр - бер эш, суңы белән булыр.**

Бүген генә, егет булган вакытта гына, күкрәгеңне киереп, борыныңны әллә кайларга чиеп эш бетми. Әле Аллаһның хозурына кайта торганың бар. Намазың белән, уразаң белән мактансаң, я салган мәчетләрең белән, я кылган изгелекләрең белән мактана торган булсаң Аллаһ кабул итәме, юкмы? Анысы да сүз! Кабул итмәде исә, йә алар да хәләл маллардан булды исә, берәүнең алдында мактаныр өчен генә, исемеңне күтәрер өчен генә ул мәчетнең капкасына фәлән-фәләннең мәчете диеп әйттер өчен генә салдырган булсаң ул вакытта киоскы ачканы хәерлерәк булыр иде! Эшләнгән эш Аллаһ ризалыгы өчен булырга тиешле. Шул вакытта ул Аллаһ хозурында кабул була. Шул вакытта Аллаһ Раббуль Гыйззә ул бәндәгә гыйззәтендә насыйп итә.

Шуның өчендә Аллаһ Раббуль Гыйззә үзенә ялварырга, үзен зикр итәргә, үзен искә алырга өйрәтә. Аллаһны зикр иткәннәрне, Аллаһны онытмаганнарны, Аллаһны гел телгә алганнарны Аллаһы Раббуль Гыйззә Көрән Кәримдә дә мактый.

**Шундый бәндәләрем бар! Алар Аллаһны бик күп искә ала! Бер дә телләреннән** ... **салмый,бер дә онытмыйлар. Аллаһны искә алучы хатыннар да бар**. Аллаһның пакъ кәнизәкләре алар да искә ала, тагын да әйтә.

**Аллаһның шундый бәндәләре бар күкләрдә дә, җирләрдә дә җан ияләре бар. Бәндәнең кыяфәтендәме, Йә башка кыяфәтендәме? Күкләрдәме, җирдә дә Аллаһның җан ияләре бар. Аллаһның хозурында булганнар Аллаһка бәндәчелек күрсәтүдән, гыйбәдәттән баш тартмыйлар алар, тәккәберләнмиләр,** кай берәүләр, үзләрен бик изге итеп санап, алар укысыннар, ураза тотсыннар, без инде алардан уздык инде, хазер без намаз укымасак та, гыйбәдәт кылмасак та ярый дип фәтфәләргә хәтлек тә бирүчеләр булдылар тәккәберләнгәндә, без Аллаһны чын таныдык инде. Ул намаз да, ураза да динеңне саклар өчен Аллаһны таныр өчен генә кирәк иде, без тануга җиттек инде. Хазер без укымасак та, була диеп тәккәберләнүчеләр дә булган. **Кылган гыйбәдәтләреннән алар оттырдык дип тә бер кайчан уйламаслар**.

Бер сәхәбә Пәйгәмбәр с.г.в.гә килә дога өйрәт әле ди. Пәйгәмбәр с.г.в. шушы сүзләрне Аллаһны мактый торган, олылый торган исемнәрне әйтә. Шушылай дип Аллаһтан сора ди Аллаһ Раббым, малны да бирүче теләгән бәндәсеннән мәхрүм итүче. Фәлән - фәлән дип әйтте. Безгә әйтте. Бу Аллаһка әйтә торган сүзләрем ди. **Миңа нәрсә булырсың ди?.** Йә, Раббым, гафу әйлә, кичер мине дип Аллаһтан сора ди. Бусы сиңа ди, тегесе белән Аллаһны мактыйсың, шунысы белән Аллаһтан сорыйсың. Шуның шикеллек Аллаһ Раббуль Гыйззә. Менә бу аят кәримәдә дә Аллаһның хозурында гына гыйбәдәтем дә олыланмаслар, үзләренең гыйбәдәтен олыграк санамаслар, кылган гамәл гыйбәдәтләреннән оттырдык, вакытыбыз әрәмгә генә китте, юкка гына очорып йөрдек дип алар хурланмаслар. **Алар төннәрендә дә, көннәрендә дә Аллаһка тәсбихларын әйтерләр. Ул гыйбәдәтләреннән алар бер вакытта да туймаслар.** Тагында Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтте

**Йә Хәбибем Мухаммад с.г.в. синнән элек, күпме генә илче җибәргән булсак та, һәр кайсысына без ваһи кылдык, аның куңеленә салдык, җиткердек. Миннән башка бүтән тәңре юк дип җиткер бәндәләремә!** Шуны белделәр исә, ул вакытта бәндәләремне бер минутка да, бер секундка да ташламыйм! Аллаһ бер дип таныдылар исә, бер генә булган, ялгыз гына булган Аллаһка тулы иманнары белән ялварып юнәлделәр исә, ул бәндәләремне Мин хур итмәм. **Мине бер дип таныганнан соң**

**бәндәчелек күрсәтсеннәр.** Бәндәчелек күрсәтү, колым, дип үзләрен танып миңа коллык күрсәтсеннәр ди. Берәүгә кол була торган булсак нишлисең? Раствор изәсең, кирпеч ташыйсың, җир изәсең, аның хезмәтен кыласың, Аллаһка кирәкмени бу? Аллаһка коллык, Үзе кушканча бәндәчелек курсәтү, 24 сәгать буена ашап, эчеп, йоклап, үрчеп йөргән вакытыбызда биш тапкыр өзелеп, дөнья мәшәкәтеннән, Аллаһу Әкбәр дип кулларыбызны күтәрәбез дә: Йә, Раббым, балта да юк, көрәк тә юк, чүкеч тә юк, кашык та юк. Гыйбәдәткә тотынам мин Аллаһу Әкбәр, Син бөек йә Раббым! Бөтен дөньясыннан, бөтен мәшәкәтләреннән, барсыннан өстенсең, йә, Раббым Аллаһ дип килеп басасың намазга Аллаһны искә төшерә башлыйсың. Шул Аллаһка коллык күрсәтү була, ләкин аның арасында, ике намаз арасында теләсәң ничек иттереп йөрү мөмкинме? 24 сәгать намаз укып та булмый! Бер җомгада әйткән идем Сәхәбәләр Пәйгәмбәребезнең с.г.в.нең җәмәгатләренә килеп аның гамәл, гыйбәдәтләрен сорап әзсенәләр дә "Кая инде безгә Пәйгәмбәргә с.г.в.гә җитәргә, берсе әйтә: Мин төне буе намаз **укыйм,** берсе әйтә: Гөмерем буена ураза тотам, Берсе әйтә: гомерем буена өйләнмим дип."

Пәйгәмбәр с.г.в.аларны шелтәләде: Шуның өчен дә 24 сәгать намазны укып булмай. Менә шуларның арасында да Аллаһның зикере телебез белән дә, эшләгән эшебез белән дә, ашый башладың икән бу ризык ярыймы икән ярамый микән? Хәләл микән, юк микән дип: Әле бая гына бер хәзрәтебез Себердән шалтырата, хәзрәт: бер даруның исемен әйтте: Серебролизм дигән, шул дару безгә ярыймикән? Нәрсәсе бар аның? Дуңгыздан вытяжкасы ясалган, дуңгызның эчендәге нәрсәләреннән ясап шул даруны ясаганнар, ниндидер баш **авыртуыннан. Шуннан** акча тотып, телефоннан шалтырата, иманлы кеше һәр нәрсәне тикшерергә тиешле, шул шалтратуы да, телефонына тоткан акчасы да, сорануы да Аллаһның зикере була, Аллаһ хозурында әҗере дә була торган була, жавабыбызда да.Пәйгәмбәребез с.г.в. аңлата: хәрәмгә дога калмады дип, минем өммәтемә Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтте.

**Ләкин кешеләрнең кайберләре әйтәләр ди Аллаһ Раббуль Гыйззә Әр-Рахман Аллаһ бала да тотты, Аллаһның баласы да бар, беләсез аны. Аллаһның баласы бар дип, әйтүчеләр дә бар. Аллаһ Раббыбыз ул кимчелекләрдән пакъ. Бәлки бөтен бәндәләр Аллаһның хозурында. Кадер-хөрмәтле коллары. Чөнки алар Аллаһны бер сүз белән дә узмаслар, бәлки Аллаһның кушканын үтәрләр.** Аллаһның баласы дип, кай берәүләре Иса г.с.не әйтәләр: Аллаһның илчесен, менә җиргә безгә җибәрде, Аллаһы Тәгәлә үзенең баласын безне хак юлга күндерергә дип, шулай әйтүчеләр дә бар. Кай берәүләр саташа-саташа фирештәләрне Аллаһның балалары ди, Аллаһы Раббүль Гыйззә әйтә:" **Алар балалары түгел, Аллаһның коллары, кадерле хөрмәтле коллары фәрештәләр. Алар Аллаһның кушканын гына үти.Үзләренең теләкләре юк! Нәрсә булса да эшләргә, Аллаһ нине кушты шуны гәмәлгә куючылар.. Аллаһ Раббыгыз аларның алларындагы булганнарында, вә артларында булганнарында , бөтенесен белә." Фәрештәләрнең элек үткәннәре дә, алларында булачакларын да, барысын Аллаһ Раббым белер, һәм алар бер кемгә дә шәфәгать кыла алмаслар. Бер кемгә файда да итә алмаслар, зыян да итә алмаслар. Йортта да тик Аллаһ риза булган бәндәләргә генә файда итә алырлар.** Алай булган вакытта Аллаһ Раббуль Гыйззә: менә ике иңебездәге фиреештәләрне дә, изгелекләребезне дә, кимчелек-хаталарабазны да язарга Аллаһы Раббуль Гыйззә билгеләде. Башка да меңләгән-меңләгән миллионнаганнары да әдәм баласына, Аллаһның әмере белән игелекне дә итүе мөмкин. **Ул Аллаһның бәндәләре, кешеләр булсын, яки фәрештәләр булсын, алар Аллаһтан куркып, Мушфиклар калтырана-калтырана Аллаһның кушканын үтәрләр**. **Әмма кем алардан, йә фәрештәләрдән, йә кешеләрдән мин үзем Тәңре, үзем хужа мин дип әйтә торган булса. Без аңарга кайтачак урынны-жәһәннәмне**

**кылырбыз, бүләккә наградасына иттереп җәһәннәм бирербез. Үз бәхетеннән качканнарга шушылай иттереп без җәзаны бирәбез ди Аллаһ Раббуль Гыйззә.** Фирештәләрдән булдымы? Иблис кем иде? Фәрештәләргә дәрес бирә иде. Үзен тәңре дәрәҗәсенә җиткермәсә дә, Аллаһы белән карыша башлады, тарткалаша башлады, бәхәсләшә башлады, шуның белән Аллаһның рәхмәтеннән сөрелде, кешеләрдән дә, кем Тәңре дәрәҗәсенә үзен куерга маташа икән, фиргауынмы булсын, гитлерларымы булсын, **Сталиннармы булсын,** башкалары мы булсын, алар гына түгел, бәндәләрнең гадиләре арасында да, Аллаһны узып, берәр нәрсә эшлим дип уйлый икән, һич–шиксез Аллаһтан җәза киләчәк, һич-шиксез!!! Шуның өчен, без бер эшебездә моны булдырам, моны эшлим, тегеләй иттерәм, болай иттерәм дип такылдарга тиешле түгел.
**Пәйгәмбәр с.г.в.:** Әгәр-әгәр дип тә әйтмәгез, ләү дип әйтмәгез, менә эт эрмәгән булса уянмый идем, менә шул бандитны тота алмый идем ә.., өемне чистартып чыгарырлар иде ә.. шунда тегенәргә барып та берәр кучтәнәч бирмәгән булсам, балам институтка кермидер иде. Әгәр әгәрләрне күп әйтә торган булды икән Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә: “Әгәрегез күңелегездә шайтанга урын ача ди, сез әгәр диеп әйткән саен шайтаныгыз күперә, зурая-зурая аннары эчегезгә кереп утыра ди. Пәйгәмбәр с.г.в. бер тапкыр гына, Инша Аллаһ , Аллаһ бирсә димәде беләсез, **яһудләр** килеп Пәйгәмбәр с.г.в.нән рух хакында, тагын бер ничә мәсьәләне сораган чагында Пәйгәмбәр с.г.в. : Ярар әйтермен диде. Кырык көн буена Джабраил г.с. килмәде. Пәйгәмбәр с.г.в. бер сүзен дә әйтә алмады, шунда **яһутләре** дә Мәккә Мәшрикләре дә көлә башладылар: Әй, шайтаның ташладымы? Бер сүз әйтә алмыйсызмы? Кырык көннән соң гына Аллаһ Тәгәлә Джәбраил г.с.не җибәрде дә.
**Бер эшкә дә, мин моны эшләрмен дип әйтә күрмә, иртәгә булыр, берсе көнгә булыр дип, әйтә күрмә**. **Аллаһ теләсә дип әйт.** Һәр эшеңдә, үзең булдыра ала торган хәлеңнән килә торган эш булса да Аллаһка тапшыр, булдыра алмаганны бигрәк тә. Аллаһы Раббуль Гыйззә үзенең зикерендә бер минут, секундына Аллаһны онытмаучы бәндәләренең дә һәм фәрештәләрнең дә бар икәнлеген бу аят Көрән Кәримдә исбат итә. Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: **اُذْكُرُوا الله حَتَّى يَقُوُلُ مَجْنُونٌ.**

**Сез Аллаһны шул кадәр искә төшерегез, шул кадәр телегездә әйтегез, бүтәннәр сезгә тилергән инде бу дип әйтерлек булса да ярый ди.** Курыкмагыз анардан, һәр вакытында Бисмилләһир-рахмәнир-рахим дип башла да, ризыгыңа догаңны кылда, әле кайчан гына юлда, йә берәркайда булса кафедамы, чәй эчтеңме, кофе эчтеңме, шунда хурланып утыралар иде, әз түгел иде. Өендә намазын да укый, уразасын да тота, кеше арасында кулын күтәрергә хурлана торган. Алай булырга тиешле түгел, Аллаһны искә алу, Аллаһның зикере хурлык түгел, бәндәнең кадерен, дәрәҗәсен күтәрә башкаларга үрнәк була торган була. Шуның өчен дә Пәйгәмбәр с.г.в. : “Башка берәүләр тилергән дип әйтерлек булса да Аллаһның зикерен телегездән салмагыз ди”. Абу Һурайра Бу хадис шәриф риваят ителә, ул әйтә:

عن ابي هريرة رضي الله قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم:**إِنَّ لِلّٰهِ تَعَالى تِسْعَةً وَتِسْعِينَ اسْمًا مِائَةً إِلَّا وَاحِدَةً، مَنْ أَحْصَاهَا دَخَلَ الْجَنَّةَ.**

**Дөреслектә Аллаһы Тәгәләнең 99 исеме бар, 100 ул 1 башка ди. Кем аларны санаса җәннәткә керер ди.** Пәйгәмбәр с.г.в. Аллаһның шул исемнәре бәрәкәтендә, аннан башкалары да бар кеше белмәгәннәр. Берәүләрнең күңеленә салган, йә бөтенләй бер кем дә, белә алмаган, кем аларны санады исә, ул бәндә җәннәткә керер. Шул исемнәр бәрәкәтендә җир - күкләр тора, Аллаһның исеме генә түгел, менә бит заводта да, директор да бар, баш инжинер да бар сакчысы да бар, пожарнигы да бар- бөтенесе бар, һәр кайсысына үзенең вазыйфасы бар. Ләкин җир, күкләрне тоту Аллаһның менә шушы ямле, матур исемнәре хакында бөтен галәмнәр тора. Бер минутка да, бу

дөньяның, барлыгы яшәүе туктамый. Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә: алар 99, кем аларны санаса җәннәткә керер.
Ул Аллаһ, аннан башка Тәңре юк! الرَّحْمَنُ , الرَّحِيمُ , المَلِكُ , القُدُّوسُ , السَلاَمُ , المُؤْمِنُ , المُهَيْمِنُ , العَزِيزُ , Ул Аллаһ, Аннан башка Тәңре юк! Мәрхәмәт шәфкәтле, дөньяда һәр кемгә ахирәттә иман белән кайтканнарга хуҗа да, изге дә, тынычлык, иминлек тә Аңардан, иманы да , һәр нигә хуҗа булучы да, кадерле дә, кодрәтле дә. الجَبَّارُ , المُتَكَبِّرُ , الخَالِقُ , البَارِئُ , المُصَوِّرُ Ул Аллаһ ялгызлыкны кирәк булса көч белән дә туктатучы. Тәккәбер дә Ул, тәккәберлек шуның өчен Аллаһка гына килешә. Юктан бар итүче дә, төзүче дә, төс кыяффәтен бирүче дә, الغَفَّار гонаһларны ярлыкаучы да, القَهَّارُ кирәк булды исә Каһары белән, көче белән дә Аллаһы Раббуль Гыйзза, бәндәне явызлыктан туктатучы да, الوَهَّابُ сорамыйча бирүче дә, الرَّزَّاقُ бәндәсенә дә, җир астындагы кортына да, күктәге кошына да, микробына да ризыгын бирүче. الفَتَّاحُ эшләрне уң итүче. العَلِيمُ бәндәләрнең эш тошларын белүче, القَابِضُ кирәк вакытында тотып алучы, البَاسِطُ җәеп тә бирүче, الخَافِضُ түбәнәйтүче дә, الرَّافِعُ күтәрүче дә. المُعِزُّ Бәндәнең кадер хөрмәтен дә күтәрүче, المُذِلُّ хур да итүче السَمِيعُ ишетүче дә, البَصِيرُ күрүче дә, الحَكَمُ хөкем итүче дә, العَدْلُ гаделлек белән, اللَطِيفُ الخَبِيرُ мәрхәмәт-шәфкәтлек белән шатлык белән эш итүче. Бәндәләрнең эч тышларын белүче. الحَلِيمُ йомшак ул Аллаһ! Бәндәләрнең күңеле каты булып кай вакытта үз баласына да бәд-дога кылырга батырлыгы җиткән вакытында да, Аллаһны Раббул-Гыйззә иң түбәнлеккә төшкән колын да кызганучы, العَظِيمُ олы ул Аллаһ Раббыгыз. الغَفُورُ бик тә гонаһларны ярлыкаучы. الشَكُورُ бәндәнең тамчы гына кылган изгелекләрендә дә, шөкерана белән кабул итүче, العَلِيُّ олы ул Аллаһ, الكَبِيرُ өстен ул Аллаһ, الحَفِيظُ саклаучы ул Аллаһ, المُقِيتُ бәндгә исәпләмәгән төшләрдән ризыкларын бирүче, الحَسِيبُ һәр кайсысының хисабын да алучы. المُجِيبُ الرَّقِيبُ الكَرِيمُ الجَلِيلُ олы булган, юмарт булган, һәр нәрсәне күзәтеп торучы. Тилмереп кулларын күтәргәннәрнең догаларын кабул итүче الوَدُودُ الحَكِيمُ الوَاسِعُ рәхмәтендә иркен булган. Хикмәт иясе булган, сөюче المَجِيدُ мактаулы البَاعِثُ юктан бар итүче. Үлгәннән соң да тергезүче الشَهِيدُ бәндәләрнең дә бөтен мәхлүкләрнең кылганнарына гуаһ булган. القَوِيُّ الوَكِيلُ الحَقُّ хак булган вәкил булган, кеше кодрәте өстен булган. المَتِينُ Нык булган الوَلِيُّ бәндәләренә якын дуст булган, الحَمِيدُ мактаулы, المُحْصِي һәрбер кылганнары исәпләүче, المُبْدِئُ башлаучы да. المُعِيدُ кайтаручы да, бөтенләй юк идек бар итте المُعِيدُ бөтенләй юк булганнан соң да, җирдә туфрак булганнан соң да яңадан кайтучы. المُحْيِي тергезүче, المُمِيتُ үтерүче الحَيُّ القَيُّومُ мәңге тере булган, мәңге каим булган, الوَاجِدُ бар итүче дә, المَاجِدُ мактаучы да, الوَاحِدُ бер генә булучы да. الأَحَدُ Ялгыз булучы да, الصَمَدُ бер кемгә мохтаҗлыгы да төшмәүче дә, القَادِرُ المُقْتَدِرُ көдрәте җитүче дә, المُقَدِّمُ алдынна китерүче дә. المُؤَخِّرُ Соңыдан кылучы да, الأَوَّلُ әүүәлдә, الآخِرُ соңыдан булган, الظَّاهِرُ күзгә күренгәндә, البَاطِنُ яшрен булганда الوَالِي берәүләрнең эшләрен күзәтеп, аңарга хуҗа булучы да, المُتَعَالِي югары булган, Аллаһ البَرُّ Мәрхәмәт шәфкатле Аллаһ التَّوَابُ бәндәләрнең тәүбәләрен бик тә кабул итүче المُنْتَقِمِ العَفُو түләгәннәреннән үчен дә алучы, ярлыкаучы да, الرَؤُوفُ мәрхәмәт шәфкәтле дә, المُلْكِ хуҗалыкның хуҗасы да, ذُو الْجَلاَلِ وَ الإِكْرَامِ олылыкның да, хөрмәтнең дә иясе булган, المُقْسِطُ биргән чагында да чамалап тигез иттереп бирүче, الجَامِعُ дөньяда да әхирәттәдә дә җыючы. الغَنِيُّ бай булган, المُغْنِي байлыкны да бирүче, المَانِعُ тыючы да, الضَارُّ зыян да итүче, النَافِعُ файдасын да биреүче, النُورُ нур булган, яктылык булган. الهَادِي хидәяткә дә күндерүче, البَدِيعُ булдырганын да искиткеч иттереп булдыручы, сокландырырлык иттереп булдыручы, Ул Аллаһ. البَاقِي мәңге бар, الوَارِثُ бөтен дөнья беткәннән соң да барысына Варис булучы. الرَشِيدُ хак юлга күндерүче дә الصَبُورُ бөтен дөньяның кылган азгынлыкларына да бик түзүче Ул Аллаһ ди .Пәйгәмбәр с.г.в. бу хадис шәрифне имам Тирмизи белән имам Байхаки хәзратләре риваят итә: Менә бу 99 исем...
عن بريدة رضي الله عنه قال: أَنَّ رَسُولَ اللهِ صلى الله عليه وسلم سَمِعَ رَجُلاً يَقُولُ: اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ بِأَنَّكَ أَنْتَ اللهُ لا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ الأَحَدُ الصَّمَدُ الَّذِي لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ، فَقَالَ: دَعَا اللهَ بِاسْمِهِ الأَعْظَمِ الَّذِي إِذَا سُئِلَ بِهِ أَعْطَى وَدُعِيَ بِهِ

**أَجَابَ.**

**Бурайра р.г. риваят ителәә, ул әйтте: Пәйгәмбәр с.г.в. бер кешенең, бер ирнең дога кылганын ишетте ди. Ул ир әйтә: Йә Раббым Аллаһ сорыйм мин синнән, чөнки син үзең Аллаһ , Синнән башка Тәңре юк, бер генә син, беркемгә мохтаҗлыгың да юк тумадың да, тудырмадың да, Сиңа беркем дә тиң дә булмады, синнән сорыйм бит. Бер кеше дога кылып тора. Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә: Бу Аллаһның шундый исемнәре белән сорады, Аллаһның Иң олы исеме белән сорады, аның белән сораган вакытында Аллаһы Раббуль Гыйззә бермичә калмас, моның догасын кабул итмичә калмас ди**.

Дөньяда да шулай бит, берәр нәрсә кирәк була торган булса , квартирмы, нәрсәме директорга бардың исә Ий, кайчаннан бирле мин монда эшлим 10-15 ел булды, әле дә фатир бирмисең. Нәрсә генә ишетәсең ә? Киләсең дә юмалыйсың. Каян Аллаһ кушты безгә синең шикелле директорны бу заводка, кара ничек иттереп эшләрдә җайга салынып китте, зарплаталарыбыз да артты , продукция да артты, Аллаһ кушты безгә бөтен кеше мактый сине фәлән итеп, тегеләй итеп, изгелекләрен искә төшерде дә, вакытлыча булсада общежитиясын бирә, буш чыгармый. Аллаһ Раббуль Гыйззә үзенә ничек иттереп ялваруны өйрәтә. Фатиха сүрәсе шуның белән башланган : Әлхәм Көрән Кәримдә иң беренче битендә Әлхәмд. **Раббым галәм** дип Аллаһ Раббуль Гыйззәгә мактау белән башланган.

عن اسمى بنت يزيد رضي الله عنها أَنَّ النَّبِيَّ صلى الله عليه وسلم قال:**اسْمُ اللهِ الْأَعْظَمِ فِي هَاتَيْنِ الْآيَتَيْنِ**

**Дөреслектә Пәйгәмбәр с.г.в. әйтте ди: Аллаһның олы исеме менә шушы ике аятта бар. Аллаһның олы исемнәре 99 ның арасында иң олыларның берсе: Сезнең Әр-Рахманир-Рахим Тәңресе Раббыгыз бер булган, ялгыз булган Аллаһ Раббыгыз , аннан башка тәңре юк, Ул Әр-Рахмән Әр-Рахим.** Шуның өчен Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әр-Рахмән дөняда һәр кемгә тигез иттереп яудыручы , хозурына кайткан вакытта иман белән кайтаручыларга, **тагын да Әл-Гыймран сүрәсенең башындагы Әлифләммим. Аннан башка Тәңре юк, мәңге гел тере Ул, гел бар Ул дигән Аллаһның Әл-Һәй Әл-Кайюм.** Шуның өчен дә галимнәр дә әйтәләр: Бик авыр, бик читен вакытта, дошманыңның каршысына килгәндә, олыларның алдына килгән вакытта. Йә Хайю – йә Кайюм дип сорасаң, беркем дә сиңа каршы тора алмас ди.

**ГОМУМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГАТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГАТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияргә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Бергәләшеп иман кәлимәләрен** яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**

Ерак-якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сайдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-
мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!
Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

**السلام عليكم و رحمة الله و بركاته**

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

## 2-нче вагаз

## Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)

Пәйгәмбәр с.г.в. Аллаһның 99 исеме бар. Әсмаул – лаһи вә хүмә Аллаһтан берәр һәҗәтегез йомышыгыз булса, Аллаһтан сорасагыз шулар белән Аллаһыдан сорагыз, шул исемнәре хакында да АРАБ догагызны кабул итер дигән иде. Исми Әгзәм дип тә атыйбыз без аны.Олы бер серләр булганга күрә һәр кайсысына бәйнә-бәйнә берәмтекләп карап чыгарырбыз. АРАБ Аллаһның үз исеме. Дөнья яратылышыннан бирле күпме потлар уйлап чыгармасаларда, нәрсәгә генә табынмаган булсалар да, аларның берсенә дә Аллаһ исеме бирелгәне юк, һәм бирә дә алмаслар Иншаа Аллаһ. Ләкин Аллаһ дигәннән элек Аллаһнын тагын бер исеме бар иде **“hу”.**

**“Һу”** дигән исеме гәрәпчәсендә **“ул”** дигән сүз, нибары ике хәрефтән генә тора **“h”** хәрефе кендектән чыга икенчесе”АРАБ” **“h”-**ның саны – 5, **“у”**нык**ы** - 6 – җыенысы 11 була. Бу нинди гәтәмәте  Атабыз Әдәм г.с.-не яратканнан соң нәрсәдән ятратты беләсезме каян ? Балчыктан. Балчык нәрсә? Чүлмәк! Көръән Кәрим Чүлмәк балчыгыннан яраттым дип әйтә кыздырылган, чиртсәң чыелдап тора торган чүлмәк балчыгыннан яраттым ди.

Чүлмәк ничек йөрий ала? Ничек ашый ала? Ничек Аллаһны искә ала? Ясап кара, күпме ясыйлар кибетләрдә дә бар чүлмәктән дә бар плассмастан да бар, башкассыннан да ясалганнары да, ләкин берсесе дә кеше дәрәҗәсенә җитә алмады. Кеше дәрәҗәсенә җитте, инсан дәрәҗәсенә атабыз Әдәм г.с. һәм аның нәселе. Кеше кем ул? Инсан дәрәҗесенә  Әдәм баласын яратты бөтен җир күкләрне, бөтен барлыкны **ярату** шул бәндә өчен. Күпме айлар, кояшлар , йолдызлар, күпме планеталар, күпме хайваннар, күпме үсемлекләр, гөлләр була торган булса, бөтенесеннән артыгы олуг һәм куркәм сыйфатта булган Аллаһнын мәхлүкләре арасындагы, кеше Әдәм баласы ышанса да, ышанмаса да. Гыйбәдәт кылса да, аунап ятса да канавада барыбер Аллаһның иң олы яратканы олуг мәхлүкләренең берсе булып саналган Әдәм баласы.

Шул, иң өстен дәрәҗәсенә җитүе нәрсә аркасында булды, Аллаһ  җан бирде дә, аны шул балчык кешегә әйләнеп **“hу”**дип әйтә башлады, сулый башлады. Һава сулый башлады, һаваны ала башлады, эшли башлады мотор. Әле бер көнне хайваннар дөньясы турында да, күрсәттеләр жирафларны. Жирафны ничек итеп тапканнарын, аяк - үрә, жирафны күз алдына китерәсезме ничә метр биеклеген.Әгәр дә жираф ятып бәбиләсә ул вакытта яши алмый икән, шул аяк үрә торган вакытында егылып төшә дә җиргә **“шак”** итеп бәрелә дә шуннан сулый башлый, Аллаһнын яратуы. Шул һава чыга торган вакытта мотор эшли башлаган вакытындә нәфәс алган вакытындә иң беренчесе дә **“hу”** чыга.

Шул вакытында, атабыз Әдәм г.с.нең җаны, гәүдәседә, шул балчыкка кереп кешегә әверелгән вакытында нәфәсе чыккан вакытында, һавасы чыккан вакытында **Әлхәмдүлилләһ** дип куя, беренче һаваны эшләтә башлагач, сулый башладымы беренче әйткән сүзе дә атабыз Әдәм г.с.нең **Әлһәмдүлилләһ.** Аллаһка мактауларым булсын Аллаһ Раббул гыйззә әйтте: وَلِذَلِكَ خَلَقْتُ **- Шуның өчен мин сине яраттым** диде. Бөтен барлыгыбыз бу дөньяда Аллаһка шөкерана кылыр өчен, **Әлһәмдүлилләһ** дип, куана куана яшәр өчен. Шуның өчен дә нормалный кешегә сау – сәләмәт кешегә, исерек булмаган, саташмаган, адашмаган кешегә, ул дигән вакытта.**”Ул”** дип әйтелсә **“hу”** дип әйтелсә, кем ул дип сорап та утырмый ул дигәчтән кем икәнлеген белә Аллаһ икәнлеген.

Бу  алмашлык (местоимение) син дип әйткәндә каршындагы кешегә әйтәсең, ул дигәч

юк ул монда шикелле, ләкин иң барларның бары **Ул**, син бар булсаң да, бу кәндә булуы мөмкин, ләкин Аллаһның барлыгын күрмәсәң дә, ул дип әйткән вакытында да Аллаһ Раббул Гыйззә бөтен тирәндә. **Ул** дигән вакытында иманлы кеше иң беренче иттереп зиһененә, күңеленә килгәне Аллаһны**,** күңеленә китерә.Шуның өчен **"һүә"** Аллаһның исеме. Хәттә бу хәрефләрнең төзелеше дә ике хәрефтән булып Аллаһның бу исеме **"Һүә" "h"**сы – 5, **"уау"** - 6 булса – 11 була . Тәхәрәт алган вакытыбызда да, эшли торган эшләребез 11. Аннан соң Аллаһның, кем икәнлеген, кем соң ул Аллаһ? дигән вакытта Көрьән Кәрим ачыктан аңлата:

**Әйт йә Хәбибем Мөхаммәд с.г.в. Аллаһ бер! Ничә дип сораса,** Нинди дип сораса, Аллаһ Раббуль Гыйззә Пәйгәмбәребез с.г.в.гә иң беренче сүзе белән аңлатты **Кульһу Аллаһу** –дигән сүз Аллаһны таныту сүзе, бу сүздә дә шушы җөмләдә 11 хәреф: Каф, ләм, һә, уау, әлиф, ике ләм,һә,әлиф,ха,дәл, 11 хәреф була. Бу Аллаһны таныту хәрефләре. Шул саннан 11 дән тәхәрәт алуларыбызның кушкыннары да, Азан әйткән вакытыбызда да Аллаһнын исеме 11 тапкыр әйтелә. Аннан соң да, сәфәргә чыккан вакытыбызда да фарызларны гына укыйбыз бит, сәфәрдә булган фарз намазларыбызның 5 вакыт намаздагa саны да 11. Шуның өстенә Әдәм баласында гәүдәсендә 11 тишек бар 7се башта: ике күзең, ике борын тишегең, авызң, ике колагың, аннары түбәнрәк булган ике теше тугыз булды, ир кешедә туган вакытыда икесе була, баш түбәсендәге кендегендәге алар аннары капланды. Хатын кызда гел бар. Баласын имезә торган урыннарыннан да икесе булды. Анысы да ун бер булды. Аллаһ Раббуль Гыйззә Үзен танытыр өчен **Хәбибе Мөхаммәд с.г.в гә әйт: Йә Хәбибем Мөхаммәд с.г.в. Ул Аллаһ Раббым бер!** Аллаһ нинди дип сорый әдәм баласы? Анарга да Аллаһ Рабуль Гыйззә явабын әйтә.

**Аллаһ Раббыгыз җир, күкләрнең нуры Ул.** Нурны нәрсә дип таныйбыз без? Яктылык, **светоч,** Аллаһ **светоч миров, небес и земли.** Аллаһ Раббуль Гыйззә җир күкнең нуры. Аллаһ Раббуль Гыйззә булмаса иде бу барлык та булмас иде, була торган булса да, бар икәнлеген беркем дә күрмәс иде. Ничек иттереп кояш чыккан вакытыда, яктылыгында күрәбез, ә? Бар икән дип, ә булмаса яктылык, кояш, йә айның яктылыгы булмый торган булса **төнлә** барасың маңгаең белән шак баганага да, әй бар икән дип таныйсың.

Аллаһ Раббуль Гыйззә Аллаһның Ул Аллаһ Раббыгыз җир күкләрнең нуры

**Ул Аллаһ Раббыгыз җир күкләрнең нуры Аллаһның нуры. Нур нинди? Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә: Аллаһның нурының мисалы: нуры андый дими Аллһның нурының мисалы , примеры үрнәге: бер яккан ут шикеллек, анда лампасы да бар. Ул лампасы да пыяла эчендә, ул пыяласы да, әйтерсең лә күктәге өнҗе балкып торган йолдызы шикеллек, мөбәрәк булган бер агачтан аның мае да зәйтүннән, көнчыгышныкы дә түгел, көнбаешныкы да түгел, аның маеннан булган яктылыгы яктырта, анарга ут тимәсә дә. Утсыз да, әле лампа беләбез шәм белән, чыра белән май салып, йә киросин салып, ләкин Аллаһның нуры яктылыгы анарга ут тимәсә дә яктырта. Нур өстенә нур Ул**, Аллаһ **үзенең нурына теләгән бәндәләрен күндерә, аны күрәләр алар, Аллаһ Раббым бәндәләргә шулай иттереп мисалларны китерә, һәр нәрсәнең серен белүче Аллаһ Раббым ди**.

Бик катлаулы аят кәримә, аңлауга да бик олы аят кәримә, гасырлар буена гәлимнәр купме тәфсирләр язган булса да, әле моның нәрсә икәнлеген моның белән Аллаһ Раббуль Гыйззә нине китергәнлекне кешелек дөньясы аңлап бетергәне дә юк. Аллаһ Раббуль Гыйззә болай аңлата

Аллаһның нурын! Нинди? Нәрсә, икәнлеген беләсегез килсә, мактау олылаулар булсын Аллаһка Ул шундый зат, күкләрне яратты, җирне яратты. Моннан күренә, күкләр алдан яратылган. Аннары гына җир йөзе яратылган һәм караңгылыкны яратты,

караңгылыкларны темнота, һәм нурны яратты, Аллаһы Тәгалә. Шул караңгылык арасыннан ачыклар өчен. Кояшы белән, айы белән, йолдызлары белән. Айның үзендә яктылыгы юк. Кояштан алган яктылыкны гына кире бәрә көзге шикеллек иттереп, ләкин кояштагы яктылыгы каян килеп тора?

Аллаһ Раббыгыз җир күкләрне яратты, караңгылыкны, яктылыкны – нурны да яратты **Аллаһ Раббыларын инкарь итүчеләр шуда да хаклыктан тайпылалар ди**. Җир күкләре бар, исәпсез йолдызлары бар, ай – кояшлары бар, шуларны да исәпләми үзеннән-үзе булган дип тә әйтергә дә төшми ышанмаган була. Аллаһ Раббысының барлыгына, көфергә саташып төшә.

Аллаһ Раббул гыйззә шундый Зат – **Ул сезне лач булган балчыктан яратты** ди. Үзегез кем ? Аллаһ кем дип сорайсыз? Сез кем? Ул Аллаһ Раббыгыз сезне балчыктан яратты. Балчык нәрсә ул? Авылда яшәгән кеше онытмагандыр әле. Бер яктан икенче якка гына үтеп бара яңгыр вакытында лач булып, аннары читкә таяклар белән сүри-сүри,кырып бөтен яклардан, кырып кереп кара шулай балчыклар ябышкан килеш өйеңә, нишләтер абыстаең? Кисәү белән өстенә килмәсә. Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә: Үзегез кем? Раббыгыз Аллаһны кем дип сорарга **Аннан соң Аллаһ Раббыгыз Әдәм баласына һәм бөтен барлыкка, әҗәлен вакытын чамасын куйды**. **Билгеле вакытыгыз, китә торган вакытыгыз да җитә, Аллаһ үзе генә аны белә Сез аннан соң да тарткалашасыз,** исәпләшәсез, бар микән, юкмикән? Булса да нинди икән дип

**Ул Аллаһ Раббыгыз, Аллаһ Ул күкләрдә дә, җирдә дә,** күктә дә Аллаһ Ул, җирдә дә Аллаһ Ул, кайда да Аллаһның хөкеме йөри, Аллаһның солтанаты, Аллаһның ологлыгы бар.

Бу Аллаһ күктә утыра, урындыкта да утыра дигән кешеләргә җавап була. Теге вахабистлар бармы? Саташтырырга – адаштырырга! Без әле бер көн Чиләбе өлкәсендә бер авылда булдык Мөслим авылында өч меңгә якын кеше булды Пәйгәмбәр с.г.в.нең Мәүлид шәрифен үткәрәбез, мәүлидләр укылды 30, 40 бала Көръәннән аят кәримәләр укылды, аннары сорыйбыз нәрсә укыдың? Татарча әйтә алмыйлар, бичаралар, урысча сорайбыз Что читал? Коран читал. Что такое Коран? Слово Аллаhа. А где Аллаh? На седьмом небе сидит на троне ди. На троне сидит булгачтын урындыкта. Аллаһы Тәгаләнең җиденче кат күктә утыра диеп Алай булган вакытта яса ракета да оч анда. Шул сабыйларын саташтырып ятучылар кемнәр?

Безгә әби- бабаларыбыз гомердән уңны да түгел, суңны да түгел алдында да түгел, артында да түгел, өстендә дә түгел, астында да түгел. Бөтен төштә Аллаһ күрә, ишетә, белә. Аллаһы Раббул Гыйззә җирдә дә күктә дә дигән сүзе, бөтен төштә дигән сүзе. **Ул Аллаһ Раббыгыз! Белә, сезнең эчегездәге серләрегезне дә,тыштан белгерткәннәрегезне ни кылганнарыгызны да Аллаһ Раббыгыз белеүче.** Кайда икән ул дип, утыру, безгә нәрсәгә? Хат җибәрәсең, киләме, телеграмма җибәрәсең, киләме, йомышың бар икән?

**Без сезгә якынрак Аллаһы Раббуль Гыйззә муен тамырларыгыздан да якынрак** ди.

Алай булгачтан кая ул Аллаһ диеп нигә соранып утырырга? Нигә төпченергә? Анарда, муен тамырыгызданда якынрак мин сезгә дигәнчтен, Ул кеше белән таныштың да визиткаңны бирәсең менә минем телефон шушы, торам шушы җирдә, квартирам шул, ул да сиңа бирә, таныштың, белештең, языштың берләшәсең, кунакка йөрисең. Кирәк булса чакыра Ул Аллаһ, бик ансат җибәрде Газраилне г.с.не – шалт, кайттың **моменталнo.** Күз алдыбызда күпме кайтучылар. Аллаһның кайда икәнлеген урынын сорап утырасы юк.

Аллаһ Раббуль Гыйззә Ул җирдә дә, күктә дә, Аллаһ! эчегезне дә, тышыгызны да белә. Ни кылганыгызны дә белә ди, шунысын бел син! Шушысын онытмасаң Аллаһ гел сиңа

якын. Эченңе дә тышыңны дә белә, ни килганыңны дә белә икәнлеген онытмадың исә, Аллаһ гел синең белән. Тагын да Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә:

أَنَا مَعَ عَبْدِي مَا ذَكَرَنِي

**Мин бәндәм белән бергә! ул Мине искә алган саен**.

Бәндәм Мине онытмады икән, Мин аның янында ди. Аллаһу Раббуль Гыйззә җирдә дә түгел, күктә дә түгел, янында ук Аллаһу Раббуль Гыйззә. Аллаһ дип искә төшерден икән, Раббым дип искә төшерден икән Аллаһкаем, Раббым ташлама инде дип ялвардың икән, Аллаһ Раббуль Гыйззә янында.

Чабасы да юк, йөгерәсе дә юк, Ул янында. Аллаһу Җәллә - Җәләлүһ. Аллаһ Раббыбызның исеме Җәләлүһ 4 хәрефтән тора.

Беренчесе Әлиф, икенчесе ләм, өченсесе ләм, дүртенчесе ха. Иң олы, хәрефләрдән кендектән чыкканы, әлифтән башлана Аллаһң исеме.

**Әлиф** бөтен гарәп хәрефләрнең нигезе. **“Бе”** хәрефенә карасаң, шул ук Әлиф яткырып кына куелган, ике койрыгын күтәреп куелган өскә, астына бер төртке төрткән. Бүтән хәрефләрнең бөтенесенең төзелеше шушы Әлифтән ясала . Әлифнең сан буенча ,саны - **бер.** Әлиф үзе күрсәтеп тора, Аллаһ бер икәнлеген!. Әлиф Аллаһның исемендә иң беренче хәреф. Бөтен гарәп хәрефләренең төзелешенең нигезе шул.

Аннан соң **Ләм** хәрефе килә. Ләмнең сан буенча билгесе 30. Ике тапкыр килде 2-30 булды, 61 булдымы? **Һе** хәрефнең саны шул ук әлиф ул бүтәнрәк итеп тә язылган 5 була. Бөтен 4 хәрефнең саннарын җыйган вактында **66-га** килә. Аллаһу Җәллә - Җәләлүһ АллҺның исеме.

**Көръән Кәримдә,** бөтен сүрәләрдә, Бисмилләһир-рахмәнир-рахим дип язган вакытындагы сүрәләр башындагы Бисмилляларны санаган вакытында **980** тапкыр килгән, бу Аллаһның иң олы исеме, Калган **99** исеме Аллаһның сыйфатлары. Менә Әхмәд бар, батыр ул Әхмәд, көчле ул ӘХМәт, җитез ул әхмәт дип әйтәбезме? Әхмәтнең сыйфатлары була. Аллһта юк болары. Аллаһ дигән сүз Аллаһның үзенең исеме була калганнары Әр-рахмәнү Әр-Раһим, Мәлик, Самад һәм башкалары туксан тугыз исеме Аллаһның сыйфатлары була. Бу **лафзаи җәләлнең Хаваз** китапларында утыз ике төрле һавасы бар. Аллаһ дип, зикер итә торган булсак, тәсбих белән алтмыш алты тапкыр әйтергә тиешле иң кимендә. Алтмыш алты тапкыр иттереп, әйтеп, аннан соң теләгеңне сорасаң, ул теләгең бер кайчан да кире кагылмый. Ис киткеч, олы бер хәтәр, зур бер бәлә төште, тагын да артыгырак сорыйсың килә 660 тапкыр әйт. Аннан соң теләгеңне әйт. Аллаһтан сорадың, ул догаң кабул була. Бер кеше Аллаһның исемен зикер итеп, шуны дәвам итә торган булса, Аллаһ,Аллаһ дип зикер итә торган булса, бу бәндәнең дәрәҗәсе өстен булыр. Бу зикереннән өзелми торган булса, һәр кешенең алдында бу кеше олы күренер, кешеләр алдында кадере дә артыр, һәр кем бу кешене олылый торган булыр һәм бу кешене хөрмәтли торган булыр. Аллаһ исемен зикер иткән кеше шушы дәрәҗәләргә ирешә. Икенче көн туган вакытта, таң аткан вакытта бер кеше Аллаһ дигән исемне бер кадерле әйбергә язып, янында йөретә торган булса, бу кеше янына шайтан бер вакытта да, килә алмас. Таң аткан вакытта, иртәнге намаз алдыннан ,бик каты салкын булган вакытта, өшеп җитер дәрәҗәгә җиткән вакытта да бер кеше шул, язган әйберен, таң аткан вакыттада Аллаһ исемен язган әйбере янында йөреткән кеше Аллаһка дога кылып, Аллаһ дип зикер итә торган буса, бу кешегә ул салкынның салкынлыгы тәэсир итмәс. Суыктан да, салкыннан да Аллаһы Раббуль Гыйззә тәэсир итмәслек булыр диде. **<u>өченчесе</u>** лафзаи җәләлне Аллһ дигән исемне ,берәү ,шушы саннары белән язып янында йөретә торган булса, һич бер нинди эш тә, бер нинди теләгенә ирешү дә бу кешегә авыр килмәс. Исеме Абдулла йә Мухаммад булган кешеләр һич чиксез Аллаһның исемен бер кайчан да теләреннән салырга тиешле түгел ди. **<u>Дүртенчесе</u>** бер кеше өч көн, йә биш көн, йә җиде көн ураза тотып, ул ураза тоткан

чагында да  ит әйберләре сөт ме булсын, күкәй ме булсын, сырлар мы булсын, хәйван ризыкларын берсен дә ашамыйча, тик яшелчә генә җиләк-җимеш кенә ашап, бигрәк суган- сарымсактан да сакланып уразасын тота торган булса йә өч көн, йә биш көн. Яшәрлек кадәрле генә иттерелеп ашап шушы җиләк-җимешләреннән ризыкларыннан, соңыннан җиденче көненә җиткән вакытта йә өченче, йә бишенче көненең уразасы тәмамланган вакытта, ике рәкәгәт намаз укып, чын ихлас һәм күңеле белән алтмыш алты тапкыр Аллаһ Аллаһ дисә, ул кешегә АЛЛАҺ Тәбарәкә вә Тәгалә үзенең рәхмәт фирештәләреннән ,бөтен эшләрендә ярдәм иттерер, бөтен  гомере буена бу бәндәнең эшләре уң булыр. Бөтен хәрәкәтләренә Аллаһ Раббуль Гыйззә рәхмәт фирештәләреннән ярдәмләрен күзенә күрсәтеп торыр. Бөтен бәлә хәсрәтләрдән бу бәндә сак та булыр дип әйтелә. **бишенчесе** исми-әгзам эчендә булган Аллаһ дигән сүзне бер кәгәзгә язып шуны бер мәетне куйган вакытында каберенә куелган булса, кем икәнлеген белеп әлбәттә, исереп үлгән, йә саташып үлгән, йә бөтенләй ышынмаган кешенең өстенә куелмый да, куелыр булса ул бәндә кабер газабыннан имин булыр бигән.

**Алтынчысының** Җәләл Аллаһның исемен Аллаһы дигән исемне бер чиста кәгәз өстенә миск хәм загфуран белән, миск дигәне хушбуй, загфуран белән бергә катнаштырып бер кәгәзгә язып, янына бер кеше йөртә торган булса, һәр вакытта Аллаһ Раббуль Гыйззә хәзрәтләре бу бәндәне саклар һәм иминлектә кылыр. Аллаһ Раббуль Гыйззә аңа һәр төрле начарлыклардан саклар шул ук вакытта патшалар, хуҗалар, түрәләр алдына кергән вакытында да бу бәндәнең сүзе үтә торган булыр, теләкләре кабул булыр, ул кеше алар тарафыннан һәр вакытта да начальникка керәсең килә икән менә шулай иттереп загфуран белән миск белән яз да куй. Аптырама Аллаһтан сора, шуны янында йөртәсең алар алдына кергән чагында да бу кеше искиткеч хөрмәт күрер, сүзе кабул ителер, алардан бер вакытта да буш чыкмас. Бу бәндәгә хуҗа- патшалар тарафыннан беркайчан да начарлыклар күренмәс ди. Менә бу кайбер әйберләре, бөтенесен әйтеп бетереп тә булмый, бәлки кирәк тә түгелдер. Ул сүзләрнең нәрсә икәнлегендә дә кешенең тәмам Аллаһка чын күңеле белән ышанып Аллаһның исемен зикер иткән вакытта һич чиксез хәдис Шәрифләрдә дә күрәбез. **Пәйгәмбәр с.г.в. хадис Кудсиләрдән дә китерде. Әйтте:** Әгәр дә, бу бәндә, мине зикер итеп, минем кушканнарымны үтәп, артыгын да үтәп нәфелләрен дә кылып миңа якын булырга тырышты исә мин аның күрер күзе булырмын, тотар кулы булырмын, атлар аягы булармын, ишетер колагы булырмын диде Аллаһы Раббуль Гыйззә. Кем аларга дошман булды исә мин аларга дошман булырмын диде. Шуның өчен дә Аллаһка якынлык булуның юлларының иң олысыннан һәм беренчесеннән Аллаһы Раббыгызны зикр итү һәм менә шуларның беренчеседә Аллаһның үз исеме Лафзаил Җәләл.

عن ابي هريرة رضي الله قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم **لِكُلِّ نَبِيٍّ دَعْوَةٌ مُسْتَجَابَةٌ فَتَعَجَّلَ كُلُّ نَبِيٍّ دَعْوَتَهُ وَإِنِّي أَخْبَأْتُ دَعْوَتِي شَفَاعَةً لِأُمَّتِي يَوْمَ الْقِيَامَةِ فَهِيَ نَائِلَةٌ إِنْ شَاءَ اللهُ مَنْ مَاتَ مِنْ أُمَّتِي لَمْ يُشْرِكْ بِاللهِ شَيْءً.**

**Абу Хурейра р.г дән  риваят ителә: Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:**

**Һәр бер иәйгәмбәрнең Аллаһ хозурында кабул булган догасы бар, һәрбер Аллаһның пәйгәмбәренең. Алар һәр кайсысы догаларын ашыктырдылар дөньяда ук, Мин үземә Аллаһның биргән бу доганың кабуллыгын саклап калдырдым өммәтемә кыямәт өчен, һәм кыямәт көнендә шәфәгәт иттереп саклау өчен, яклау өчен бу догамны саклап калдым** про запас **булып чыга Һәм һиччиксез өммәтемә ул догамның кабуллыгы ирешәчәк, кем дөньядан киткән вакытта Аллаһка ширк какмаган булса, Аллаһка тиңдәш тотмаган булса, ул кешегә Аллаһ Раббул Гыйззә минем шәфәгәтемне һәм ул кешегә минем догамның кабуллыгын насыйп итәчәк.**

**Әйт, йә Хәбибем Мөхәммәд с.г.в. Җир-күктәгеләр кемнеке? .......................**

**Аллаһныкы**, сорау Кул-лимән җавабын әйт: Аллаһның үзеннән булырга тиешле, Аллаһтан сорадың икән

**Аллаһ Раббыгыз үзенә рәхмәтне язды.** Асыл Аллаһта рәхмәт, шәфкәть, мәрхәмәт, явызлык, начарлык, үч алу юк Аллаһта. Явызлыктан кылмый бер катылык бер бәла китерә торган була, йә сынар өчен, сынап дәрәҗәсен арттырыр өчен бирә, гамәл белән ирешә алмады исә йә кылган явызлыгына җәза иттереп Аллаһы Раббул Гыйззә бирә, Дөняда шуның белән азапланып бетсен дә, мәңгелегенә калмасын дип. Йә, дөм көферлектә азгынлыгын кыла торган булса, башка изге хәерле бәндәләренә явызлыклары тимәсен өчен Аллаһу Тәгәлә аларга явызлыгын кыла, ләкин залимнән Аллаһы Раббуль Гыйззә кылмый, чөнки Аллаһның Аллаһ дигән исеменнән соң беренче килә торган сыйфаты **Әр-Рәхмән,** мәрхәмәт шәфкәтле кешегә дә, хайванга да, үсемлеккә дә, иманлысына да, имансызына да изгелеген кылганына да, явызлык кылганына да, бөтенесенә дә бертигез Аллаһы Раббуль Гыйззә рәхмәтен яудыручы

Нигә ашыксын **Аллаһ Рабыгыз һичшиксез тиздән җыячак сезне кыямәт көнендә, ул көннең булуында шик тә юк! Үз бәхетләрен оттырганнар алар ышанмаслар**, **Аллаһка да ышанмаслар, Кыямәт көненә дә ышанмаслар,** ләкин китеп тора

**Аллаһныкы төннә булганы да, көндә булганы да. Сезнең сөйләгәннәрегезне дә, моң зарларыгызны да, теләкләрегезне дә, догаларыгызны да, зикерләрегезне дә Аллаһы Тәгалә ишетүче дә, нинди күңел белән, нинди ният белән кылганнарыгызны да Аллаһ Раббыгыз белүче ди**.

Шуның өчен дә, Аллаһы Раббуль Гыйззә берлегенә тулы иман белән, ышанган бәндәләрдән булуларны насыйп әйләсәң, кувәтле булыйк дисәк, эшләребез уң булсын дисәк, батыр булыйк дисәк, һәр эшләребездә Аллаһның йәрдәменә ирешик дисәк Аллаһның зикере белән яшәүләребезне Аллаһы Раббуль Гыйззә мөяссәр кылса иде.

Росуль Әкрам с.г.в.

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: **اذْكُرُوا اللهَ حَتَّى يَقُولُ مَجْنُونٌ.**

**Аллаһны искә алыгыз бүтән күргәннәр тилергән инде бу дип әйтерлек була торган булса да ди**. Тартынмыйк Аллаһны искә алудан, дөнья ахирәт хәҗәтләребезне Аллаһтан сорыйк Үзенең зикере белән, Үзенә ялвару белән.

**ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ**

**Сорагыз, догаларыгызны кабул итүче Мин ди** Аллаһ Раббуль Гыйззә. Илләребезгә тынычлык, иминлекләр Аллаһ Раббуль Гыйззә әйләсен. Яуган яңгырлары да шифалы булсын, матур көзләре дә җитеп, анда да матур һавалары булып игеннәрне вакытында алуларны да, аларны ашаган эчкән вакытыбызда да, шөкераналарыбызны кылып, гәмәл гыйбадәт белән шөкераналар яшәүләребезне Раббуль Гыйззә насыйп әйләсә иде. Балаларыбызга тауфик истикамәтләр насыйп итсен, авыруларыбызга шифалар әйләсен, динебезгә, иманыбызга Аллаһы Раббуль Гыйззә нусрат, һәм кувәтләр, мияссәр кылса иде. Әмин.

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГАТЕНӘ "ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ" МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГАТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олылауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебез өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахаба икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреpгә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып кучүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Бергәләшеп иман кәлимәләрен** яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**

Ерак-якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сайдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-
мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвәмлы кылса иде.

*3-нче вагаз*

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

**Аллаһның Әр-Рахмән, Әр-Рахим дигән исемнәре**

“ **Әр-Рахмән”-** дигән сүзе рәхмәте күп булган тик Аллаһка гына бирелә торган исем, Аллаһтан башка беркемгә дә ул исем бирелми.

**“Әр-Рахмән”-** дигән сүз рәхмәте **өзлексез** гел булып торучы, һәр вакытта бөтен бәндәләргә, бөтен мәхлүкәтенә рәхмәтен яудыручы.

Һәр нине үзенең рәхмәте белән чорнап алучы, мәрхәмәт –шәфкәтләреннән дә, иң мәрхәмәтлесе. Дөньяда бөтенесенә Аллаһка ышанамы, ышанмаймы, мөсөлманмы, мөсөлман тугелме? Кешесе дә, хайваны да бөтен үсемлекләре дә, бөтен дөньясы шушы **Аллаһның “Әр-Рахмән”** сыйфатыннан өлеш ала.

Безнең **Әр-Рахмән** мәрхәмәт шәфкәтле дигән сүз. **Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:** Мәрхәмәт-шәфкатле булыгыз, сәхәбәләрдән кайберсе Йә, Расуллулаһ Бөтенебез, мәрхәмәт – шәфкатле барыбызның күңелләребез йомшак ди. **Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:** Алай түгел үзеңнең Ата-анаңа гына, үзеңнең балаңа гына, туганнарыңа гына түгел, бөтен бәндәләргә, бөтен хайваннарга, бөтен тирәгезгә сезнең мәрхәмәт-шәфкәтегез җитәрлек булсын ди. Безгә җитми ул, ул хәтлеге. Берәү авыр сүз әйтсә дә, берәү кыек караса да, аннан бизәсең, әмма Аллаһ Әр-Рахмән. Бөтен барлыктагы мәхлүкатларына, яратканнарына Аллаһ Раббуль Гыйззә Әр-Рахмән Ул. Мәрхәмәт-шәфкатен Аллаһы Раббуль Гыйззә яудыручы, Пәйгәмбәр с.г.в.нең алдында гаскәр сәфәрдән кайта, атлы гәскәр шәһәргә килеп кергән вакытында бер сабый бала юлга атылып чыга, атлар астында кала яза, анасы чабып чыга да, баланы бәгеренә кыса, кочаклап ала, кырыйга ала, атлар астында тапталмый, **Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:** Күрәсезме ди ананың мәрхәмәт-шәфкатен ди. Аллаһы Раббыгыз менә бу анадан да, шәфкатлерәк әдәм баларына ана ничек иттереп үзенең баласына мәрхәмәт- шәфкатле була торган булса, Аллаһ Раббыгыз тагын да бәндәләргә шәфкатлерәк.

**Шул “Әр-Рахмән” сыйфатыннан Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:** Хайван да үзенең тоягын күтәрә, баласының өстенә басмый ди. Иң ерткыч бүресе дә, аюы да, арыслан да, башкасы да үзенең баласын карый, крокодил да карый. Һәркайсасына Аллаһы Тәгәлә бу Әр-Рахмән сыйфатыннан өлешне биргән һәм **хәдисләрдә дә күрәбез, Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә:**

Әр-Рахим ананың карыны, баланың дөньяга килгәнче тугыз айдан артык яткан урыны гарәпчәсендә Әр-Рахим дип атала. “**Әр-Рахим”-** дигән сүз ди : Аллаһы Раббул Гыйззә “Минем” “Әр –Рахмән” сыфатымнан алынган шуңарга күрә дә, мәрхәмәт – шәфкатемне салдым. Шул ана карыны аркылы туган булалар, кем туганнарыннан бизсә Мин алардан биздем, кем туганнарына тоташа торган булса, мәрхәмәтле – шәфкатле булса “Мин”дә аларга мәрхәмәт – шәфкатле ди Аллаһы Раббуль Гыйззә.

**“Әр- Рахмән”** Аллаһның исеме. Без белергә тиешбез көн шикеллек иттереп ачык, җир йөзендә генә түгел, бөтен галәмдә, бөтен барлыкка Аллаһы Раббуль Гыйззә рәхмәтен яудыручы. Шуның өчен Аллаһы Раббуль Гыйззә койма төбендә исереп, аунап ятканга да, һавасын да сулата, исәнлеген дә бирә, ризыгын да бирә, изге юлда йөргәненә дә, намазын укыган, уразасын тотканына да, аерып утырмый Аллаһы Раббуль Гыйззә.

Әгәр дә, явызлыгына бераз **шымлыгына** карата, хаталарына карата Аллаһы Раббуль Гыйззә рәхмәтен дөньяда ук кисә торган булса, ул вакытта тигезсезлек булыр иде. Ләкин Аллаһның **Әл-Гадел** исеме дә, **Әл-Гадел** сыйфаты да бар. Тигезлек белән бөтен

бәндәләренә, бөтен мәхлукәтләренә караучы Ул Аллаһ.
**Әр-Рахмән** дигән исемнең саны Көръән Кәримдә **57** тапкыр килгән. Бу Бисмилләһир-рахмәнир-рахим дигәннәрен санамый торган булсак. Бисмиилләһир-рахмәнир-рахим дигән вакытта 114 сүрәнең берсесендә генә әйтелмәгән. Калган 113-дә, дә Аллаһның бу Әр-Рахмән исеме бар. Тик бер сүрәдәгенә, сугыш турында, кара-каршы тору турында сүз булганга күрә, ул исем әйтелмәде, Һәм менә корбан чалган вакытыбызда да, Бисмилләһи Аллаһу Әкбәр дип кенә әйтәбез. Монда Әр-Рахмән сыйфатын әйтү урыны булмаганга күрә.
Бер бәндә Аллаһның "**Әр-Рәхмән"-** исемен искә ала торган булса, искә алган вакытта да, әгәр дә тәсбих белән тарта торган булсак **298** тапкыр аның саны, хәрефләрнең саны буенча. Берәү шуны, яки Әр-Рахмән дип, яки Йә-Рахмәну дип әйтеп, үзенә гадәт итә торган булса Әр-Рахмән Аллаһтан аерым хөрмәтләргә дөнья вә ахирәттә бу бәндә Аллаһның гыйәнәтенә ирешүенә, Аллаһның рәхмәтенә ирешүенә сәбәпче була, хәтта китапларда әйтәләр, берәүнең баласы каты күңелле булса, йә мәрхәмәт-шәфкатсез бер кешенең катырак бәгерле кеше була торган булса, шушы Аллаһның "**Әр-Рахмән"-** дигән исемен, язып, суы белән шуны эчерергә кирәк дип әйтелгән. Яки берәүнең Аллаһка зур йомышлары бар, зур бер бәла - хәсрәтләр төшкән, шунардан котыласы килә, теләкләренә ирешәсе килә, бу кеше икенде намазын укыганнан соң, икендедән соң кыйблага юнәлеп, йә Аллаһ, Йә Рахмән дип зикр итергә, кояш баеганчыга кадәр тиешле. Кояш баеганнан соң кулларын күтәреп Аллаһтан дөнья – ахирәт хәҗәтен сораса бу кешенең, бу догасы һичшиксез кабул булачак дип әйтелгән.
Доганың кабуллыгына имин – сәламәт булуына, теләкләренә дә ирешүенә Аллаһның Әр-Рахмән исемен берәү әйтеп йөри торган булса сәбәп булыр дип әйтелә.
**Икенчесе Аллаһның Әр-Рахим Исеме**
Бу да шул ук хәрефләрдән. Төп хәрефләре Ра, Ха, Мим. Әр-Рахим дигән исем аның мәгънәсе дә нигъмәтләрен яудыруы туктаусыз, һәр вакытта булучы, һәр вакытта рәхмәтен яудырып торучы, Аның рәхмәтенә чиге булмаган дигән сүз, **Әр-рахмән** сыйфаты белән Аллаһ Раббуль Гыйззә дөньяда һәркемгә мәрхәмәт – шәфкатен җиткерә торган булса, **Әр-Рахим** сыйфаты белән Аллаһы Раббуль Гыйззә Үзенә иман белән кайтканнарга мәрхәмәт – шәфкат иясе дигән сүз.Анысы аерым.
Көфердә булган дип, динсезлектә булганнарга кыямәт көнендә Аллаһның мәрхәмәт – шәфкате юк! Дигән сүз. Гонаһлылыларга бар, кимчелек хаталыларга бар, ләкин дөм көфердә йөрегән, үзен инкарь итеп йөргәннәргә Аллаһның ул көндә мәрхәмәт – шәфкате булмый дигән сүз.
Иман белән генә катканнарга, ышанып кайтканнарга, Аллаһның барлыгына ышанган, кыямәтнең хаклыгына ышанган кешеләргә, рәхмәтен яудыручы дигән сүз. Монда нинди гаделсезлек бармы? Бернинди гаделсезлек юк, алар ул көннең булачагын да көтмәгәннәр иде. Көтмәгәннәренә ирешмәгәчтән, бернинди кайгы – хәсрәт юк шикелле аларга, олы булса да. Ул бик көтеп – көтеп аннары шунарга ирешә алмасаң зур бер оттыруда, үкенечтә булыр иде. Алар ахирәткә ышанмады, алар Аллаһка ышанмады, шуның өчен дә ул көнендә, Аллаһы Раббуль Гыйззә рәхмәтеннән аларны мәһрүм итә торган булса. Аларга бернинди гаделсезлек тә юк!
**"Әр-Рахим"** сыйфаты дөньядан киткән чагыбызда, йә кыямәт көнендә һәм мәңгелектә, ахирәттә, үзенең рәхмәтен иман белән кайткан яудыручы дигән сүз.
**Моның саны, "Әр-Рахим"** саны дүрт хәрефтән торганга күрә **258** тапкыр әйтелә: шушы исем белән Аллаһны зикр итәсең килсә тасбих белән **258** тапкыр әйтелә: "**Йә Рахиму, йә Аллаһ" дип**, йәки "**Әр-Рахману"** дисә дә була. **"Йә"** дигән сүзе Аллаһны зикер иткән вакытта исемен генә әйтергә түгел, алдында "**Йә**" дип әйтергә кирәк. Ул хәрефе була, өндәү була, чакыру була. **Көръән Кәримдә Әр-Рахим исеме Аллаһның**

**99** – биш тапкыр килгән. Бисмилләһләрен санасак анда да **113** тапкыр. “Әр-Рахим” исемен зикер иткән вакытында. Зикер итүнең тәртипләреннән дә берәү Әр-Рахим дигән язуны янында йөретә торган булса, язуын ул вакытында да бу кеше, башка кешеләрнең алдында бик кабуллы да була, дәрәҗә - кадере дә була.
**“Йә Рахиму”** дип зикер итә торган булса дәвамлы, иртәсен – кичен искә ала торган булса, бу кешенең догасы да кабул, сәламәт – имин дә була, теләгенә дә ирешер ди.
Берәү Аллаһның “Әр-Рахим” исемен **269** тапкыр язып бер кәгәзгә төнлә куркып уяна торган, төнлә йылый торган баланың янына куя торган булса, ул йылавыннан да туктар. Ул куркуларыннан да Аллаһ Раббуль Гыйззә саклар ди. **269** тапкыр төнлә куркып уянучы баланың ястык астына куела. Биш вакыт намаздан соң, һәрбер намаздан соң **269** тапкыр Аллаһның “Әр-Рахим” исемен укый торган булса берәү, бу бәндә күркәм холыклы була, ризыгында Аллаһ Раббул Гыйззә бәрәкәт бирә, саулык – сәламәтлеге дә какшамаслык була ди.
“Әр-Рахмән”, йәки “Йә-Рахмән” дигән исем белән Аллаһны зикер итү кайгы-хәсрәтләрнең китүенә сәбәп, һәм бу кешенең батыр булуына сәбәп ди. Бер дошманның арасына барып төштең икән бер карангы урында каршы бандитлар килә икән, Аллаһның **“Йә- Рахмәнү”, “Йә- Рахимү”** исемләрен әйтә торган булса, Аллаһ Раббул Гыйззә бу бәндәнең күңеленә батырлыкны да бирер һәм кайге-хәсрәтеннән дә саклар дип китапларында күренә. Берәү атнакич, җомгага каршы кичтә көмеш бер йөзеккә “**Әр-Рахмәнү – Рахим”** дип исемен язып янында йөретә торган булса, шуның өстенә шул йөзеккә караштыргалап кай-кай вакытта булса да, сирәк кенә булса да, Аллаһның бу “Әр-Рахмәнү”, “Әр-Рахим” дигән исемен искә ала торган булса, гомере буена Аллаһның кәрамы,Аллаһның саклавы бу бәндәнең өстенә төшәчәк, Аның саклавыннан бу бәндә мәхрүм булмас дип әйтелгән.
**Көръән Кәримдә** беләбез Аллаһның бу исеме белән аерым бер сүрә дә бар. Мәрһәмәт – шәфкатле

мәрхәмәт шәфкатлеالرحمن

**Ул Аллаһ, Көръәнне өйрәтте, Әдәм баласын юктан бар итте, аны сөйләрлек иттереп Аллаһы Тәгалә анарга баянны да өйрәтте ди.**
Күз алдына китерегез, сирәк булмаса күңелендәгене әйтә алмасаң, акылыңда бар, үлчи дә аласың, әйтәсе сүзеңне әйтә алмый торган булсаң, немой диләр андыйны, зур бер бәлә, зур бер кимчелек. Аллаһ Раббуль Гыйззә Мәрхәмәт – шәфкәтле Аллаһ Ул, Әдәм баласын юктан бар да итте, аңарга сөйләрлек, аңлатырлык иттереп телен дә бирде ди.
**Әйт: йә Хәбибем Мухаммад с.г.в. дөреслектә фазлы мәрхәмәт - шәфкәте Аллаһның көдрәт кулында, теләгән бәндәсенә бирә Ул, рәхмәте киң булган, эч-тышларыгызны белеүче Ул Аллаһ. Үз рәхмәте белән теләгән бәндәсен аерыр Ул Аллаһ. Олы фәзиләтнең дә иясе олы фазылның да мәрхәмәт-шәфкатнең дә иясе Ул Аллаһ ди.**
**Бу Әр-Рахмән** сүрәсен җәннәттә укылыр, һәр-бер иманлы кеше ишетер. Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә: Көръән Кәримдә карый торган булсак Аллаһның мәрхәмәт – шәфкәтенә кагылышлы булган аятлары. Хәтта менә Әр-Рахимнең мәгнәсен аңлар өчен күрәбез Бакара сүрәсендә, 37-нчы аятта.
дип килә. **Аллаһ Раббуль Гыйззә бик тә ул тәүбәләрне гафу итүче, мәрхәмәт – шәфкатле**, Рахим дип килгән, Рахмән дип килмәгән, чөнки тәүбә кылучы иманлы кеше генә була. Тәүбә кылды икән, ул кеше иманлы, шуңарга күрә дә Аллаһ Раббуль Гыйззә анарга мәрхәмәт – шәфкәтен яудыра.
**Әмма йөзләре ап-ак булган, йөзләре ак булган бәндәләр, алар Аллаһның рәхмәтендә булырлар.**
Йөзе каралар, кая икәнлеге билгеле кыямәт көне турында сүз бара, Аллаһ Раббуль

Гыйззә йөзләре ак булганнар, Аллаһның рәхмәтендә булырлар, алар Аллаһның рәхмәтендә мәңге калырлар ди. Тагын да Көръән Кәрим
**Мөхәммәд с.г.в. Көръән Кәримдә ике төштә генә Пәйгәмбәребез с.г.в.нең исеме килә, шунда Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә:**
**Мөхәммәд һәм Аның Аллаһның илчесе, Аның белән бергә булганнар, кяферләргә катылар алар, өсләренә басып сугышырга килгәннәргә катылар алар. Үзләрен яклар өчен кирәк булса, дошман килде икән, илләрен, гаиләләрен, иманнарын, диннәрен саклар өчен алар нык торырлар. Үз араларында мәрхәмәт- шәфкәтлеләр алар ди.**
Аллаһның менә, бу Әр-Рахим сыйфаты шуның белән Пәйгәмбәр с.г.в.нең сыйфатында да күрәбез, кешегә дә үтүе мөмкин.
قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: **اِرْحَمُوا مَنْ فِي الْأَرْض يَرْحَمْكُمْ مَنْ فِي السَّمَاءِ**
**Җирдәгеләргә мәрхәмәт – шәфкәтле булыгыз, күктәгеләр дә сезгә мәрхәмәт – шәфкәтле булырлар ди**. Росуль Әкрам с.г.в.
قال رسول الله صلى الله عليه وسلم**: مَنْ لا يَرْحَمْ لا يُرْحَمْ**
**Үзендә мәрхәмәт – шәфкәте**
**булмаган, ул** да **мәрхәмәт – шәфкәтне күрмәс ди,-**Пәйгәмбәр с.г.в. Иманлы кешеләр, бер-берсенә мәрхәмәт – шәфкәтле булырлар, алар иманлы кешеләр. Алай булган вакытта, мөселманнарның арасында, бер-берсенә карата каты бәгерлелек, дошманлык була тогран булса, иманлылар арасыннан әкертенләп-әкертенләп шуып чыга икәнлекләре дә күренә торган була.
**Күрерсең син аларны Йә, хәбибем Мөхаммад с.г.в. Рукугта да кылырлар, сәҗдәдә кылган хәлләрен дә күрерсең Аллаһ Раббыңнан мәрхәмәт – шәфкәтен теләрләр, Аллаһның ризалыгын теләрләр. Һәм аларның йөзләрендә сәҗдә кылганнарның әсәрен күрерсең ди.**
Кайбер илләрдә маңгайларына сызык куялар мөселманнар шул сәҗдә кылганның эзе булса иде дип, йә көйдереп, йә бастырып. Андый эз турында сүз бармый, намаз укыган, ураза тоткан кешенең йөзенә нур чыга, кәләпүш кимәсә дә, чапанын кими торган булса да, урамда да үткән вакытында бер-берсен күрә торган була. Сәҗдә кылганының әсәре йөзенә чыга торган була аерым бер нур, Аллаһтан булган нур.
**Йә, Хәбибем Мөхәммәд с.г.в. җибәрмәдек без сине, җибәрдек исә, бөтен гәләмнәргә рәхмәтебез иттереп җибәрдек ди** Аллаһ Раббуль Гыйззә. Алай булган вакытта Аллаһның рәхмәте бу дөньяга әдәм баласы булып туганыбыз да, Аллаһның рәхмәте. Кушымча иттереп мөселман кешеләре булып тууыбыз да, Аллаһның рәхмәте үзебезнең туган илебездә туып яшәүебез дә, Аллаһның рәхмәте һәр көнне туган яңа көнне күзләребез белән күрә алуыбыз да. Аллаһның рәхмәте, мә дигәне дә, тукта дигәне дә, ишетә белүебез дә, саный башлый торган булсаң Аллаһның рәхмәте исәпсез, шул олы рәхмәтләреннән Аллаһ Раббыгыз хәбибе Мөхәммәд с.г.в.не хак илчесе иттереп күндерде, һәм шунарга Аллаһ Раббуль Гыйззә безне өммәттә булуыбызны насыйп итте.
**Әйт, Йә хәбибем Мөхәммәд с.г.в. дөреслектә миңа уаха кылына Аллаһ Раббыгыздан тәңрегез, Раббыгыз Аллаһ бер, ялгыз үзе Ул тәңре**. Инде сез мөселманмы дип сора ди, Аллаһ Раббыгызга буйсынучыларданмы сез? Күпме үгетләп, күпме чакыру сезгә. Шул бер булган, ялгыз булган Аллаһ Раббыгызның колы булдыгызмы инде?
**Әгәр дә йөз** чиерсәләр, **кабул итмәсәләр. Әйт, Йә, хабибем с.г.в. барыбер сезгә рөхсәтен дә бирдем, өндәдем бөтенегәзне, кабул иткәннәрегез кабул итте, кабул итмәгәннәрегез итмәде. Йә, хабибем Мөхәммәд с.г.в. Белмим мин сезгә вәгдә ителгәнлеге, якынмы, еракмы икәнлеге, чөнки кыямәт җитәчәк. Бу дөньялары бетеп, башка дөньясы ахирәте мәңгелеге булачак, аның якынмы, еракмы**

**икәнлеген мин белмим. Ул дөреслектә Раббыгыз Аллаһ, ачыктан сөйләгән сүзегезне дә, яшеренен дә белә. Ул кыяматнең дә, кайчан икәнлеген белмәүен, сезнең дә белмәүегез, бәлки Аллаһның фитнәседер, бәлки бер вакытларга кадәр кинәнеп калсыннар дип Аллаһның биргән бер мөһләтедер. Әйт: Йә, хабибем Мөхәммәд с.г.в. Раббың Аллаһ, хаклык белән үзең хөкем ит, безнең Раббыбыз Аллаһ, бер тигез рәхмәтен яудыручы, һәр**
**анарга таянырлык, олы хуҗабыз Ул!**

Аллаһ Раббуль Гыйззә шундый мәрхәмәт – шәфкәт иясе, Әр-Рахмән булган, Әр-Рахим булган Аллаһ Раббыгызның бәндәсе, колы булып, яшәүебезгә шөкераналарыбызны үтәүләрне насыйп әйләсә иде, Аллаһның зикере белән яшәүләребезне мәрхәмәт – шәфкәтен өмет итеп, үзебезгә дә мәрхәмәт – шәфкәтле булып бер беребезгә дә, ата – аналарыбызга да, баларабызга да, оныкларыбызга да бөтен тирәбездә дә мәрхәмәт – шәфкатле булып яшәүләребезне, дөнья – ахирәттә дә Аллаһның мәрхәмәт – шәфкәтенә ирешеүләребезне Аллаһ Раббуль Гыйззә насып итсен.Әмин!

**ГОМУМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып,кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Бергәләшеп иман кәлимәләрен** яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**

Ерак-якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сайдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт- мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвәмлы кылса иде.

### *4-нче ВӘГАЗ*

### Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)

## Аллаһның “әл-Мәлик” дигән исеме

Арабский текст.............

Аллаһның 99 исеменнән “**Әл- Мәлик”** дигән исеме бар. Әр-рахмәнур-рахим Мәлик диеп килә. Мәлик дигән исем, аның мәгнәсе – патша дигән сүз. нәрсә икәнлеген беләсез – хуҗа. Кайсы бер шархларда моның аңлатуы шушылай килә.

هُوَ اللهُ مَالِكُ الْمُلْ ُوكِ لَهُ الْمُلْكُ وَهُوَ مَالِكُ يَوْمِ الدِّين وَمَلِيكُ الْخَلْق فَهُوَ الْمَالِكُ الْمُطْلَقُ

**Аллаһның “Әл-Мәлик” дигән сыйфаты, Аллаһның Үзе патшаларның да патшасы дигән сүз**, күпме дөньяда хуҗалар, патшалар була торган булса да, бөтенесенең чын хуҗасы **“Ул”,** дин көненең дә хуҗасы, дин көне кайчан? Кыямәт көне дигән сүз. Көрьән Кәримдә дә, Фатиха сүрәсендә дә килде, бүген дә дин көне, динсез көн юк, ләкин бүген башкасы да үтә, диннән башкасы да, алтын да, көмеш тә үтә, ботинка да, көпчәк тә үтә, нәрсә дә үтә, помидор да , кыяр да үтә, әмма ул көн җиткән вакытында боларның берсе дә үтми, динең генә үтә торган нине кәсеп иттең мәңгелегенә ул көнендә хуҗасы, иясе **“Ул” Аллаһ.** وَمَلِيكُ الْخَلْق - бөтен барлыкның хуҗасы дигән сүз. Кешеләрнеке генә түгел, бәлки бөтен хайваннарныкы да, бөтен барлык менә шушы җир йөзендә генә түгел, бөтен күкләр дә дә бөтен галәмнәрдә 18 мең галәм дип китапларыбызда әйтелә торган булса, барсының да юктан бар итүчесе дә, хуҗасы “Ул”.

Кайсы бер галимнәр әйтә: Ученыйлар имеш, дөрес высший разум бар, олы акыл бар, “Ул” юктан бар иткән бөтен дөньяларны, бөтен галәмнәрне, аннан соң тәбигать, бөтен барлык үзенең канунлары белән генә давам итә ди. Создатель есть, но Ул бар гына иткән дә, аннан соң бөтен дөнья, по законам природы дәвам итә ди. Алай түгел шул, Ул канунларның яратучы да Аллаһ, шуларның хуҗасы да Аллаһ, һәр көнкедә, һәр минутында, һәр секундында бу бөтен барлыкны идара итүче хуҗа Ул. Әгәр дә хуҗа патша булган Зат, йә атасыннан калды аңарга дәүләт, патшалык, йә сайлап куйдылар, йә бер ел хуҗа булып торды да, аннары секретарлар күбәйде, вәзирләр күбәйде, министрлар күбәйде, калган ягында охотога йөреп, ашап , эчеп, киенеп кенә йөри булса ул патша буламы?

Ул уенчык була! Янындагылар аннары уңга – сулга бора, аның исеменнән дәүләтне үләксә базына да илтеп куюы мәмкин, чын хуҗа булган, чын патша булган Зат бер минут, бер секундына да , **анаң** кул астындагы дәүләтне, хөкемәтне, үз хуҗалыгыннан ычкындырырга тиешле түгел, **анаң** бәхете өчен, аның киләчәге өчен, бүгенге көне өчен дә, аннары тапшырган өчен дә, уйда, фикердә һәм хәрәкәттә, хезмәттә булырга тиешле Аллаһ Раббул гыйззә, **“Мәлик”** - юктан бар итүче дә, һәм аңарга ия булучы да الْمَالِكُ الْمُطْلَقُ чын хуҗа, аннан өстен хуҗа булучы бер кем юк!

Бу Аллаһның **“Әл-Мәлик”** дигән исеме Көрьән Кәримдә 5 сүрәдә килгән. Аллаһның бу 99 исемен каян алабыз Пәйгамбәр с.г.в.нең хәдис шәрифендә сезгә исегезгә төшергән идем. Алар бөтенесе Көрьән Кәримнең сүрәләрендә килгән “Таха” сүрәсе, “Муъмину” сүрәсендә, “Әл-Хушер” сүрәсендә Җомга сүрәсендә һәм “Нас” сүрәсендә. Беренчедән “Таха” сүрәсендә Аллаһның хуҗа “**Мәлик”** дигән исеменең чын мәгнәсен аңларга тырышыр өчен. “Таха” сүрәсендә Аллаһ Тәгәлә әйтә:

**Менә шулай итеп без сиңа аны гарәп Көрьәне иттереп индердек ди. Аны дигән сүзе Көрьән Кәримне**, бөтен элеккеге пәйгәмбәрләргә күпме ваһи кылынган булса иң соңгы китап Көрьән Кәримне ваһиемне, сүземне сиңа, Йә, хәбибем Мөхәммәд с.г.в. гарәпчә укыла торган Көрьән иттереп иңдердек

**һәм ул Көрән Кәримдә әдәм бәндәләренә, кат-кат иттереп, вә кисәтүләребезне дә әйттек ди.**
дигәне шушылай иттерсәгез, шушылай иттерермен, дип Аллаһның кисәтүе предупреждениялары була кисәтүләре була.
**Шаят ки, алар Көрьән Кәримдә Аллаһның кисәтүләрен ишетеп, такваллыкта булырлар, Аллаһның газабыннан куркып, рәхмәтен өмет итеп, шаят ки, алар таква бәндәләрдән булырга тырышырлар.**
**Әгәр алай булмасалар. Аллаһ Тәгалә икенче юллар белән аларга исенә төшерер ди.**
Аллаһ кушканын үтәми торган булсаң, менә бер балага, бер әйтәсең, ике әйтәсең, өч әйтәсең, аннары да тыңламый икән шап итеп куясың. Йә урамга чыгармыйсың, йә телевизор күрсәтмисең. Ничек булса да исенә төшерәшәсең әйткәнне тыңларлык иттереп.
Аллаһ Раббуль Гыйззә дә, шулай иттерә. Йә авыру белән, йә башың сызлый башлый, йә бүтән берәр төшең. Яңгылыш итеп Аллаһның кушканын үтәмәдең исә, аннан башкаларын да Аллаһ сакласын. Җир селкенеүе белән дә, харап булулар белән дә, төрле бәла-хәсрәтләр белән дә, Аллаһ Раббуль Гыйззә, әдәм балаларын йокыдан уята. Әй тукта, минем үз эшем бар әле, бетмәде эше, Аллаһның сүзен тыңларга вакыты булмаган чагында, Аллаһ Раббуль Гыйззә шушылай иттереп тә, яки аларга иснәтүне дә Аллаһ Тәгалә шушылай иттереп бар итер.
**Бәс, чын булган хуҗа Раббың Аллаһ өстен ул - ди Аллаһ Тәгалә** бу аят Кәримәдә.
Менә монда Аллаһның **"Әл-Мәлик"** исеменән "**әл- Хакта"** килде чын дигән сүз. **"Хак"** булган хуҗа Раббың һәр вакытта өстен **"Ул"**, аннан өстен була торган бер кем юк!.
**Йә, Хәбибем Мөхәммәд с.г.в. Аллаһның ваһие иңеп сиңа беткәнче Көрьән белән ашыга күрмә.** Җәбраил галейһиссәләм Пәйгамбәр с.г.в.гә ваһине китергән чагында, пәйгәмбәр с.г.в. онытмасын өчен артыннан укырга маташкан вакытлары да бар иде.
Аллаһы Тәгалә әйтә: Көрьән Кәримнең аятлары бөтенесе сиңа иңеп беткәнче ашыкма "син" Көрьәнне укырга ди. Ашыкма! Чөнки Аллаһ Раббуль Гыйззә Ваһи белән аны бәгренә язган шикеллек иттереп калдыра иде**.**
**"Йә, Раббым Аллаһ, миңа гыйлемне арттырсаң иде", дип әйт.** Кешенең бөтен нәрсәдән, бөтен хайваннардан, хәтта фирештәләрдән дә аерылуы, һәр нәрсәнең гыйлемен белеүе белән. Аллаһ Раббуль Гыйззә, атабыз Әдәм Гәйләйһи сәләмне яратты һәр нәрсәнең исемен өйрәтте, фәрештәләргә дә аңарга карап сәҗдә кылырга кушты. Аллаһтан башкага бер кемгәдә сәҗдә кылырга ярамый, беләсез**.** Ә Аллаһы Тәгалә үзе фәрештәләргә Атабыз Әдәм гәләйһиссаләмгә карап, сәҗдә кылырга кушты. Менә берәү балта остасы: ишек ясаганмы, тәрәзә ясаганмы, йә станокта берәр деталь ясаган. Берәүләр шуны: Ай бигрәк шәп тәрәзә булган диеп, мактый торган булса шуны, эшләүчесе шатлана, куана, үзе мактаган үзе үк була торган була, бик син яхшы, остагына диеп әйтеу тугел, ой молодец диеп кенә тугел, карый-карый төрле якларыннан аның ясаган урындыгынмы, өстәленме, исе китеп берәү карый торган булса, остасы шунарга шатлана.
Аллаһы Раббуль Гыйззә дә, атабыз Әдәм гәләйһиссаләмне бар итте дә, сәҗдә кылыгыз диде. Чөнки бөтен барлыкның иң өстене, иң ямлесе, иң күркәме һәм аның эчендә бөтен галәмнәр бар ителгән, кем иде Әдәм галейһиссәләм?
Атабыз Әдәм галейһиссаләм һәм аның нәселе. Шуның өчен дә кеше, Аллаһның иң күркәм махлюгы, аның өчен бөтен галәмнәр бар ителгән. **"Мөъминун"** сүрәсендә Аллаһның бу **"Әл-Мәлик"** исеме килә.
**Уйладыгызмы сез! Ди: Аллаһы Раббуль Гыйззә. "Без сезне тикмәгә генә, юкка гына, просто булай гына яраттык дип уйлыйсызмы".** Тикмәгә генә, дөньяда килдек тә, ашадык-эчтектә, ашап – эчкәнеңне барып бушаттың да, йокладың да, үлдең дә,

киттең дә. Шуның өчен генә яраттык дип уйлыйсызмы? **Любой** заводта чыккан вакытында бер чамасы була, нәрсә өчен эшләгәнлеге, бәдрәфкә йөри торган кәгәз чыгарыла торган булса да, нәрсәгә өчен билгеле, дәфтәр нәрсәгә чыгарыла билгеле, машина нәрсә өчен чыкканы билгеле, каләмме, авторучкамы, нәрсәме ни өчен икәнлеге билгеле.

Бу кадәр миллиардлаган кешене, Аллаһ Раббуль Гыйззә нигә яратты?

**“Без сезне тикмәгә генә яраттык та, бер дә безнең хозурыбызга кайтмабыз дип уйлыйсызмы”?**

“ **Алай уйлаудан, алай тикмәгә генә юкка гына бар итүдән, чын хуҗа, чын патша булган Аллаһ Раббыгыз өстен Ул”. Аннан башка тәңре юк, олы гарешнең дә, хуҗалыкның да Ул Раббысы.**

**Кем Аллаһтан башка тәңрегә ялварыр булса, Аллаһтан башкадан берәүдән хәҗәтләрен сорар булса, аның дәлиле дә юк! Аның хисабы, отчеты да Аллаһ Раббысының хозурында булачак. Көферлектә динсезлектә булганнар котылмаслар.**

**Әйт: “Йә, хәбибем Мөхәммәд с.г.в. Раббым ярлыка. Мәрхәмәт – шәфкатеннңне яудыр, мәрхәмәт – шәфкатлеләренең дә иң шәфкатлесе Син үзең бит”, - дип Аллаһка тилмер ди. Аллаһка ялвар ди.** Мәнә ике сүрәдә дә күрәбез Аллаһның “Әл-Мәлик” исеме килгән вакытында “Әл-Хак” килде, чын хуҗа, чын патша дигән исеме килде. Хәшер сүрәсендә.

**Ул Аллаһ, шундый зат, Аннан башка тәңре юк! Яшеренне дә белеүче, күренгәнне дә белеүче, мәрхәмәт – шәфкәтле дә “Ул” – “Ул Аллаһ”, Аннан башка тәңре юк. “Әл-Мәлик” хуҗа ул, патша ул, “Әл-Куддус” – изге, “Әс-Саләм”– тыныч, “Әл-Муъмин” – иманлы, “Әл-Муһаймину”- һәр нигә өстен, хуҗа булучы да, “Әл-Газиз-Гыйззәтле” дә,” Әл-Җәббәр”-җәбер белән туктатучы, “Әл-Мутәкабир” - олы да Ул. Аллаһ Раббыгыз, аңарга ширк итеп катырга тырышканнардан барсыннан остен һәм пак Ул.**

Менә монда, Аллаһ Раббыгызның “Әл-Мәлик” исеме алдыннан, “Әр-Рахмән”, “Әр-Рахим” исеменең алдыннан килгән шикелле үк ,Лә иләһе иллаллаһү дигән сүз килде. Ул Аллаһ Аннан башка тәңре юк, чын хуҗа Ул, дигән вакытында Аллаһ Раббыбызның чын хуңа кем икәнлеген аңлатуы килде. Җомга сүрәсендә.

**Аллаһ Раббыгызга күктәгеләр, күктәге нәрсәләр, җирдәгеләр дә, хуҗа Аллаһка, патша Аллаһка, изге гыйззәтле һәр эшендә хикмәт иясенә тәсбихләрен әйтерләр.** Сезгә әйтегез дип Аллаһ әйтә: сез дә Аллаһны искә төшерегез ди, сез искә алсагыз да, алмасагыз да, икенче аят кәримәдә Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә: “әгәр дә Әдәм балалары Аллаһны искә аларга тартынсалар, җир күктәгеләр Аллаһны мактый, җир – күктәгеләр Аллаһны искә төшерә, Аллаһ Раббыгызга җир – күктәгеләр, бөтенесе тәсбихләрен әйтә”. Ул Аллаһ падишаһдыр, изгедер, гыйззәтле һәм хикмәт иясedер, **ул наданнан булган уку, - язуны да белмәгән аларның арасыннан ук илчене күндерде. Аллаһның аятларын укый, аларны хак юлга бастырып тырышып пакълый. Аларга Аллаһның китабын да, хикмәттән дә өйрәтә. Элек алар ачык саташуда булган булсалар да.** Шуның өчен, дә Пәйгәмбәр (с.г.в.) элекеге пәйгәмбәрләр шикелле үк, бергенә булган, ялгыз булган, мәрхәмәт – шәфкәтле чын хуҗа Аллаһның илчесе. **Әле Аллаһның пәйгәмбәрләренә ирешмәгән соңгыларына да, Аллаһның аятларын укый дип.** Пәйгәмбәребез заманында яшәмәсә дә, кыямәт көненә кадәр булачак, безгә дә, бездән соңгыларга да. Әлхәмдулилләһ Аллаһның китабы, Пәйгәмбәр (с.г.в.)нең сүзләре калды. “Ул Аллаһ Гыйззәтле һәм Хикмәтле”. Нәс сүрәсендә. Сүрәне укый :

**Әйт, йә хәбибем Пәйгәмбәр (с.г.в.) Кешеләрнең Раббысына сыенам,** кешеләрнең патшасына сыенам, кем кешеләрнең патшасы, берәү әйтер “мин ул”, мин миңа сыен

кубан диләр. Элек тә булды, хәзер дә бар. Кешеләрнең патшасы, бөтенесенең хуҗасы уен уйлаучы, йә мал, дәүләте, йә гаскәре, көче-куәте булганга , ләкин кешеләрнең дә хуҗасы, аларның да патшасы дигән вакытта, иманлы кеше әүвал Аллаһны таный. **Сыенам мин бәндәләрнең Раббысына, бәндәләрнең хуҗасына, бәндәләрнең тәңресенә, явызлыкны вәсвәсә кылып чәчүче, шайтанның иблисның явызлыгыннан Кешелернең бәгерләрен бутый-бутый, аларга вәсвәса салучылардан да, җенләрдән дә, кешеләрдән дә булган иблисның иярченләреннән Раббыма сыенам**.

“ Әл-Мәлик” дигән сүз. Мулкъ дип әйтәбез дип. Мулк дәуләте бар. Байлык, хуҗалык, сыеры да күп, акчасы да күп, дәүләте дә бар, җире дә бар, ул да хуҗа үзенчә нәстәгәдер, кәҗәсенә булса да хуҗа, ләкин Аллаһ Раббуль Гыйззә бөтен галәмгә, бөтен барлыкка бар итүчесе бер хуҗа булып беткәнчәгә хуҗа булып торучысы да, аннан соң да.

Моның хәрефләре “Мәлик” исемнеке өч хәреф: م - **Мим** хәрефнең саны **40**, ل -**Ләмнеке 30**, ك - **Кәфнеке 20**, шуның белән Аллаһның “Мәлик” исеме саны **90** була. Бу исем белән Аллаһка мөрәҗәгать иткәндә, йә намазлардан соң зикр иткән вакытыбызда **90** тапкыр әйтергә тиешле була, алдында, **“Йә”** сүзе белән, “**Йә – Мәлику”**, и т.п. 90 тапкыр. Алдында ال-Әлиф, ләм хәрефе белән килә торган булса, Әлифнеке тагын үзенеке **1**(бер) саны, Ләмнеке **30** булганга күрә **120** була, барлыгы **121**тапкыр.

“**Әл-Мәликү”** иттереп саныйбыз. Мәнә шушы Аллаһның “Әл-Мәликү” сүзен бер көмөшкә дүшәмбе көнне язып берәү үзенең янында йөртә торган булса, һәм һәркөнне иртә намазыннан соң **121** тапкыр искә төшерә торган булса, зикр итә торган булса, бу кеше Аллаһның көдрәте белән кешеләрнең арасында кадере артыр, һәм сүзе үтә торыр ди. Шушы сүзне зикр иткән вакытында дога галимнәр зикр итә.

**اللَّهُمَّ إِنَّكَ الْمَالِكُ الْقُدُوسُ يُحْيِي الْأَرْوَاحَ وَالنُّفُوسَ لِمَلِكِ الرِّقَابِ وَيُسَبِّبُ الْأَسْبَابِ مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ يُقَرِّبُ الْبَعِيدَ وَيُجِيبُ دَعْوَةَ الْمُضْطَرِّينَ لاَ إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ الْوَاحِدُ الْأَحَدُ ذَلَّتْ لَكَ رِقَابُ الْمُلُوكِ وَصَارَ كُلُّ مَالِكٍ لَكَ عَبْدًا مَمْلُوكًا أَسْأَلُكَ بِإِسْمِكَ الْمَالِكِ الْقُدُّوس أَنْ تَمْلِكَنِي تُمَلِّكَنِي النَّاصِيَةِ وَتَكْشِفَنِي الْحَقَائِقَ عَالَمِ الْجَبَرُوتِ لِأَحْزَابِ الْأَسْرَارِ الرَّبَّنِيَّةِ وَالْآيَاتِ الْمَلَكُوتِيَّةِ وَأَسُودَ بِإِشْرَاقِ جِنْسِي وَمَلِّكْنِي اللَّهُمَّ نَاصِيَةَ عَوَالِ إِسْمِكَ الْأَعْظَمِ الَّذِي تَعَزَّزْتَ بِهِ وَلَا يُسَمَّى بِهِ غَيْرُكَ يَا مَالِكُ يَا قُدُّوسُ يَا مَالِكُ الْمُلْكِ يَا ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ أَجِبْ أَيُّهَا السَّيِّدُ الْجَلِيلُ صَاحِبُ هَذَا الاسْمِ الْجَلِيلِ مُدَّنِي بِالرُّوحِ مِنْ رُوحَنِيَّتِكَ يَخْدُمُنِي فِي حَوَائِجِي يَا رَبَّ الْعَالَمِينَ يَا مَالِكُ يَا اللهُ.**

**Йә, Раббыбыз Аллаһ дөреслектә син чын изге хуҗа. Бөтен җаннарны да тергезүче. Бөтен муенарның да хуҗасы. Бөтен сәбәпләрне дә бар итүче. Мәлики яүмитддин дин көненең дә хуҗасы. Еракны да якынайтучы, аптыраганнарның да догасын кабул итүче. Синнән башка тәнре юк. Ялгыз гына, бергенә Син. Бөтен патшаларның да муеннары сиңа, йә, Раббым бөгелде. Һәрбер патша да сиңа кол, синең көдрәтеңдә. “Йә, Раббым Аллаһ, үзеңнен “Әл-Мәликул Куддус”исемең хакында сорыйм. Минем маңгаемны үзең тотсаң иде, йә үзеңнән башкага, Йә Раббым Аллаһ, беркемгә тоттырмасаң иде. Бөтен хаклыкларын миңа ачсаң иде. Үзеңнең олы серләреңне аңлауыма, бөтен барлыктагы булган серләр күз алдымда ачылса иде. Йә, Раббым Аллаһ! үзеңнең олы исемең, шуның белән, олы кадерләрдә булган ул исемеңнән башка беркем дә аталмаган. “Әл-Мәлик” исеменең кадерләрен Йә Раббым Аллаһ! белеп шуны миңа насыйп итсәң иде, “Йә – Мәликү”, “Йә-Куддусу”, “Йә-Мәликүль-Мулки”, “Йә-Зуль-Җәлләли вәл – Икрам”. йә хуҗам Раббым, изге Раббым!, патшаларның да патшасы булып булган, Йә Раббым! олылык һәм кадернең дә иясе булган. Ий, Раббым! миңа үзеңнен рухыңнан олы куәтләр белән йә Раббым Аллаһ! миңа насыйп итсәң иде, дөньяның бөтен хаҗәтләрен җиңеп чыгарлык булса иде, Ий галәмнәр тәрбиячесе Раббым Аллаһ, хуҗам Аллаһ** диеп дога кылуна да галимнәр тиешле итеп санаганнар. Бутәнчә дә, күңеленә нәрсә генә килә торган гына булса да дөнья, ахирәт-хаҗәтләреңне сорасаң була. **90** тапкыр бу исем зикр ителә. Аллаһ Раббым бу исемнең чын мәгънәләрнең

аңлауны насыйп итсәң. Телем белән “**Йә-Мәлик”** дип Аллаһны зикр итеп, эчендә, хуҗа иттереп башканы санасаң, я шишадан, я көчтән, я хатыннан, я башкасыннан аптырап куркып йөри торган булсаң, ул вакытта ул зикрен чын күңелдән үк чыкмый торган була. Бу исемне зикр итү Әдәм баласының йөрәген күүәтләндерә, иманын арттыра һәм дөньяда, һәр бер эшендә хуҗасы булган Раббысы Аллаһның ярдәме күзенә күренеп килеүче Инша Аллаһ сәбәп булачак. Аллаһ Раббуль Гыйззә авруларыбызга хәерле шифалар, саташканнарга тауфик истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык иминлекләр насып әйләсәң. Әмин!

**ГОМУМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГАТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреpгә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә ияргүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Бергәләшеп иман кәлимәләрен** яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**

Ерак-якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сайдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-
мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк  һәм дәвамлы кылса иде.

***5- нче ВӘГАЗ***

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ ӘЛ-КУДДУС ДИГӘН ИСЕМЕ***

Аллаһ Раббыгызның "**Әл-Куддус**" дигән исеме, Көръән Кәримдә ике урында килә ни бары. Ул да исә Хәшер сүрәсе белән Җомга сүрәсендә. Аллаһ Раббыгызның бу исеме Хәшер сүрәсендә килгән чагында олылыгына, дәлил булган, кодрәтенә, газәмәтенә дәлил булган исемнәр арасында Аллаһ Раббуль Гыйззә моны. Сүрәдә күрәбез.

**Ул Аллаһ Раббыгыз! Аннан башка тәңре юк. "Мәлик"- Ул хуҗа, патшадыр Ул. Куддус изге дер ул. "Әс-Саләм"- тынычлык,иминлек Анардан, "Мөъмин"- иманлыдыр Ул. "Мухаймин"- һәр нигә өстен, хуҗа булган заттыр Ул. "Газиз" – көч һәм куәт өстендә булган зат Ул." Әл-Җәббәр" – явызлык бар икән аны, песим-песим генә түгел ,килеп шат итеп туктатучы җәбер белән дә туктатучы зат Ул. "Әл-Мутәкәббир"- һәр кемнән өстен булган, югары булган Аллаһ Раббыгыз Ул. анарга берәүләр нинди генә кимчелекләрне табарга маташа торган булсалар да, Аллаһ Раббыгыз алардан бөтенесеннән пакъ дыр Ул ди.** Бу Хәшер сүрәсендә, ахырында бар Аллаһның бүтән исемнәре дә сөюче дә, мәрхәмәт – шәфкәтле дә, менә монда араларында да исемнәрдән килгән бөтенесен дә күрәбез Аллаһның көдрәтенә, җәберенә дә, олылыгына да дәлил булган исемнәр.

Менә шушы ,Хәшер сүрәсендә бер тапкыр Аллаһның "**Әл-Куддус**" дигән исеме килде. Аннан соң да тагы исемнәре бар. Ни өчен зикр итте, чөнки аның алдында бик олы сүз бар иде. Аллаһның бәндәләргә булган өндәүе, Аллаһы Раббуль Гыйззә әйткән иде:

**"Йи Иманлы бәндәләрем Аллаһның берлегенә ышанган булсагыз, ышанасыз икән. Аллаһтан курка күрегез, саклана күрегез, газабыннан шелтәсеннән, таквалыкта була күрегез. Һәр бер җан иясе, иртәге көнгә нәрсә әзерләгәнен карасын**. Иртәгә кияргә кием бармы, пальто бармы, иртәгә генә түгел, иртәгә көнеңә нәрсәңне әзерләдең. **Аллаһтан саклана күрегез. Дөреслектә Аллаһ Раббыгыз, ни кылганнарны  һәр кайсысын да белеүче Ул.**

**Аллаһны онытып, аннары Аллаһ үзләрен дә оныттырган кешеләр шикелле була күрмәгез. Чөнки Аллаһны оныткан кешеләр, үзләрен дә оныткан кешеләр, алар чамадан узып, бозыклыкка төшкән фасиклар – азгыннар. Ут әһеле белән утлы табада көйгәннәр белән, җәһәннәм утына төшкәннәр белән, Аллаһы рәхмәте, ризалыгы урыны җәннәтләрендә тиң булмас. Җәннәткә ирешкәннәр алар котылганнар, алар Аллаһтан олы бүләккә ирешкән бәндәләр ди.**

Менә шушы сүз бар иде! Ни сүз? Аллаһы Раббуль Гыйззә әйтә: бу сүзендә "иманыгыз дөрес булды икән, ул вакытта сез Аллаһның газабыннан сакланып йөри күрегез, һәр көнегез өчен әзерлегегезне күрегез, мәңгелегезне дә бар иртәге көн, иртәге көн генә түгел, мәңгелегез дә бар. Бу ямле дөньясыннан китәчәгегез дә бар, Аллаһ Раббыгызның хозурына кайтачагыгыз бар иманлыгызның дәлиле, иманыгызның нәтиҗәсе, аның яме , бу дөньягызда да, мәңгелектә дә яктыртырлык булырга, нурлы булырга тиешле. Үзләрен, Аллаһны да онытып, үзләрен дә, оныттырылган бәндәләр шикеллек иттереп була күрмәгез. Аллаһны оныткан кешеләр ничек? Мәчеткә генә килеп намазда укыган вакытта искә төшереп, бөгелеп-сыгылып, сәҗдәләрен кылып намазын укып, аннары

мәчеттән чыгып киткәннән соң, ашаган ризыгында да, сөйләгән сүзендә дә, эшләгән эшендә дә, бер нәрсәне дә уена, фикеренә китермәгән кеше, шул бәндә Аллаһны оныткан кеше. Кулында тәсбихы була торган булса да, кат-кат Аллаһ диеп әйтеп йөреп, Аллаһның кушканын үтәмәсә, тыйганыннан тыелмаса, ул бәндә Аллаһны онытканнар белән бер була. Аллаһның хозурында кайтачагың. Үлгәннән соң, яңадан терeләчәген исенә төшерә торган булса, иманлы кеше. Ашаган ризыгы хәләлме? Хараммы? Сөйләгән сүзендә ярарлык сүзме? Дөньямы, ахирәтме, әллә юкмы? Атлаган адымнарымда, эшләгән эшендә дә, һәр кайсысында да, үзенең нәфесен, үзенең җанында исәпләргә Аллаһның хозурына кайтуын исенә төшерергә тиешле. Шул вакытта гына Аллаһны оныткан бәндәләрдән булмый, Аллаһны онытты исә, бу бәндә үзен дә Аллаһы Тәгалә оныттыра. Үзенең дә файдасын да күрми, гел генә шымлыкларга чумып, бәхетсезлек – азгынлыкларга гына төшеп, дөньясын да, ахирәтен дә хараб иткән кешеләрдән булачак, Аллаһ сакласын.

Шуның өчен дә, Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәләр фасикка - гөнаһка төшкән бәндәләр ди. Исегезгә төшерегез ди, сез Аллаһыга ышандык дигән вакытыгызда, үлгәннән соң кубарылуга да, ышандыгыз ди. Кыямәт көненең хаклыгына ышандыгыз, Аллаһның хозурына кайтып, басып, хисап бирүегезгә ышандыгыз! Анда җәннәте бар, җәһәннәме бар, утта көйгәннәр белән җәннәт бакчаларында кинәнгәннәр бергә булмас. Җәннәт әһелләре алар котылганнар. Аллаһның рәхмәтенә ирешкән бәндәләр. Шушы сүзне әйткәннән соң Аллаһ Раббуль Гыйззә

**Ул Аллаһ Раббыгыз! Аннан башка тәңре юк! Ул Аллаһ Раббыгыз. Ул Аллаһ Раббыгыз! Хуҗа да, дөньясының да хуҗасы, ахирәтенең, дә хуҗасы, җәннәтенең дә хуҗасы, җәһәннәменең дә хуҗасы. Сезнең дә хуҗагыз, ләкин ашыкмый. “Әл-Куддус” -ул изге Ул! Изге ул Аллаһ Раббыгыз!** Җомга сүрәсендә күрәбез. Җомга сүрәсендә Аллаһның иенә бу, “**Әл-Куддус”-** исеме, изге дигән исеме сүрәнең башында ук килә, алдында бернинди дә сүз юк.

**Олылыйлар, пакълыйлар, Аллаһ Раббыгызны. Күкләрдәге булган нәрсәләрнең, җирләрдәге булган нәрсәләрнең, бөтенесе, хуҗа булган, изге булган, куатендә, гыйззәтендә олы булган, өстен булган, һәр эшендә хикмәт булган Аллаһ** Раббыгызны ди. Бөтенесе, күпме барлыгы ,бу ни дигән сүз? Сез Аллаһны мактасагыз да, мактамасагыз да, Аллаһка тасбихларыгызны әйтсәгез дә, әйтмәсәгез дә, Аллаһны искә алсагыз да, алмасагыз да: күктәге кошлары да, йолдызлары да, ай, кояшлары да, бөтен планеталары да, әле сез белмәгәннәрнең барысыда, җирдәге агач ташлары да, кортлары хайваннары да, бөтенесе Аллаһка тәсбих әйтеп тора. Бөтенесе Аллаһны искә төшерә, Аллаһ кушканча яши, Аллаһны олылый, Аллаһның барлыгына дәлил иттереп, үзләренең барлыгы тора, күрсәтеп торалар, менә шушы сүзне Аллаһ Раббуль Гыйззә, Җомга сүрәсенең башында әйтә. Баягы сүрәдә, Хәшер сүрәсендә Аллаһ Раббуль Гыйззә олы сүзне әйттедә, аннары үзенең кем икәнлеген искә төшерде. Монда Аллаһ Раббуль Гыйззә, Җомга сүрәсендә алдан кем икәнлеген сөйли, көчендә куәтендә көдрәтендә өстен зат икәнлеген исебезгә төшерә. Гыйззәт тә анарда, хикмәт тә анарда изге Ул, хуҗа Ул.

Сүрәнең исемен онытмыйк нинди сүрә Җомга сүрәсе. Җыела торган Җомга сүрәсе, көннәрнең дә өстене иң кадерлесе булган Аллаһ каршысында, ике Гәетебездән дә олырак булган мөбәрәк булган көн, чөнки бу көндә, җомга көнендә Пәйгәмбәр (с.г.в.) әйтә: Бер сәгать бер вакыты бар, бер мизгеле бар, берәү Аллаһтан дөнья ахирәт хәҗәтләрен сорап, күңеле ихласы белән, дога кылды икән, кабуллыкка ирешә һич - чиксез ул догасы кире кагылмас ди. Җомга алдындамы ул, ике азат, каумәт арасындамы ул, фарызы белән сөннәте арасындамы ул, кояш баеганчыга кадәр, шушы көндә, шундый бер мөбәрәк Аллаһның кабул бер сәгате бар. Шуның өчендә менә, бу Аллаһның

кодрәтенә дәлил булган исемнәрдән соң Аллаһ Раббуль Гыйззә, бу сүзне әйтә:
**Әйт: йә хабибем Мөхәммәд с.г.в. – дөреслектә ул үлем! Сез анардан кача торган үлем, сезгә** юлыгачак. Бер кеше искә төшерәсе килми, ләкин һәр көнне күз алдыбызда атаңда, анаңда китеүе, мөмкин Аллаһ сакласын бәгер җимешең дә китеүе, дистәләп-дистәләп сабыйларда дөньядан китте. Һәр көн Аллаһ Раббуль Гыйззә күрсәтеп тора мәңгегә килмәдегез!. **Ул үлгәннән соң, туфракка, җиргә генә , кереүегез түгел, җир астына күмелүегез генә түгел, тар ләһетләргә кереү генә түгел, эчегезне-тышыгызны белүче Аллаһ Раббыгыз хозурына кайтарыласыз**. **Нәрсә эшләгәнегезне, һәр кайсысын, берәмтекләп-берәмтекләп һәр кайсыгызга да ни кылганнарыгыз, ни эшләгәннәрегез һәр кайсыгыз тезелеп чыгачак.** Үлем дә алдыгызда булса, Аллаһның хозурына кайтырлык була торган булсагыз Минем сүземә ышансагыз, ышанмасагыз да барыбер кайтасыз. Ий иманлы бәндәләрем:
**Сез, Аллаһны искә алырга, намазга азан әйтелде икән чакырылдыгыз икән, җомга көнендә Аллаһны искә алыуга ашыгыгыз. Иң тәмле, ләззәтле дә, булган эшләрегезнең берсе. Сатуны куеп торыгыз, сату-алуларыгызны куеп торыгыз. Бу сезнең өчен хәерлерәк булачак белер булсагыз.**
**Намазыгызны үтәдегез икән, җәелегәз җир йөзенә!. Аллаһның рәхмәтеннән булган, нигъмәтләреннән булган дөнъяның бөтен нигъмәтләреннән теләгез, эстәгез, алыгыз!. Аллаһны эзләгәндә, аларны тапкан кәсеп иткән чакларыгызда да, Аллаһны искә алыгыз, зикр итегез. "Шаят ки, сез котылырсыз ди"!** Аллаһ Раббуль Гыйззә шушыны әйтә: шул сүзне искә төшерер өчен "минем" кодрәтемне онытмагыз, "мин" хуҗа икәнлекне, кодрәт иясе икәнлегемне онытмагыз, бәндәләрем! Атнасына бер тапкыр булса да, җыелышыгыз җәмәгать намазына, чөнки менә монда җыелышкан вакытта, ялгыз да, өйдә дә намаз укып була. Аерым – аерым да була, ләкин ике генә кеше укыды исә ул җәмәгать була өчәү, дүртәү, бишәү булды исә, кырык булды исә Пәйгәмбәр (с.г.в.) әйтә: Ул вакытта гәскәрсез ди. Йөзләгән меңләгән кеше булды икән, намаз сафларында кеше артык булган саен, ул намазның дәрәҗәсе Аллаһ хозурында кабуллыгы арта. Боларның нурлары берсе-берсенә кушыла. Аллаһ Раббуль Гыйззәнең рәхмәте бу бәндәләргә төшә торган була. Мәчетләребездә менә шушылай борылып карасак артларыбызга, буш түгел, ул сафларда, анда Аллаһның рәхмәт фирештәләре шуңарга күрә алгарак-алгарак барып утырабыз, ләкин фирештәләрнең гонаһлары юк, алар аны эшли дә алмый, булдыра да алмый, без булдырганны әҗер савап та безгә кирәк иде. Атнасына бер тапкыр булса да, шул базарлардан дөнья куулардан, чабып йөрүләребездән тукталып, менә шушында җомгабызга килеп Аллаһның сүзен ишетергә. Пәйгәмбәр (с.г.в.)нең дәресен алырга, тагын бер атналык булса да күңелләребезгә, җаннарыбызга, азык алып, бер атна булса да Аллаһ кушканча яшәргә ашкындык исә, атна буена Аллаһның рәхмәте безне ташламый. Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә: **Бер намаздан икенче намаз, бер җомгадан икенче җомга, бер Рамазаннан икенче Рамазан аның араларындагы бөтен гонаһларны себереп түгә ди.**
Бер кеше җомгага килеп, намазны үтә де икән җәмәгать белән бергә, ул вакытта Аллаһы Раббуль Гыйззә бу бәндәнең 10 көннек кимчелек хаталарын ярлыкый. Бу атна арасындагы җиде көннекен дә тагын өч көнгә әле запаска кала торган була ди. Ни бәрәкәтендә? Шушында Аллаһ Раббыгызга, дөнья кууларыбыздан да, базар мәшәкәтләребездән дә, кәсәптән дә бетми ул эш. Мең ел яшәсәң дә Аллаһ Раббуль Гыйззә, гел мәшәкатен таба сиңа. Әгәр дә син ул мәшәкәть арасында, Аллаһны искә алырга вакыт тапмасаң. Аллаһны искә алырга вакыт таптың исә, Аллаһ Раббуль Гыйззә ул мәшәкәтләреңне бөтенесен, үзенең рәхмәт фәрештәләреннән гаептән килгән **иреннәрдән,** Аллаһ Раббуль Гыйззә эшләреңне бетерәчәк. Артык вакытаң да калачак. Ул вакытыңны искә алып эшли торган булсаң, ул кәсебеңне дөньяңны куган чагыңда:

Дигән, әмеренә буйсынып **Аллаһны, күп искә алыгыз, шаят котылырсыз, эшләрегез уң булыр дигән.** Вәгъдәсенә карата, бөтен эшләребез, йомышларыбыз күз алдыбызда, йомгакланып, бәрәкәте килер. Аллаһ насыйп итсә, яшәүебездән дә, ләззәттән һәм мәңгелегебезгә дә ,Аллаһ Раббыбыздан әҗер һәм савапларны инша Аллаһ ирешәчәкбез.

Менә шушыны искә төшерер алдыннан Аллаһ Раббуль Гыйззә “**Әл-Куддус”-** дигән икенче тапкыр Көрән Кәримдә исемен зикр итте, ни була “Куддус”- дигән исем? Ни бары Көръән Кәримдә ике генә урында “**Әл-Куддус”** аның масдары(чыгышы), “**Әл-Кыйдәсә” - изгелек** дигән сүз. Изгелек- беләбез ул сүзне, изгелек эшләде изге бәндә бу, якшы кеше дибез. Аллаһ та, изге кеше дә изге була аламени? Була ала икән, чөнки Аллаһ Раббуль Гыйззә Әдәм баласын, үзенең җир йөзендәге хәлифәсе иттереп яратты, җир йөзендәге вакиле – кем ул? Приказчигы. Бер директор була, бөтен эшне ул эшләми бит, кул астындагы ярдәмчеләре йөри, завоттамы, сату сәүдәсендәме, үзенең йомышын йомышлаучылар була.

Аллаһ Раббуль Гыйззә бөтен ямле дөньяны яратып, шушы ямле дөньясына вакиле иттереп, бу дөняның хуҗасы иттереп Аллаһ Раббуль Гыйззә Әдәм баласын халифә иттереп яратты. Һәм шунарга күрә дә, Аллаһ Раббуль Гыйззә Әдәм баласына, менә дигән төс кыяфәтендә, булдыклыгын да, батырлыгын да, акылың да, зиһенең дә, күрерлек күзеңдә, ишетер колагыңда, көчең – кууатеңдә һәм изгелегеңдә Аллаһы Раббуль Гыйззә бирде.

Сабый чактан ук булган изгелекне, Аллаһның биргән изгелеген, көферлек гонаһлар белән, явызлык – азгынлыклар белән быкырдатмадык исә гомеребез буена саклап, изге бәндәләрдән булып Аллаһның дусты булып, дөньяда яшәп, Аллаһның дусты булып дөньядан үтүебезне дә Раббул Гыйззә насыйп итәчәк. Аллаһның “**Әл – Куддус”** исеме шуны күрсәтә, үзе – үзенән Аллаһ Раббуль Гыйззә изге, шунарга күрә дә, Аллаһы Раббуль Гыйззә изгелекне тели. Бер кеше явыз азгын булса, үзеңнән явызлыгы да чыга, башка кешенең явызлыгын күргән вакытта аңарга исе китми, кинәнеп тора. Кара, бу да минем шикеллек дип, берәү изге, йомшак куңелле, матур тәбигатъле була торган булса, эшләгән эшендә дә анарда, йомшак тәбигатълек тә, күркәм холык та, изгелек тә, башкалардан да шуны күрәсе килә. Башкалардан да шуны кургән вакытында, сөйенә, куана. Китапларыбызда язылa, кем Аллаһның менә бу исемен, “**Куддус”-** исемен һәр вакытта искә ала торган булса, ул бәндә явыз холыклардан котыла. Аллаһы Тәгалә коткара.

Аллаһның изге икәнлеген искә төшереп ,“**Йә – Куддус”** и т.д. әйтә торган булса, теленнән төшерми торган булса, Аллаһы Тәгалә бу бәндәнең каты күңеленнән, начар эшләреннән котылуга кууәт бирә. Һәм бу бәндәнең күңеле, йомшаклык белән, изгелек белән тула торган була диләр. Бигрәк тә, хәрәм ризыклардан сакланып, артык каныбызны кайната торган ризыклардан да сакланып, куәтле ризыклардан да сакланып.Берәү, иртәнге намаздан соң **170** тапкыр Аллаһның бу исемен таң намазыннан соң әйтә торган булса, бу бәндә үзе хәйбәтле була, мәхәбәтле була, сүзе һәр кем кабул итә торган бәндәләр арасында да дәрәҗәсе арта торган була ди. Һәм арасында **170** тапкыр “**Йә – Куддусу”** и т.п.дигеннән соң

**سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّ الْمَلاَئِكَةِ وَالرُّوحِ**

дип йомгаклап куергa тиешле ул да гүзәл булыр диләр. “**Әл – Куддус**” исеме **4** – хәрефтән тезелә; **“Каф”**, **“дәл”**, **“уау”**, **“син”**, **“уау”**ның өстендә тәшдиде дә бар. **“Каф”** хәрефе үзе шундый хәрефләрдән, кайсыгына сүздә **“каф”** хәрефе булган булса катылыкны күрсәтә. Тәкъдир дигән сүздәдә, Кадир дигән сүздә дә, ис киткеч катылыкны, ныклыкны күрсәтә торган була. Шул хәрефнең бәрәкатендә бәндәнең кадере дә артуы, дошманларга өстен булуы да, дошманнарның телләренең баглануына

да, үзенең теләге ирадасе куатләнугәдә сәбәп була. **ق - Кафның** саны **100**, **د -дәл** – хәрефе йомшак хәрефләрдән, чөнки изгелектә йомшаклык та бар,аның саны **2**, 2*2була **4**, **و - уау** – хәрефе ис киткеч йомшак

хәреф **уау** дигән вакытыбызда аның **6**, анан соң **"син"** килә, **س - "син"** дигән сүздәдә, шулай ук **"син"** хәрефе. **"Син"** хәрефе буенча саны **60** – ка килә. Менә шушыларның бөтенесе җыелган вакытында **170** була һәм Аллаһ Раббыгызны бу исеме белән аңарга берәр теләк, берәр максат белән ялвара торган булсак, дога кылыр алдыннан **170** тапкыр шушы исемен "**Йә – Куддусу"** и т.д. дип әйтергә тиешле була. Менә бу Аллаһның мөбәрәк исемнәреннән бер исеме Аллаһ Раббуль Гыйззә, "**Әл – Куддусу"-** изге ул! Бездә үзебездә изгелекне арттырырга тырышырга "**Әл – Куддус"** булган Аллаһ Раббыгыздан бөтен изге эшләребездә ярдәмнерне теләүләребезне Аллаһ Раббыгыз насыйп әйләсә иде. Изгелек булган вакытта гына гамәлләребез Аллаһ хозурында кадерле, җаннарыбызга да рәхәт, дөнья ахирәтебезнең изгелегенә дә ИншаАллаһ сәбәп булыр. Әмин!

**ГОМУМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Бергәләшеп иман кәлимәләрен** яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**

Ерак-якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сайдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-
мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвәмлы кылса иде.

***6 –нче ВӘГАЗ***

**<u>Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)</u>**

## ***<u>АЛЛАҺНЫҢ Әс – СӘЛӘМ ДИГӘН ИСЕМЕ</u>***

**Аллаһ Әр-Рахмәнур-Рахим әл-мәликуль куддусу-сәләм.** Аллаһ Раббыбыз дөньяда, һәр кемгә мәрхәмәт шәфкәтле. Иман белән кайткан бәндәләргә рәхмәт иясе. Көръән Кәримдә, "Әс–Сәләм"- дип Аллаһның исеме нибары, бер урында, ул да "Хәшер" сүрәсендә килә. "Сәләм"- дигән исеме сүздә, башка урыннарда килә торган булса да. Бу сүрәдә, "Хәшер" сүрәсендә, бер ничә исемнәр Аллаһның җыелган иде. Ахырындагы аятләргә карасак Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә: Хәшер сүрәсен укый.

Ул Аллаһ Раббыгыз! Анан башка тәңре юк, тик Ул гына "Әл – Мәлик"- хуҗа, "Әл – Куддус"- изге, "Әс – Сәләм"- иманлы да Ул, өстен дә Ул, гыйззәтле дә Ул, җәбер белән явызлыкны туктатучы да Ул. Өстен дә Ул. Аллаһ Раббыгыз анарга ширк катырга, тиңдәш тоторга исәпләгәннәрдән бөтенесеннән өстен. Һәм пакъ ди. Көръән Кәримнең аятләрендә Аллаһ Раббыгызны бу "Әс – Сәләм"-дигән исемен мәгънәсен аңлатырлык иттереп, башка бер аятләргә карасак, Аллаһ Раббуль Гыйззә Юнус сүрәсендә әйтә:

**Ул Аллаһ Раббыгыз! өнди, чакыра, сәләм йортына тынычлык, иминлек йортына Раббыгыз өнди, һәм теләгән бәндәсен хак юлга да кундерә**.

**Изгелекне эшләгән кешеләргә, ихсан кылган кешеләргә, изгелек булыр. Артыгы белән ди, Аллаһы Раббуль Гыйззә.** Шушы аятның соңында изгелек дигән -сүз Аллаһны күргән иттереп эш итү. Сөйләсәң дә, йөресәң дә, эшләсәң дә, мин күрмәсәм дә, Раббым Аллаһ, мине күреп тора дигән нияттә булу. Изгелек -шул. Нәрсә генә эшли торган булсаң да, Аллаһ Раббым мине күреп тора дип. Шушы теләк белән дөньяда яшәгән, шуны гамәлгәдә ашырган кешеләргә. Аллаһ Раббыларыннан изгелек артыгы белән дә булачак. Чөнки Аллаһ Раббуль Гыйззә кылган гамәлеңә,иң әзендә ун өлөш әҗер савабын да бирә. Җиде йөзгә кадәр булуы мөмкин, теләгәненә исәпсез дә. **һәм аларның йөзләренә караңгылыкта килмәс, чырайлары да бер кайчан да сытылмас, хурлык түбәнлектә килмәс. Менә шунарга ирешкәннәр бәндәләр җәннәт әһелләре**, **алар анда мәңге калырлар ди Аллаһ Раббуль Гыйззә.** Ләкин менә шушы, җәннәт әһеле. Җәннәтнең **<u>даруссәләмнең</u>** Аллаһ Раббуль Гыйззә сыйфатын әйткән вакытында, йөзләренә караңгылык та килмәс. Борчу да төшмәс, аларга хурлык та килмәс, мәңге алар анда калыр дигән вакытында Аллаһ Раббуль Гыйззә аның алдыннан, ә җәннәт булмаганы нәрсә? Ул даруссәләмнән башкасы нәрсә икәнлеген Аллаһ Раббуль Гыйззә, дөнья тормышын, безнең яшәгән тормышыбызны мисал иттереп, бу аятны алдына китерә. Әммә дөнья тормышы, якын тормыш, хәзер яшәгән тормышыгыз күктән төшкән су шикелле ди. Күз алдына китерегез, ул су белән җирдәге үскән үсемлекләр дә катнашты. Әдәм балаларының ашаганнары да, хәйваннарның ашаганы да. Хәттә җир йөзе, үзенең бөтен бизәкләрен алды гөлләр, яфраклар ярды, чәчәкләр атты, җимешләр өлгерде.

Бөтенләй бизәнде җир йөзе. Кайсы ягына карый торган булсаң, сокланып карарлык.

җирдә яшәгәннәр бөтенесе бу безнеке инде хәзер, безнеке инде өзеп алабыз, кабабыз дигән вакытында

Безнең кушуыбыз, әмеребез төште дә ,җир йөзенә йә төнлә, йә көндезендә

Кичә генә бер нәрсә булмаган шикеллек иттереп урылган, бөткән, төтелгән, иттереп тә кылып куйдык. Уйлаган исәпләгән кешеләргә, шушылай иттереп, аятларыбызны бәйнә-бәйнә иттереп, аңлатабыз ди.

Карагыз әле Краснодарда, әле кайларда, Чехословакияларда, кайларда гына, нинди генә әфәтләр, нинди генә бәләләр килми. Бөтен җимешләре өлгергән, бөтен дөнья ял итергә җыелган, тәмләп ашап, кып ялангач бөтеннәй кинәнеп, диңгез буйларында сузылып ятырга дип барган чагында: әфәтләре дә, бәлаләре дә килә дә, исәпләмәгән төшләрдән дулкын-дулкын сулары да басып китә, нинди генә бәла-хәсрәтләр китерми. Ишеткәнебез дә юк инде бу кадәр иттереп: кырыгышар, иллешәр, йөзәр кешеләр диңгезләргә агызылганнарны, никадәр ваемсызлык, ни кадәр исәпсезлек, каян булырга тиеш иде бу. Менә шушы дөнья тормышы инде ди Аллаһ Раббуль Гыйззә. Бу дөнья тормышы инде, алай булган вакытта, Сәлам дигәне, сәлам йорты да, кайгы-хәсрәте, бәла-әфәтләре булмаган урын. Аллаһның бу исеме дә, кайгы, бәла-хәсрәтне бирмәүче, бәлки Әдәм баласының күңеле дә, тәне дә, бөтен тормышы да, бәхетле барлык итүче. Моннан соң да Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә:

**Әйт, йә Хәбибем Мөхәммәд с.г.в. Мактау, олылауларның бөтенесе Аллаһ Раббыма булсын. Аллаһның үзе сайлаган бәндәләренә дә булсын. Аллаһ хәерлерәкме, әллә сезнең чирк катканнарыгызмы? Аллаһтан башка, тагын кемдер сезгә: тынычлыгында , бәләсен дә,шатлыгын да, хәсрәтендә, да бирүче дип, бар уйлыйсызмы. Аллаһ хәерлерәк, әллә алармы?**

Әллә җир-күкләрне, күзенә сыйдырып бетерә алмаслык күкләре, бөтен йолдызлары, айлары, кояшлары, бөтен планеталары белән. Шуларны искиткеч ямле җирен бар иткән, күктән сезгә: суын да, яңгырын да яудырган, сокланып бетә алмаслык бакчаларын да, шуның белән үстергән. Ул бакчларның бер агачын да үстерә алмыйсыз бит! Ди: Аллаһ РаббульГыйззә. Аллаһтан шунарга үсеүгә бәрәкәт булмаса. Ташлаганнан соң да, орлыгын утыртканнан соң да, суын сипкәннән соң да, үсмәүе мөмкин. Аллаһның әмере булмаса. **Аллаһтан башка тагын тәңре бармы? Ул яңгырын да яудыручы, Ул агачларын да, Ул үсемлекләрен дә үстерүче, тагын тәңре бармы? Ләкин дөньяда. Шушы дөньяда яшәүче, бәндәләрнең арасында, хактан ауышкан тайпылган, булдырабыз бөтенесен дип, йөргән халыклар да бар ди.**

**Әллә җирне, нык урнашырлык, бер, урын кылган. Аның бөтен тирәләрендә елгаларын агызган, какшамас -авышмас тауларын да бар иткән. Диңгезләрнең арасын да аерган Аллаһмы, әллә анардан башка тагын тәңре бармы Аллаһ белән, ләкин кешеләрнең күбесе шушының аермасын да белми.** Аллаһ РаббульГыйззә җирне карар иттереп кылды. Карар дигәне без карарны кабул итеү, ләкин карар какшамаслык урын. Менә бу аны күрәсез, селкенеп тора, хәзер матрацлар бар 20-15см пружиналы, өстенә бассаң каушап торасың, аягың нинди була торган булса да, я казылган җир йомшак булса, аңардан барганда да тигез итеп барып булмай.

Аллаһ Раббуль Гыйззә, йә көймәдә барганда дулкыннар булган чагында, йә машинада тормозить итә башлады, терәлдең, маңгаең белән тәрәзәсен дә тишеп чыгуы мөмкин, яки самолетта, поездда барган вакытта карары бар идеме, юк карар, гел исәпләп торасың кайсы якка каушар икән, кайсы якка авышыр икән дип, әзер булып торасың. На чеку булып торасың. Аллаһ Раббуль Гыйззә күктә оча торган, җир йөзендә, самотетларга, ракеталарга караганда да тиз, оча җил, үзенең юлында, ләкин без аны сизмибез дә, нык иттереп шушы җир йөзендә Аллаһ Раббуль Гыйззә бу җир йөзен карарлы иттереп кылды. Елгалары булмаса ,карагыз , бөтен авыллар, бөтен шәһәр дә иң зур елгалар тирәсендә урнаша. Кайда бераз гына су булды икән, күлләр булды икән, чиста пакъ су булды икән, шуның тирәсендә бөтен авыллар да урнаша торган була. Аллаһ Раббыбыздан башка моны кем бар итте? Эшләп карыйбыз төрлесен дә, сазларын

да киптереп карыйлар, каналларын да эшләп карыйлар, ләкин алардан файдалануы шул ук суны эчә дә алмый, хәттә Аллаһның яратткан күлләрен дә, елгаларын да быкырдаудан башка, бөтен канализацияларны шунда агызудан башка әллә нәрсәне Әдәм баласы булдыра алмады. Элек тә миллионлаган-миллионлаган халык яшәгән. Ләкин бернинди фильтырлары да, бер нәрсәсе дә, хәзерге шикеллек иттереп тилмереп йөреп, чишалап-чишалап су сатып алуга гомердә дөнья калганы юк иде. Тауларын да, җир йөзенең әйләнеүенә дә, бизмәнне тигезләгән итеп Аллаһ Раббыбыз бар итте. Диңгезләр арасын да аерды, ничек иттереп диңгезләр аерылган ди?. Кайда, диңгезләрдә бармы анда ни булса да, **койма‌лары, капкалары**. Һич чиксез юк та алар, ләкин барлары да бар икән, бөтен диңгезләрнең сулары тозлы була торган булса да, шуларның арасында да Аллаһ Раббыбызның шуны уртасында пәрдә белән кылганнары да бар. Галимнәр аларында эзләделәр, таптылар, хайран булдылар. Алар аны бүген эзләп күргән генә булсалар, әмма Аллаһ Көръән Кәримендә 1400 ел моннан элек үк аны әйткән иде, шуларны күреп, хайран булып, Кусто дигән бар иде эзләнүче галим, хәттә иман китермичә хәле дә булмады.

**Аптыраганның догасын да, Анарга ялварганда кадар итүче тагын кем бар? өстегезгә төшкән бәла-хәсрәтне дә китәрүче, сезне җир йөзендә хәлифәсе иттереп яратучы Аллаһтан башка тагын кем бар? Әдәм баласының күбесе моны исәпләми** дә ди Аллаһ Раббуль гыйззә. Аллаһ Раббуль Гыйззәгә болай итү мөмкин, ярар тегенекен кабул итте, моныкын кабул итте. Әдәм баласы яшәгәндә шундый хәлләргә төшеүе мөмкин. Кырык врач, бөтен доньяның профессорлары, әллә кемнәре үгетли торган булса да, кабул итми, бер сүзен. Күңеленә бер тынычлыкны китереүе мөмкин түгел, менә әле кырыгын үткәргән сабыйлары киткәннәрнең кем баласын кайтара ала. Ятимнәр йортыннан да алып тәрбияләсәләр күңелләренә бер җылылык булыр. Кайсылары мәчеттән башладылар, кайсылары ятимнәрне алалар, кайсылар тетелгән гаиләләре төзеклнә башлады, балалары киткән, бөтеннәй калмаган, ә алар ул **хәдисәгә** кадәр ир-хатын талашып балаларны тилмертеп йөрткән булганнар. Алар да үзенең хаталарын аңлап, кушылып, ир-хатын гаиләләрен корып яңадан төзекләндерделәр. Аллаһ шушылай иттереп тә исләренә төшерде. Менә шул аптыраган күңелне, кайда барыйм, ни эшлим дигән вакытта, күңелгә карарлануны да бирүче, тынычлыкны урныштыручы да Аллаһтан башка зат юк.

Ул да бөтенесе Аллаһның “Әс-Сәләм” исеменнән. Тынычлык, иминлек анарда үзендә. Тынычлык, иминлекне дә бирүче ялгыз Ул. Һәм Аллаһ Раббуль Гыйззә, Раббыбыздан башка, өстебезгә килгән бәла-хәсрәтләрне дә **китәрүче** кем бар иде?. Берәү, баласына юлда булган киртәсен алуы мөмкин, бер канау аркылы, бер чокр аркылы күтәреп чыгаруы мөмкин. Зуррак йомышың булса, заводның директорынамы, хуҗагамы барып тилмердең, ләкин бар шундый бәлә-хәсрәтләр Аллаһ Раббыңнан башка аны сиңа бер кем китерә алмый. Сиңа тынычлык күңелеңә карарлану иминлекне бирүче Аллаһтан. Башка тагын кем бар ди Аллаһ Раббуль Гыйззә?. Һәм сезне җир йөзенә, үзенең хәлифәсе иттереп яратучы Аллаһ Раббыгыздан башка кем бар?

Хәлифә дигән- сүз наместник богу, на земле. Әдәм баласы, һәр бер кеше Аллаһның җир йөзендәге хәлифәсе, нәрсә дигән сүзе менә бу дөньяны Аллаһ Тәгалә яраткан, дөньясы Аллаһныкы, бар Әдәм баласы шушында. Мин кушкан эшләрне эшлә, мин кушканча эшлә. Бөтен мөмкинлекләрен Аллаһ Раббуль Гыйззә бар иткән, квартирага ордер биргән шикеллек. Шушы дөньяда яшәгән вакытында, бәхеткә, тынычлык-иминлеккә Әдәм баласы Аллаһның хәлифәсе иттереп яшәсә генә җитешә ала. Әгәр дә, мин бу дөньяда хуҗа диеп, күкрәген киереп, оятсызланып, азгынланып йөри торган булса, ул вакытта бөтен җир йөзендә нәрсә генә кала? Үләксә базы да, мусорный свалкалар кала бөтен төштә. Менә дигән урман, менә җәй буена урманнарга чыгабыз, бөтен дөнья чыга,

коенырга да, кызынырга да, җиләгенә дә, җимешенә дә, теләсә ни эшләргә, анысына гына түгел. Бөтен кибетнең чишаларын җыештырып, анда кинәнеп һавасын сулар урнына, рәхәтләнеп шунда карап моңланып, зарланып, гыйбәдәтләрен кылып, сокланып, йөрәгенә дә, җанына да азык алып кайтыр урнына, доң-доң бер берсенең артыннан чишаларны эчә-эчә, аннары дуңгыз булып аунап, аннары шул чишаларга атып, йә аларны тетеп, аннан соң барып кара син ул урынга! Ул тетелгән, ватылган чишалар, ул балаларың шунарга барып кадалмас өчен үлән астында ул чиша төбләре ята. Йә анда тутырган, йә монда тутырган, **кәкәйләрен** итеп куйган, нинди ул. Бу да Әдәм баласы, бу да Аллаһның хәлифәсе, ләкин ул, үзен хуҗа иттереп саный. Бөтен дөньясының да, үзенең өенекен генә түгел, үзенең ишек аллары, үзенең йортлары быкырдык, мусорный яшеккә әйләнгәнлекләр генә түгел, урманнарында, **кырларында бөтен дөньны да, бер быкырдык оясына** , хурлык оясына, бер кем дә, хәттә үзенең баласы да аннан соң баргачтын шуннан ләззәт, рәхәт тапмаслык иттерә. Матур җилләр искән вакытта, шунда кошлар сайрап торган вакытында, шул пыяласына, чишасына китереп бассаң, күренәме ул кошларның сайраганы. Йә шул ук тәмәкеләрен тартып, учакларын ягып меңләгән-меңләгән гектар урманнар яна. Ел саен, илебездә дә, дөньяда да. Кемнәр яндырганын белә торып яндырганнары да бар. Икенчесе исереп, өченчесе исе дә китмичә шунда ташлады да, ә йорт салыр өчен 5-10 куба метр урман алырга мең бәла кирәк, мең рөхсәт кирәк. Тагансызлык аркасында Әдәм балалары исәпләмәгәннәре аркасында күпме урманнар, күпме хайваннар тилмергәннәре, болар гонаһ түгел мени? Дуңгызны ашау, аракы эчү генә гонаһ мени, болар гонаһ түгел мени? Белергә тиеш һәр бер бәндә, менә хәттә тәхәрәт алган вакытыбызда да, шуның чамасы да чамаланган, бер комган. Бер тәхәрәтне 3 комган белән алган булсаң исраф кылганың өчен гонаһлы буласың. Диңгезләр була торган булса да, дәрьяләр, күлләр була торган булса да, исраф кылганың өчен, тәхәрәт алган вакытыңда да гонаһлы булуың мөмкин. Шуның шикелле ук Аллаһ яраткан дөньясын быкырдатып, мин торган булса, синнән соң быкырдык кына тетә торган булсаң, һич чиксез гонаһы җыясың. Һәм Аллаһ хозурында аның өчен дә Әдәм баласына һич чиксез хисабы бар. Хәлифә булырга тиешле Аллаһның җир йөзендәге хәлифәсе булса, Әдәм баласы шул вакытында ул дөньясында ук сәләмгә ирешкән, иминлеккә, тынычлыкка ирешкән. Болар да бөтенесе Аллаһның “Әс-Сәләм” исеме бәрәкәтендә. **Аллаһтан башка тагын тәңрегез бар дип уйларсызмы?** Сез быкырдатканны тагын берсе җыештырып йөрүче бар дип уйлыйсызмы? Әз генә Әдәм балалары исәпкә төшерерләр.

**Җир йөзенең караңгылыкларын да, диңгезләрнең караңгылыкларын да сезгә юлларын күрсәтүче кем? Шатлык-рәхмәтләре килер алдыннан шатлык иттереп җилләрне истерүче кем? Аллаһ Раббыгыз белән тагын бер тәңре бар дип уйлыйсызмы? Аллаһ Раббыгыз өстен Ул, Анарга ширк табып азапланганнардан өстен Аллаһ Раббыгыз.** Аллаһ Раббуль Гыйззә боларын да искә төшерә. Ярыймы, хәзер кнопкага гына бастың да включательга уты да янды, чәйне дә төрттең дә розеткасына кайнап та тора. Аларның юк вакыты да бар иде, болар да юк булыуы мөмкин бер көндә, бер минутында. Илнең кайсы гына почмагында, йә газы сүндерелә, йә электричествосы сүндерелә, болар да вакытлы иде. Дингездә дә, җирнең караңгылыкларында да сезгә юлны да күрсәтүче, курыкмый аптырамаслык итеп йөрүче дә. Ул җилне дә үзенең рәхмәте иттереп яудыручы, шатлык-куанычны сезгә килүче, хәбәр итүче Аллаһ Раббыгыз белән тагын нинди тәңреләрегез бар ди. Әле без, йөдә үскән гөлләргә дә су сибәргә онытабыз, әз түгел корып кала, әгәр дә шушы икмәк, игеннәрнең һәр бөртегенә килеп аталандырырга, шул җил белән аталана. Хөрмә агачына, хөрмә агачының ата агачы, ана агачы бар. Ата агачыннан чәчәкләрендә булган тузаннарын җыеп пумала белән ана агачына менеп шуңа сибәргә кирәк. Шунсыз хөрмә

житешеп бетми. Җилнең анда сирәккә булганлыгыннан, ә игеннәргә дә шулай булса иде, йә бал кортлары, йә җилләр белән аталана торган булса иде ни ашар идек? Берәмтекләп һәр кайсына йөрерлек иттерсә Аллаһ Раббуль Гыйззә ансысын да үзе булдыра.
**Әллә ул юктан бар итүче, юктан бар итеп. Аннары туфракка кергәннән соң да яңадан сезне бар иткән, күктән дә, җирдән дә сезне ризыкландырган Аллаһ Раббуль Гыйззә белән тагын тәңре бармы? Әйт йә Хәбибем Мухәммәд Мостафа с.г.в. китерегез дәлилләрегезне, әгәр үзегезнең даиминнәрегезне дөрес дисәгез** дип әйт. **Әйт йә Хәбибем Мухәммәд Мостафа с.г.в. күкләрдә, җирләрдә булганнар да Аллаһтан башка гаепне белмәс**. **Кайчан, ничек иттереп кубаруын да сизмәсләр**. **Бәлки аларның кыямәтнең булыуын да һаман да дәресләргә, җәннәтләргә ирешү әле булу булмасында, аларның ышанычы юк, шикләре олы. Бәлки алар әхирәт хакында, үлгәннән соң да, яңадан терелү хакында, яңа тормыш хакында, сукырлар алар ди Аллаһ Раббуль Гыйззә.** Аллаһ үзе сакласын. Таха сүрәсендә Аллаһ әйтә болай: Бөтенесе, тынычлык Аллаһның Әс-Сәлам исеменнән.
**Кемгә ул тынычлык-иминлек? Әс-Сәлам булган Аллаһтан булган тынычлык. Һидәяткә күнгәннәргә, хак юлга күнгәннәргә, Аллаһ Раббыгызның хәлифәсе булып яшәргә омтылган бәндәләргә Аллаһтан тынычлык.**
**Менә бу юл Раббың Аллаһның юлы туры итеп бер ителгән юл. Дөреслектә без исәпләтә торган акыл, эшләтә торган белгән кешеләргә, бөтен гәләмәтләрне бәйнә-бәйнә иттереп аңлатык, Аларга Аллаһ Раббыгызның хозурында мәңгелектә тынычлык-иминлектә йөртеп, җәннәтләре булачак аларның кылган гәләмнәренә карата Аллаһ Раббыгыз аларның дусты да, аларны ташламас**. Алай булган вакытта Аллаһ Раббыгыздан тынычлык-иминлек, һәр вакытта анардан гына. Ул тынычлык-иминлек тә дөньяда да кирәк, мәңгелектә дә кирәк. Шуннан да Аллаһтан сораган вакытта
**Йә, Раббыгыз Аллаһ тыныч , рәхәт тормышларны бу дөньяда да мәңгелектә дә бирсәң иде, уттан да коткарсаң иде**. Бу дөнья да газапланмыйча, көннәребез тынычлыкта үткәрәсе килә, чөнки көн шикеллек ачык беләбез. Ашаган кашыкларың алтын, табакларың алтын да булса да, сау-сәламәт бөтен гәүдәң булса да, алтын, патша сарайларында тора торган булса да, күңелендә тынычлык бер көн генә булмый тора торган булса, бөтенесен онытасың, берсесе дә күзеңә күренмәс була торган була, юк кына бер борчыу, әллә кайда дөньяның икенче ягында бер дустыңмы, яки балаңмы, оныгыңмы, туганыңмы бер кайгы-хәсрәтен ишетсәң генә дә, шуңарга күрә дә ул тынычлык иминлекне Аллаһ Раббыгыздан дөнья, әхирәттә дә телибез, дөнья-әхирәтнең тынычлыгын да бирүче Ул Аллаһ.
Намазны укып бетергән чагыбызда да, намаздан чыгу иттереп Аллаһ шушыны куйды, намазны укып бетердек:ике рәкәгәтме, өчме, дүртме Сәламугалейкум вә рахматуллаһ Сәламу галейкум вә рахматуллаһ дибез. Аллаһның рәхмәте сәламдә уң якка булса иде, уң як фәрештәгә дә ният итергә тиешле. Намазда синең уң ягында кем бар, кешеме, хайванмы, үсемлекме, мәчетнең уң ягында кем бар, бөтенесенә минем сәлам, аннан соң сул якка бирәбез. Телибез шул вакытта, күңелебездә ният булырга тиешле, мин намазны укып бетердем Аллаһка шөкер, миграҗым булды Аллаһка шөкер, Аллаһның рәхмәте дә, минем сәламнәрем дә, тынычлык-иминлек тә бөтен дөньяга җәелсә иде. Уңга-суңга, бөтен дөнья тыныч-имин булмаса, синң тыныч-имин яши алмайсың, ләкин ул тынычлык-иминлек тә бездән түгел, без аны булдыра алмыйбыз, без аны сакларга тырышывыбыз мөмкин, без аны бергәләп җәергә тырышывыбыз мөмкин, ләкин чын тынычлык Аллаһтан, Аллаһның Әс-Салэм сыйфатыннан, шуңа күрә дә, кулларыбызны күтәрәбез дә.

**اَللَّهُمَّ أَنْتَ السَّلَامُ وَمِنْكَ السَّلَامُ تَبَارَكْتَ يَا ذَا الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ**

**Йә, Раббым Аллаһ, тынычлык-иминлек синң Үзең, синнән генә тынычлык иминлек, өстен Сиң, йә Раббым Аллаһ.** Шушы җирдә Тынычлык-иминлек булуларын да насыйп итсәң иде дип, менә шушы бәрәкәтендә балаларыбыз Әлһәмдулилләһ, бөтен дөньяга тынычлык-иминлек бәрәкәт төшә. Шуларны без мәчетебездә, өйләребездә намаз укыган вакытларыбызда, һәр вакыт телибез Аллаһ Раббыдан, һәр чагында да кабул да әйләсә иде, ә әгәр дә без намазларны укып, шушы догаларны укып, Әсәламугалекум вә рахмателлаһи вә бәрәкәтух диеп мәчеттән чыгуга башладык исә, бар андый мәчетләрдә. Менә китергән намазлык кайда, фәлән садакалар кайда, фәлән нәрсәсе булды, йә юк бер нәрсә өчен бер-берсе белән сугышып яткан, мәчетләр дә бар, җәмәгатләр дә бар, йортыбызда тынычлык бәрәкәте килеп китә торган булса, юк-бар нәрсә өчен ул тынычлык-иминлекне тетә торган булсак, ул вакытта намазларыбыз да, укыган догаларыбыз да, биргән сәламнәребез дә, бөтенесе буш кебек.

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم : **الْمُسْلِمُ مَنْ سَلِمَ الْمُسْلِمُونَ مِنْ لِسَانِهِ وَيَدِهِ.**

**Мөселман шул, аның теленнән дә, аның кулыннын да башкалар имин булган** ди Пәйгәмбәребеә Мухәммәд Мустафа с.г.в.: Бер кемгә дә кулы белән дә, теле белән дә рәнҗү китермәскә тырышкан кеше, Аллаһтан булган сәламне шушылай иттереп ирешергә тырышкан кеше шунарга күрә дә, юлыккан вакытыбызда да безнең бер беребезгә биргән нәрсәбез бар Сәламугалейкум вә рахматуллаһ, үәгәләйкум әссәлам вә раһматуллаһ, исәнмесез дип түгел. Бер көнне мин шалтыраткан идем бер абзыйның өенә, үзе юк иде, абыстае алды телефонны, каушап калдым, бабаем юк, абыстае гына, хатын-кыз белән сөйләшеп утырасы да юк, алай да Сәлам бирү урынына бүтән сүз ычкынды телемнән. Исәнмесез дип андый бабай бармы? Исәнбез ди. Җавапны шулай дип бирде. Исәнмесез дигән сүз, әле үлмәдегез мени, әле дә тере мени дигән сүз булып чыкты. Мин каушап калып әйттем, шуңа күрә исәнме сез диеп түгел, здравствуйте диеп кенә дә түгел, здравствйтены да әйтеп була, гел яшә, исән бул диеп, дога иттереп тә кулланып була, ләкин бездә, Аллаһның өйрәткәне, Пәйгәмбәребез с.г.в.нең өйрәткәне. Сәламу галейкум вә рахматуллаһ. Кайда гына барып керсәң дә, кемнең генә арасына барып керә торган булсаң да Сәламугалейкум вә рахматуллаһу вә бәрәкәтуху Аллаһның рәхмәте сәламы булсын сезгә, бу кешегә кем булса да, зыян китерергә батырчылык итеүе мөмкинме? Аллаһтан да, үзеннән дә, анарга сәлам биргән чагында, һичшиксез Үәгәләйкум әссәлм вә рахматуллахи вә бәрәкәтух дип анарга җавап әйттерәчәк Аллаһ Раббуль Гыйззә. Пәйгәмбәребез Мухәммәд Мустафа с.г.в. әйтә: **Өйләрегезгә барып кергән чакта да, чит кешенең өенә барып кергән вакытта да, беркем булмый торган булса да, йортыбызга кайтканда, сәламу гәләйкум вә рахматуллаһ диеп сәлам бирегез** ди.

Шул Аллаһның **Әс-Сәлам** исеменнән ул йортка бәрәкәт иңә торган була, сәлам белән тула ул йорт. Аллаһның рәхмәт фәрештәләре шуны тутыра торган була, шуның өчен без бу саләмне беркайчан да кызганмаска тырышмаска тиешле. Тынычлык-иминлек тә, просто тыныч кына түгел, карның ач булса ничек тыныч була аласың, чыгасың, эзлисең, йә артык булса, кайда барып бушатырга белмисең, анда да тыныч була алмыйсың, шуның өчен сәлам дигән сүз, бөтен ягыңнан, күңелең дә, тәнең дә, бөтенесе тыныч, синең тирәдәге балаларың да, гаилән дә илең дә, бөтен дөнья да тыныч, шул вакытта Әдәм баласы, чын бәхеткә ирешә торган була.

Сәлам дигән сүз Аллаһның исеме, سَلِمَ -يَسْلِمُ дигән сүздән чыга. Аллаһның Сәлам дигән сүзе, исеме сыйфаты**, бөтен бәндәләр, бөтен мәхлүкләр, хайваннар, үсемлекләр, бөтен дөньясына тынычлык-иминлекне җәеүче һәм Үзе, бөтен кимчелекләрдән, гәепләрдән, юк булудан да тап булган Аллаһ** дигән сүз. Бу Аллаһның әс-Сәлам дигән исемендә Аллаһка ялварган вакытыбызда, **йә Сәламу**, **йә Аллаһ** дисәң дә була, **Йә**

**Сәламу Йә Джәлләлүһ** дисәк тә була. Дүрт хәрефтән тора: س -**“Син”** хәрефенең саны **60**, ل -**“Ләм”**неке **30**, ا - **“Әлиф”**неке **1**, م - **“Мим”** неке **40**, шуның белән **131** була.
Шушы Әс-Сәламу диеп Аллаһне искә алуның фазиләтләре турында китапларда күрәбез, ап-пак кәгаздә Аллаһның бу исемен язып янында йөртә торган булса бу бәндә Инша Аллаһ һич беркайчан бәла-хәсрәт күрмәс ди. Янында, кесәсендәме йөртә торган булса, шушы Аллаһның Йә Сәламу диеп зикрен берәү теленнән төшермичә һәр вакытта әйтә торган булса, бигрәк тә таң аткан вакытта, кояш баеган чакларында бу бәндәгә Аллаһ Раббуль Гыйззә бәла-хәсрәт күрсәтмәс, шулардан бөтенесеннән имин булыр ди. Шуның тагын таблицасын язу да, **уифк** дип атала, саннары белән язылган вакытта тулы ихтикат белән шуны янында йөрткән чагында берәү монарга ук белән ата торган булса, йә пычак казамакчы булса да, Аллаһ Тәгалә казаттырмас анарга моны ди. Аллаһның Сәлам исеменең бәрәкәтендә.
Өченчесе кайбер китапларда языла, Аллаһның бу йә Сәлам дигән исемен 160 тапкыр **берщү** ауруның янында укып, аңарга әйтә торган булса Аллаһның кушуы белән Аллаһның исеме белән бу ауруга шифасын да табыр ди, бигрәк тә күңел ауруларыннан, моның догасы да бар.
**اللَّهُمَّ سَلِّمْنِي فِي خَوَاطِرِ النَّفْسَنِيَّةِ وَأَحْيِ قَلْبِي بِدُونِ مَعْرِفَتِكَ الْقُدُسِيَّةِ وَ سَلِّمْنِي الْقُدُورَاتِظُّلُّمَنِيَّةَ وَالرُّعُونَاتِ النَّفْسَنِيَّةَ وَجَنِّبْنِي كُلَّ مَكْرُوهٍ وَأَنِلْنِي كُلَّ رَفْعَةٍ وَاكْشَفْ يَا قُدُّوسُ يَا سَلَامُ يَا مُؤْمِنُ يَا مُهَيْمِنُ وَمَكِّنِي نَاصِيَةَ الْمَلَكِ الْخَادِمِ بَعْطَايِيل وَاكْشِفْ بَيْنِي وَبَيْنَهُ الْ حِجَابَ وَاقْضِ الْحَوَائِجَ بِحَقِّ اسْمِكَ السَّلَامِ.**
**Йә, Раббым Аллаһ, күңелемнең хәтәлләреннән Үзең мине сакласаң иде, күңелемне, изге тану белән тану йә, Раббым Аллаһ, терелеү бирсәң иде, күңел караңгылыкларыннан да, бөтен начарлыклардан читләштерсәң иде, өстен дәрәҗәләргә йә, Раббым Аллаһ, ирештерсәң иде. Йә Куддус, Йә Аллаһ Раббым, изге Раббым, тынычлык-иминлек анардан булган Раббым, үзеңдә хезмәттә булган Багтаил фәрештәсенә дә хезмәтенә йә, Раббым Аллаһ, аның маңгаен миңа ия иттереп булуын насыйп итсәң иде ди. Ул хезмәт итерлек булса иде ди, аның белән минем арадагы пәрдәләрне ачсаң иде. Үзеңнең Сәлам исемеңнең бәрәкәтендә йә Раббым Аллаһ, хәҗәтләремне үтәсәң иде** ди Пәйгәмбәр с.г.в.
Боларда кайсе берселәренең шикләнеүе мөмкин, кайдан килгән бу доганы кем уйлап чыгарган, ничек алай иттереп булыр дип. Карыйбыз Пәйгәмбәребез Мухәммәд с.г.в.нең хәдис шәрифенә.
قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: **نْمَ قَالَ حِينَ يُصْبِحُ ثَلَاثَ مَرَّاتٍ أَعُوذُ بِاللهِ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ثُمَّ قَرَأَ ثَلَاثَةَ آيَاتٍ مِنْ آخِرِ سُورَةِ الْحَشْرِ وَكَّلَ اللهُ بِهِ سَبْعِينَ أَلْفَ مَلَكٍ يُصَلُّونَ عَلَيْهِ حَتَّى يُمْسِيَ وَإِنْ مَاتَ فِي ذَلِكَ الْيَوْمِ مَاتَ شَهِيدًا وَمَنْ قَلَعَ حِينَ يُمْسِكَ النَّبِيُّ تِلْكَ الْمَنْزِلَ.** رَوَاهُ الترمذي
**Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә: Кем таң аткан вакытта уянгач дисә, ишетүче, белеүче Аллаһы насыбыннан, рәхмәтеннән таш белән сөрелгән шайтанның явызлыгыннан дип, өч тапкыр әйтеп, аннан соң Хәшер сүрәсенең ахырыннан өч аятне укый торган булса, Аллаһ Тәгалә бу бәндәгә җитмеш фәрештшәсен яратыр, болар анарга кояш батканчыга кадәр, бу бәндә шул көнне әҗәле җитеп дөньядан китә торган булса, шәһид булып дөньядан китер ди. Шәһид дигән сүз кыямәт көнендә гәмәлләре үлчәнеп тә тормый, бар җәннәткә дип Аллаһ кертә торган була. Кем шуны кояш баер алдыннан дип өч тапкыр догасын укып аннары Хәшер сүрәсенең ахырында Аллаһның менә бу Әс-Сәлам дигән исемен дә аның эчендә булган, Ләә Ястәвидән башлап. Шуны кем укыган булса шул ук дәрәҗәгә Аллаһ Тәгалә бу бәндәгә насыйп итәчәк** дип Пәйгәмбәребез әйтә. Имам Термизи риваят итә. Менә шушылай булган вакытта Аллаһның бу исеме **Әс-Сәлам** дигән исеме тормышыбызның һәр бер елы гына түгел, һәр бер көне генә түгел, һәр минутыбыз белән багланган исем. Шуның өчен дә Аллаһның бу исемен санынча **131** тапкыр да, бәлки артыгын да, кимен дә һәр вакытта искә алып, бер беребезгә сәлам биргән вакытта да, бигрәк тә

балаларыбызга йөрәтеп, сәлам биргән чагыбызда да Аллаһның шушы исеме искә алынган булган була, күңелебездә тынычлык, гаиләләребездә тынычлык иминлек, бәрәкәт артуында да, мәңгелектә дә Аллаһның җәннәтләренә дә ирешеүенә анда да тыныч-имин булуыбызга Инша Аллаһ сәбәп булачак.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якыннардан сәяду җомгаларны хормәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем

Ерак, якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

*7 –нче ВӘГАЗ*

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## *АЛЛАҺНЫҢ* ӘЛ- МУЪМИН *ДИГӘН ИСЕМЕ*

Аллаһның **Әл-Муъмин** дигән исеме Көръән Кәримдә ни бары бер тапкыр гына килә. Алдан булган исемнәрне күргән идек Көръән Кәримнең төрле сүрәләрендә килә иде, кайсысы бер-ике сүрәдә. Әл-Муъмин дигән Аллаһның исеме **лә ястәвинең** үзендә соңында дигән аят кәримәдә егерме өченче аят була.

**Ул Аллаһ Раббыгыз шундый зат була, аңардан башка тәңре юк, ялгыз үзе, Ул хуҗа да Әл-Мәлик, Әл-Куддус – изге дә Ул, Әс-Сәлам тынычлык-иминлек тә Анардан. Әл-Муъмин иманлы, Әл-Муһәймин - һәр нигә өстен булучы, гыйззәт һәм кодрәтендә өстен булган, явызлыкны җәберлекне туктатучы, Әл-Мутәкәббир өстен Ул Аллаһ Раббыгыз дип Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә Аллаһ Раббыгыз анарга күпме тиңдәшләрне табырга маташа торган булсалар да, күпме кимчелекләрне, быкырдыкларны табарга маташа торган булсалар да Аллаһ Раббыгыз монардан барысыннан да пак** ди.

Менә бу аят кәримәдә дә Әл-иман дигән сүзләрдән алынган, Муъмин беләбез мъмин - мөселман ышанган кеше дигән сүз була, инанган дигән сүз була, шуның **исму фәгыйле** була эшләүчесе, үтәүчесе. Русчасында иман дигән сүзнең мәгънәсе верить, уверовать, обеспечивать безопасность дигән сүз иде. Алай булган вакытта Әл-Муъмин дигән сүз аның мәгънәсе уверовавший, верующий, обеспечивающий безопасность дигән була торган була иминлек бирүче дигән сүз була. Асылы исә иман дигән сүз ул да **ифгәлдән** алынган булып асыл моның төзелеше **аманат** һәм әменнән асылы алынган, аманат дигән сүзне беләбез аның фыйгеле **امن - әмәнә, يؤمن - йәъмәнү** була быть верным надежным, честным дигән сүз, ышанычлы булу һәр вакытта имин булу шушысы Әл-Әмәнә Әл-Әменнән алынган булса әмәнә, йәъмәнү быть безопасным, благополучным, быть уверенным, доверять дигән сүз була. Шуның өчен дә аның исеменнән дә Әмин дә килә әмән дә килә алай булган вакытта Әл-Муъмин дигән сүз бәндәләр хакында була торган булса инаныр өчен, ышанган, Аллаһның берлеген таныган иманлы бәндә дигән сүз була Аллаһ Раббыбыз хакында Әл-Муъмин дигән сүзнең исеменең мәгънәсе дә, тынычлык-иминлекне дә бирүче, ныклыкны да күрәбез. Аллаһ Раббыбыз хакында алай булган вакытта

**أَيْ الَّذِي أَمَنَ أَوْلِيَاءَهُ عَذَابَهُ وَ الَّذِي يُصَدِّقُ عِبَادَهُ مَا وَعَدَهُمْ.**

**Тынычлык-иминлекне дә Ул бирүче һәм үзенә дус булган Аллаһка дус булырга омтылган бәндәләргә, дусларына Аллаһ Раббуль Гыйззә газабын тидермәүче газабында саклаучы һәм бәндәләрне вәгдә иткәннәрне, урынына җиткереп үтәүче, биргән вәгдәсен дә тотучы** дигән сүз була.

و قال الضحاك عن ابن عباس: **أَيْ أَمَنَ خَلْقَهُ مِنْ أَنْ يَظْلِمَهُمْ.**

Тәфсир гәлимнәреннән Дахак Хәзрәтләре Абдуллаһ ибне Аббас р.г. риваят итеп әйтә: **үзенең халкына хаксыздан рәнҗетүдән иминлек бирүче** ди тиешсезгә беркемгә дә Аллаһ Тәгалә бәла-хәсрәтен дә, мәшәкатен дә авырлыгын да бирми тик томалга бер кемгә дә булмай.

و قال قتاده: **أَمَنَ بِقَوْلِهِ أَنَّهُ الْحَقُّ.**
Катада Хәзрәтләре әйтә Аллаһ Раббуль Гыйззә хак дигән сүз.
و قال ابن يزيد: **صَدَّقَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ فِي إِيمَانِهِمْ.**
Бу да тәфсир галимнәреннән Муъмин дигән сүзе Аллаһның **Муъмин** дигән исеме **бәндәләрнең иманнарын дөрескә чыгаручы,** без ышандык дип әйтәбез Аллаһның Әл-Муъмин дигән исеме ул вакытында бәндәләрнең иманнарын дөресләүче дигән сүз була.
Көръзн Кәримдә аерым бер сүрә бар **Әл-Муъмин** дип атала **Гафир** дип тә атала бу сүрә ул да шушы ук исем белән аталган Пәйгәмбәребез с.г.в. бу хәдис шәрифендә әйтә.
قال رسول الله صلى الله عليه وسلم : **مَنْ قَرَأَ آيَةَ الْكُرْسِيِّ وَأَوَّلَ حم الْمُؤْمِنِ عُصِمَ تِلْكَ الْيَوْمَ مِنْ كُلِّ سُوءٍ.** عن ابي سلمة وابي هريرة.
Расүл Әкрам с.г.в. әйтә **кем Аятел Көрси һәм “Хә” “Мим” Муъмин аятне укый торган булса ул көндә Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәгә бөтен бәндәләрдән кимчелек хаталардан гонаһлардан саклый** ди, пәрдә булачак ди. Иртәннән Аятел Көрси белән Әл-Муъмин башындагы бер аятен булса да укыса Абу Сәламә һәм Абу Хурайра р.г.дән риваят ителә бу хәдис шәриф. Яңадан да бу сүрәнең башында булган без Аллаһның Әл-Муъмин дигән исемен аңларга тырышабыз.
**“Ха” “Мим” ике хәреф, болардан кем икәнлеген Аллаһ Раббуль Гыйззә үзе белеүче**, ләкин кайбер галимнәр бу да Аллаһның исемнәре диләр шуның өчен дә бу. Аерым сүзләр белән хәрефләр белән башланган сүрәләрне саклар өчен галимнәр киңәш иткән. **Менә бу Көръән Кәрим көчендә күәтендә кодрәтендә өстен булган гыйззәтле эч-тышыгызны белеүче Аллаһ Раббыгызның иңдергән Көръән Кәриме бәндәләрнең гонаһларын гафу итүче, тәүбәләрен кабул итүче, шелтәсен дә каты булган, өстенлеккә ия булган һәр нәрсәнең өстенә өстен булган Аннан башка һич бер тәңре булмаган Аллаһ Раббыгыз иңдергән Көръән Кәриме. Кайту да Анарга. Аллаһның аятләре хакында, Аллаһның галәмнәре хакында, тик көфердә булганнар гына тарткалашырлар. Иманлы кеше Аллаһның гәләмнәре аятләре хакында бер вакытта да тарткалашмас. Йә Хәбибем Мухаммад с.г.в. Аллаһның аятләре хакында тарткалашып ышанмыйча**, ул Таурат, Забур, Инҗил хакында гына түгел дөньяның төзелеше дә аятләр һәр бер яфрагы да, һәр бер агачы да һәрбер хайваны да Аллаһның гәләмәтләре Көръәндә, Тауратта, Забурда, Инҗилдә без Аллаһның аятләрен, гәләмәтләрен карай торган булсак, язылган иттереп дөньясын да күрәбез күзләребез белән Аллаһның аятләре хакында тарткалашучылар иркеннәп дөньяда уңнарга-суңнарга йөри торган булсалар. Йә, Хәбибем Мухәммәд Мустафа с.г.в. аптырама анарга. **Алардан элек Нух г.с.нең халкы да ялганга тотканнар иде Аллаһның аятләрен алардан соң төркемнәр дә төрле-төрле партия булган, төрле төрле төркемнәрдә Аллаһның гәләмәтләрен яланга тотканнар иде, үзләренең пәйгәмбәрләрен хур итергә. Аны тотыр өчен, аны хур итер өчен һәм бәтил белән тарткалашканнар иде хакны шуның белән хур итер өчен, аны тетер өчен. Мин аларны тоттым. Минем тотыуым ничек булды ди Аллаһ Раббуль Гыйззә** Нух г.с. ни эшләткәннәрне дә әйтеп утырмый бөтен дөнья белә иманлысы да, имансызы да мөселманы да, хрестияны да, яхуды да, башкасы да бөтен халыкларның тарихында җир йөзендә су басуы, туфан булганлыгы билгеле Аллаһ Раббуль Гыйззә ул ялганлыкка тотканнарны да ничек иттереп тоттым, минем илчеләремә карышкан булсалар, аларга минем шелтәм нинди булды.
**Менә шулай итеп Раббым Аллаһның сүзе көфердә, динсезлектә булганнарга өстен булдылар утта әһеле булачак утка барып керәчәк урыннары булачак ди** Аллаһ Раббуль Гыйззә кисәтә.
Бу сүрәнең башында Аллаһ Раббуль Гыйззә иманның чынлыгы хакында әйтә торган булса ничек иттереп иман көферлек өстен булуын Аллаһ Раббуль Гыйззә дөнья

ахирәттә икәнлекне искә төшерә торган булса сүрәнең уртасында Аллаһ Раббыгыз болай дип тә куя. Ул Аллаһ Раббыгыз шундый зат ышаныйкмы, ышанмыкмы дип йөри торган булсагыз иман кирәкме, кирәк түгелме диеп йөри торган булсагыз, әлек үткән халыкларның хәлләреннән гыйбрәт алмасагыз Ул Аллаһ Раббыгыз. Менә шушы җирен дә какшатмаслык итеп йөрерлек иттереп сезгзә кылды өстегезгә Аллаһ Раббыгыз күкләрне дә төзеде бина иттереп. Һәм сезгә төс-кыяфәтләрегезне бирде. Аллаһ Раббыгыз сезне татлы ризыклардан да ризыкландырды. Менә Ул Раббыгыз шуны бирүче җирне дә карарлы иттереп, күкләрне дә сәзгә өстегезгә бина кылып, сүрәтләрегезне дә бирүче Ул, сүрәт күркәм итүче. Аллаһ Раббыгыз мөбәрәк зат Ул Ул мәңге терек, гел бар, аннан башка тәңре юк.Анарга ялварыгыз Аңардан дөнья ахирәт хәҗәтләрегезне сорагыз динегезне иманыгызны Анарга чын күңел белән, ихласыгыз белән кылып Әлхәмдүлилләһи Раббил Галямин, чөнки мактау олылау да, шуларның бөтенесен дә бар итүче Аллаһ Раббың ялгыз. Үзеңә берәү сиңа бер чиләк бәрәңге бирсә дә кырык тапкыр рәхмәтләреннне әйтә-әйтә китәсең, яки берәр күчтәнәчме китерсә дә Әдәм баласы белә шунарга рәхмәтен әйтмәсә, хәер догасын кылмаса этлек икәнен. Аллаһ Раббуль Гыйззә бу җирен дә карарлы иттереп яратты, күкләрен дә Аллаһ Раббуль Гыйззә бина иттереп яратты, җир үзе космически ракеталардан да өстен тизерәк оча хаваларда, ләкин без аны сизмибез дә калтыранып калтыранып утырасың ни эшләр икән дип. Анда да шулай, ләкин ни файдасын бирә инде, ә җир йөзендә йөрибез дә, ятабыз да, кинәнәбез дә, гәмәл-гыйбадәтен дә кылабыз бер нинди аркан белән кую да юк, хайванны җибәргән чакта йә тышаулыйсың, йә арканга куя торган буласың күктә күпме әле метиоритлар башкалары да төшкәне юк вакытында да берсе дә, бик сирәк кенә җиргә килеп җитә торган була чөнки Аллаһ Раббуль Гыйззә шундый җир йөзен шул кадәр катлар белән катлап куйган килеп төшкән вакытында ул метиоритлары янып төшә торган була, күзгә теге йолдыз төшкән иттереп күренә, бушлык анда була торган була да Аллаһ Раббуль Гыйззә безгә суларлык иттереп шушы җир тирәсендә һаваларын яраткан, күрәсез космонафтлар очкан вакытында да скафандрларын,башкаларын кия, шуның тамчы гына ярыгы була торган булса ике минут та **ялмый,** җаны чыга торган була Аллаһ Раббуль Гыйззә ул күкне дә бина иттереп анардан гына түгел үзеңнен генә түбәң капланмаган булсада, әллә ни кадәр яхшы йортың бөтен җихазлаган, бөтен мебел фәләннәрең бер җирендә тишеге була торган булса яңгыр яуган саен шуннан ага торган булса күңелең рәхәт түгел ничек иттереп ямарга, ничек иттереп төзәтергә белмисең Аллаһ Раббуль Гыйззә бу күген дә, иң күркәм сыйфатында ятатып кояшын, нурлар да эссе мәле дә чамасы белән генә җитерлек иттереп Аллаһ Раббуль Гыйззә яратты тагын да сезгә сүрәтегезне. Ул Аллаһ Раббыгыз бирде ди алты миллиардтан артык кеше була торган булса бөтенесенең аерым үзенеке, матурмы, матур түгелме. Әдәм баласы булгач бик матур искиткеч гүзәл. Әгәр дә бөтенебез бер төстән, чиләкләрне ничек штамповат итеп чыгаралар шулай чыга торган булса бөтен кеше, бер төсеннән, кайдан бер беребезне таныр идек, озыннык та киңлегебез дә, кашларыбыз да, борыннырыбыз да төрлелек булмый тора торган булса, бер ата анадан туган выкытында да бөтенесе искиткеч төрендә бар. Атасыннан да бар беразы, анасыннан да бар, җиде буынга кадәр ошауы мөмкин дигән Пәйгәмбәребез с.г.в. дә әйткән иде. Паспортымны чыгарып күрсәткәнче, кем икәнеңне әйткәнче үк йөзеңнән ата-анаң да, дусларың да таный. Аерым иттереп хөрмәтләп Аллаһ Раббуль Гыйззә кемгә үзенең төсен, сүрәтен биргән шуның өчен. Ул төсегезне дә, кыяфәтегезне дә Аллаһы Тәгалә күркәм кылды ди, бер кемнең дә йөзе ямсез түгел Аллаһ Раббуль Гыйззә Үзе биргән йөз, берәү шунардан кимчелек табып борының тегеләй, күзең болай, авызың болай дип гаеп итә торган булса.

Аллаһтан гаеп кимчелек эзләргә газапланган була һәм Аллаһ каршында шуның өчен дә

гонаһлы була. Һәм иң хуш ризыклардан да Аллаһ Раббыгыз сезне ризыкландыручы, берәүләр әйтүе мөмкин үзебез сукалыйбыз, үзебез чәчәбез, үзебез урабыз. Ләкин бүген бик күп кешеләр бизнес белән шөгелләнә, тегендә-монда завод фабрикаларда да урыны да кирәк,бинасы да кирәк, станоклары да кирәк шуларны бөтенесен эшләрлек иттереп Аллаһ Раббуль Гыйззә кул - аякларыңны да бирүче, бөтен компютерлардан өстен булган зиһенеңне дә бирүче, акылыңны да бирүче, шуларны барысын чамалап үлчәп тә бирүче Аллаһ Раббуль Гыйззә түгелме? Һич чиксез Аллаһ Раббыбызның күәте белән Ул ризыкларны без табабыз әле эзләгәннән соң да, пешкәннән соң да авызыңа кабып чәйнәгәннән соң да, пешкәннән соң да, йотыр өчен Аллаһтан күәт кирәк иде. Әзме ризыкны йота алмыйча, йоткан вакытында тыгылып калып дөньядан киткәннәр шуның өчен дә ризыкландыручы да Аллаһ Раббуль Гыйззә Сүрәнең азагында Аллаһ Раббуль Гыйззә болай ди.
Йормәделәрме Әдәм балалары ышану кирәкмикән, иман кирәк микән Аллаһ бар микән юк микән диеп аптыраучалар, алар җир йөзендә йөрмәделәрме, йөрсәләр карарлар иде алардан элек Аллаһның сүзләрен ялганга тотканнарны хәле булганын ди.
Әгәр үзенең авылында үз бакчасында, яки абзарыңда гына кайнап йөреп сыерның, сарыкның тизәкләреннән башканы күрмәгән булса дөньяны карап карасын элеккеләр ничек яшәде башкалар ничек иттереп яши Аллаһтан башка бу дөньяда төзеклек булуы мөмкинме.
Сездән элек булган халыклар күберәк тә көчлеләр дә, күәтлерәк тә иде җир йөзендә әсәрләрен дә күберәк калдырганнар иде, ләкин аларның бөтен булдырганнары, кәсип иткәннәре аларга файда итә алмады.
Аларга Аллаһның илчеләре килгән чакта ак-караны аерырлык, хәрам-хәләлне аерырлык туктагыз бу вакытлы гына тормыш бу якын тормыш, дөнья тормышы бер көн Аллаһның хозурларына кайтачакларыгыз бар аның хозурында да хисабы бар боларның барысын юктан бар итүче Аллаһның хак илчеләре килгән вакытында.
Дөньядан белгәннәре, без айларга очабыз, күкләргә очабыз, җир астына төшәбез күпме техника фәләннәребез бар дип куанычлар да. Алар җиңелгә санаган, хурга санаган боларның бөтенесен чорнап алды тирәләрен. Кайчан безнең көч-күәтебезне күрсәләр исә, салган шәһәрләрне дә астын-өстенә китерергә хәлебез җиткәннәрен дә бөтен булганнарны да чәлпәрәмә китерергә көчебез җиткәнгә.
Аллаһның бер үзенә ул генә ышандык инде, бар икән Ул дип әйтер булдылар. **Мине Аллаһка ширк тота торган булсак шуларга кәфер булдык инде, ышанмыйбыз ансына.** Ләкин безнең газабыбызны дөньяга, осләрен кайгыларны яудырганны күргән чактан гына, хәзер ышанабыз инде без Аллаһка дигән сүзләре ул аларга ул иманнары файда бирмәс булды, чөнки Аллаһ Раббыбызның сөннәте Аллаһның куйган гадәте бар, элеккеге үткән җирдә яшәгән халыклар өстенә дә булган иде ул көферлектә булып яшәгәннән соң җир-күкләр селкенгән вакытта гына китергән иман файда итмәс.
Аллаһның газабы килгән вакытта гына иман китерү файда бирмәгәнгә күрә көфердә булганнар алар хәсрәттә калырлар дип Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә. Алай булган вакытта Аллаһ Раббуль Гыйззә элекеге халыкларны да искә төшереүе дөньяларны күрегез менә бүгенге көндә Египеттагы перамидалар гына бар 150шәр метрларга күтәрелгән бер-бер ташлары йөз тонналы ташлар бар ничек күтәргәннәргә, ничек җыйганнар, ничек иттереп өйгәннәр, арасына пычак та кермәслек иттереп дип бөтен дөнья галимнәренең исе китә. Җеннәр булышканмы, үзләренең техникалары булганмы, бүгенге булган техникалар белән дә менә шушы мәчетнең манарасына айны күтәрер өчендә, манараның өстен күтәрер өчен дә кран Башкортостанда ике генә иде утыз биш тоннаны түтәрергә, шунарга күпме кранны көттек кирәк булганлыгына, дөньяда иң булдыклы, иң өстен әйберләр белән дә моннан мең ел элек салынган биналарны тозү мөмкин түгеллеген

галимнәр бүгенге көндә дә әйтәләр. Шуның өчен ул бәндәләрнең кәсиб иткәннәре көч һәм куәтләре Аллаһка карышырлык түгел. Күпме төшләрдә йә җир селкенә башлый, күпме тырышлык белән салынган шәһәрләр тетелеп бетә, меңләгән кешеләр шунда харап була. Йә бер төштә таулар кайный башлый, вулканнар кайный башлый, кем аны каплый ала, тик кырдан күзәтеп торудан башка, тәтенләгән ялкыныннан качудан башка бер ни эшләргә хәле җитми, шуның өчен дә Аллаһ Раббуль Гыйззә иманнарыбызны уята, шуларны да бар итүче сезнең булдырганыгыз белән минем булдырганымны чамалагыз, шул вакытта иманыгыз куәтләнер, шул вакытта иман китерергә, Аллаһка инанырга тиеш икәнлегеңне танырсыз, Мин дә **Әл-Муъмин** иманнарыгызны дөресләрмен ди. Дөресләүе шушы дөньяда күргән-ишеткәннәребез белән һәр көнебездә Әлхәмдүлилләһ иманнарыбыз яңарып тора.

Аллаһ Раббуль Гыйззәнең вәгъдәсе дә бар иманны бәндәләребезне, ул иманны Аллаһ Раббуль Гыйззә чынлыгын насыйп итеүе белән бергә куәт һәм ныклык та Аллаһ Раббуль Гыйззә насыйп итте. Көръән Кәримдә әйтә Ибраһим сүрәсендә. Аллаһ Раббыгыз иманлы бәндәләрне, Аллаһ Раббыларына ышанган бәндәләрене Көръәнне укып дөньяга карап һәрбер яфрагыннан да, хайваныннан да, шаулаган урманнарыннан да, чылтырап аккан чишмәләреннән дә, һәркайсыннан иманы артып куәтләнгән бәндәләрне Аллаһ Раббуль Гыйззә нык сүз белән дөнья тормышында да, ахирәттә дә ныклыкны насыйп итәчәк, ярдәмнәрен насыйп итәчәк ди, дөньяда да, бу бәндәнең куәте дә һичшиксез ташып торачак, Аллаһның хозурына кайткан вакытында да бу бәндә Аллаһ Раббының хозурында.

Раббың кем дигән вакытында да Инша Аллаһ җавап бирәчәк. Тик үз бәхетеннән качканарны зөлемдә булганнарны,Пәйгәмбәрләрне ишетмәдем, китапларны күрмәдем, белмим мин нәрсә дин дип кенә йөреп, күктән яуган яңгырларын да, җирдән кайнап чыккан чишмәләрен дә, шул туфракка төшкән бер бөртек орлыктан күпме икмәкләр үскәнен дә шул бер тамчы орлыгыннан ярты грамм да булмаган алмагач орлыгыннан чиләк-чиләк алмалар пешеп җиткәнен дә бөтенесен күреп тә, бу үзеннән үзе булган дип Аллаһка иман китергән бәндәләрне Аллаһ Раббың саташтырыр, теләгәнен Аллаһ Раббың эшли дә. Бәхетне теләгән бәндәләргә Аллаһ Раббуль Гыйззә иманнарында куәт бирер дөньяда да, ахитрәттә дә, ләкин бәхетеннән качканнарны Аллаһ Раббуль Гыйззә тагын да саташтыра Аллаһ Раббуль Гыйззә шуның өчен дә җөмләбездә иман әһеле булып яшәргә Аллаһның ярдәменә, рәхмәтенә ирешүләребезне гомеребез буена һәм мәңгелектә насыйп итсә иде. Менә бу **Аллаһның Әл-Муъмин** исеменең мәгънәләрен карыйбыз. Шушы исемнең хәрефләре дүртәү; **م - “Мим”**нең саны **40**, **و - “Уау”**нықы **6**, **م - “Мим”**неке тагын да **40**, **ن - “Нун”**нықы **250**. Бөтенесе **336** килеп чыга Аллаһның Әл-Муъмин дигән исемендә.

Аллаһка бу исем белән берәү догасын ялварырга тишле булса, **Йә Муъмину, йә Муъмину** дип эндәшеүе тишле була **136** тапкыр әйтелсә күркәмерәк китаплпрыбызда язылa берәү Аллаһның Йә Муъмину исеменә, яки Йә Муъмин диеп Аллаһка дога кылса гел искә ала торган булса **дауым** укыса Хак Тәгалә бу бәндәгә. Дошманнарыннан именлекне насыйп итәчәк, язып янында йөртсә хәүфләрдән имендә була бу бәндә. Ялган һәм көфердән Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәне саклый ди. Теленә гел килгән саен **Йә Муъмин Раббым, Йә Муъмин Йә Аллаһ** дип дәшә торган булса шуны үзенә гадәт итә торган булса Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәнең теленә ялганны да китермәс, ялганнан саклар һәм көферлектән дә Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәне саклар ди. Иртәнге намаздан соң **276** тапкыр әйтеп, шул әйтүне гадәт итә торган булса, бу бәндә һич беркайчан да дөньяда тарлык күрмәс һәм Инша Аллаһ мохтаҗлыкка төшмәс ди. Теләкләре кабул булсын өчен **136** тапкыр **43** көн буена иртәнге намаздан соң әйтергә тишле Аллаһтан зур бер теләкләрен, зур бер йомышлары булган вакытта иртәннән **136**

тапкыр **43** көн буена Аллаһка ялварырга кирәк икән. Берәр нинди йогышлы авырулар илдә таралып шул хаүфе булган чагында да китапларда алардан сакланыр өчен Аллаһка ялварган вакытта бу Йә д Муъмин дигән Аллаһның исемен тапкыр әйтергә тиешле ди менә болар һәр кайсысы да Аллаһның зикре була Аллаһның **Әл-Муъмин** дигән исеме. Аллаһ Раббуль Гыйззә шушы исемне такрарлар итеп Аллаһ Раббыбызга ялварырга, иманларыбызның чынларына ирешергә, теләкләребезнең кабуллыгына ирешергә Аллаһ Раббуль Гыйззә насыйп әйләсә иде.

Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә Аллаһны искә төшергән белән, Аллаһны искә төшермәгән кешенең мисалы ди. Аллаһны исенә төшергән, Аллаһка исемнәре белән ялварып дөнья-ахирәт хәҗәтләрен сораган кеше тере кеше Аллаһны оныткан, йә Аллаһка ялвармаган кеше-үлек кеше ди. Аягында йөреп тә, ашап-эчеп тә мәет булып йөрү мөмкин икән. Тагын да Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә Имам Муслим хәзрәтләре, Абу Хурейра р.г.ләрдән риваят итә Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә:

Бер халык бер төштә утырып Аллаһны искә алдылар исә, аларны Аллаһның рәхмәт фәрештәләре канатларына чорнап алырлар, Аллаһның рәхмәте боларның өстенә явып торыр һәм боларның күңелләренә Аллаһ Раббуль Гыйззә сәкинәтне, күңел тынычлыгын насыйп итәр. Берәүләр күңел тынычлыгына ирешер өчен нинди генә дарулар эчми, ничек кенә, ниндисе генә калмый эчә торган булса да ул ул йөрәкне дә туктатуы мөмкин, ләкин күңел тынычлыгына ирешер өчен Аллаһ Раббыңны искә төшерү кирәк.

Бу бәндәләрне Аллаһ Раббуль Гыйззә бер җыелыштамы, мәҗлестәме, кайда бергә утырышып, базарда бүген ит-бәрәңге күпмедән дип утырганчы Аллаһ Раббыңны искә төшереп, Аның олылыгын, Аның кадерен искә төшереп. Аллаһның мәрхәмәт-шәфкәтен исенә төшерә торган булса Аллаһ Раббыбыз боларны үзенең хозурында булганнар арасында да, фәрештәләр арасында да әлбәттә. Аллаһ Раббуль Гыйззә искә алачак ди исеме-исеме белән кара Вәлине, Абдуллаһны алар мине искә төшермиләр дип Аллаһ Раббуль гыйззә исенә төшерәчәк ди.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМУМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреpгә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә ияргүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәядү җомгаларны хөрмәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем
Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!
Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле

Ислам кардәшләребезне, **Җомга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

***8 –нче ВӘГАЗ***

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ*** **ӘЛ- МУҺАЙМИН** ***ДИГӘН ИСЕМЕ***

Йи, иманлы бәндәләрем, минем берлегемә ышанганнарым, Аллаһ Раббыгызны күп искә алыгыз, зикр итегез, зикр итү искә алу дигән сүз. Аллаһ Раббыгызны күп искә алыгыз иртәләрендә дә, кичләрендә дә Аллаһ Раббыгызга тәсбих әйтегез. Тәсбих әйтегез дигән сүз Аллаһны паклау. Паклау үзебезчә әйтсәк тазарту. Ничек иттереп Аллаһны тазарталасың? Үзе пак, быкырдаган нәрсәне генә паклау мөмкин. Паклау дигән сүз күпме генә мушрикләр, Аллаһка килешмәгән сыйфатларны тагарга маташып йөри торган булсалар без Аллаһны паклап, кимчелекләрдән пак диеп таныуыбыз иманыбызны тазарту була.

Иртә-кичләрендә дә Аллаһ Раббыгызны паклагыз, Аңарга зикр-тәсбихләрегезне әйтегез, чөнки Ул Аллаһ Раббыгыз һәм Аның рәхмәт фәрештәләре дә сезгә салават кыла, сезне динсезлек гонаһларыннан иман-ислам нурына ирештерер өчен. Аллаһ Раббыгыз иманлы бәндәләргә шулай мәрхәмәт-шәфкатле булды Ул ди гел. Аллаһтан салават рәхмәтләргә ирештерү дигән сүә, фәрештәләрдән салават-догалар дигән сүз. Көръән Кәримдә күрәбез. Аллаһның рәхмәт фәрештәләре дә Аллаһның хак илчесенә Мухаммәд Мустафа с.г.в.гә салаватлар кыла Аллаһ рәхмәтен яудыра, фәрештәләр дә пәйгәмбәр Мухаммәд с.г.в.гә салават кылулары, дога кылулары була. Ничек инде Аллаһ та салават кыла, фәрештәләр дә салават кыла дия торган булса, мәгънәсе шул була, Аллаһтан салават рәхмәтен яудыру, фәрештәләрдән салават хәер дога кылу эшләрне уң кыл, бәлә-хәсрәтләрдән сакла дип фәрештәләр дә сезне динсезлек караңгылыкларыннан гонаһ, шайтан вәсвәсәләреннән, иман-ислам нурына чыгару өчен рәхмәтләрен яудыра.

Һәм Аллаһ Раббыгыз иманлы бәндәләргә мәрхәмәт-шәфкатле булды ди. Менә Монда рәхим дигән сүзе, Рахим дигән Аллаһның сыйфаты, иманлы кешеләргә хас икәнлеге күренеп тора. Мәрхәмәт-шәфкать Аллаһта да, Пәйгәмбәребеә с.г.в.нең дә исемнәре арасында Рахим дигән исеме бар иде. Шуның белән бергә, иманлы бәндәләр дә, мәрхәмәт шәфкатле булып, бер-беренә изгелек итә торган булсалар Аллаһның мәрхәмәт-шәфкатеннән алар да өлешен алган була. Җирдәгеләр дә мәрхәмәт-шәфкатле булыгыз. Аллаһ Раббыгыз да сезгә мәрхәмәт-шәфкатле булыр диеп Пәйгәмбәребеә с.г.в. әйтте.

Алай булган вакытта Аллаһ Раббыбызның зикрендә булу, Аңа тәсбихләребезне әйтү иманны кешенең вазыйфасы, бурычы. Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын ди. Сез Мине онытмасагыз, мин дә сезне онытмамын ди Һәм Аллаһны оныткан кешеләр кебек булмагыз. Аллаһны онытканнар бар, бу дөньяда без хуҗа диеп йөргәннәр бар. Аларны Аллаһ Тәгалә, Аллаһ Раббылырын онытканга күрә, үзләрен дә оныттырды ди. Бер көнне килеп терәлер танавына әҗәле, йә бөереннән, йәбавырыннан, йә йөрәгеннән, кайдан Аллаһ Тәгалә киттереп тоттара да, аннары әҗәле җитеп дөньядан китә торган була. Алар дөньяда Аллаһны онытканнары өчен, Аллаһ Раббуль Гыйззә үзләрен дә оныттырды, алар шикелле була күрмәгез, Аллаһ Раббыгызны оныта күрмәгез, искә

төшерегез ди. Без бүген Аллаһның 99 күркәм исемнәреннән **Әл-Муһаймин** дигән исеменә килдек Алынган, аның мәгънәсе Һәрбер нәрсәне саклап күзәтүче, үзенең бөтен яратканнарынын бөтен Аллаһның мәхлүкләре, шуларның бөтенесенең кылган гәмәлләренә дә, ризыкларына да, әҗәлләренә дә каин булучы, ризыгын да бирүче, гәмәлләрен дә уң итүче, үлән үсеп чыга торган булса, орлык ташладың да, үсеп чыга дигән сүз түгел, ташлап та, чыкмауы мөмкин, шунарга кайнап чыгып, яшелләнеп, чәчкә атып, җимешләр бирерлек иттереп күәтен бирүче Аллаһ, әллә кайчан вакытта бар иткән түгел, шул сәгатендә, шул минутында, яфраклар да ярдыручы, чәчәкләрен дә аттыручы, җимешләрен дә җиткерүче, яңгырларын да яудыручы, дөньяга да тудыручы, бәндәләрен дә, бөтен мәхлүкләрен дә, бер көнне әҗәлләрен дә китүрүче Ул Үзе. Болар бөтенесе дә **Әл-Муһаймин** исеменең мәгънәсенә килә.

Һәр мәхлүкнең ригаясе белән дә, һәр бер минут, секундында да аларны саклаучы да, яшәтүче дә, **мәхсүл** булган зат дигән сүз, кем дигән сүз була бу мәгънәдә әйткәндә, кем, зиһенебезгә кем килә чын хуҗа дигән сүз аннан башка бер кешенең дә монарга күәте, кодрәте дә җитми, бер хуҗа сиңа бирде акча, зарплата ашарга, түләргә җитми дисез, ни инде безнең бюджет шулай гына, калганын тап, берәр кайда эшкә кер, яки үзең тап, үзең тап дигән сүз берәр кайда төннә йөрергә туры килә Аллаһ сакласын. Әл-Муһаймин дигән Аллаһ дөньяга китергәнче үзе синең ризыгыңны да бар итте, дөньясын да бар итте, шушы дөньясында, ризыгын да биреп торучы, кайгы-хәсрәтләреңне дә ңибәреп торучы, моң-зарларыңны ишетүче, сорамыйча да синең хәлләреңне белеп рәхмәтен яудыручы, чын хуҗа дигән сүз без шундый хуҗаның коллары, аның берлегенә иман китерәбез. Аллаһның бу **Әл-Муһаймин** дигән күркәм исеме Көрьән Кәримдә нибары бер тапкыр гына әйтелгән, бүтән исемнәр бар, йөзләән-өзләгән тапкыр әйтелгәннәре дә бар, әле менә соңрактан килә **Әл-Гәзиз** дигән исеме туксаннан артык тапкыр әйтелгән, без моннан элек тә күрдек Аллаһның **Әс-Сәлам, Әл-Муъмин** исемен дә Көрьән Кәримдә ни бары лә йәстәви, Хәшер сүрәсенең ахырын укып ятса Аллаһ Раббуль Гыйззә аны бөтен бәләләрдән саклый. Ни бары Әл-Муһаймин дигән Аллаһның исеме, чын хуҗа дигән исеме Көрьән Кәримдә ни бары бер тапкыр килде, бүтән бер дә юк 6666 аяттан шушы килде, бүтән Аллаһ Раббуль Гыйззә кат-кат искә төшереп тә тормады, чөнки чын хуҗалыкта, Аллаһ белән бер кем дә тарткалаша алмый. Мин дигәннәр күп булды, фараоннар да, гитлерлар да, башкалар да җитәрлек булды.

Аллаһ Раббуль Гыйззә чын хуҗа кем икәнлекне, бөтен дөньяга меңләгән еллар буена аңлатты ди. Чын хуҗа икәнлеген, ышанган-ышанмаганы да ышанырлык булды. Аллаһ Раббы бу сүрәдә.

Ул Аллаһ Ул ди **ястен**, ул дигән вакытта, ул Вәли, Ул Әхмәт, ул Иван, ул Гәли дип әйтелмәсә дә ул дигәннән соң турыдан туры Аллаһны чамаларга тиеш иманлы кеше. Ул Аллаһ шундый зат аннан башка тәңре юк. **Әл-Мәлик чын хуҗа**, ия ул исемгә генә куелган түгел, **Әл-Куддус - изге, Әс-Сәлам – тынычлык-именлек** Анардан булган зат, **Әл-Муъмин** – иманлы бәндәләрнең дә иманын дөресләүче, **Әл-Муһаймин – чын хуҗа** булган Раббым **гыйззәтле дә**, явызлыкны җәбер белән теләсә дә туктатучы, **Әл-Мутәкәббир - өстен** булган Аллаһ Раббың.

Купме Анарга кимчелекләр тагарга маташкан булсалар да, булай иттерде инде яңгыр яудыра инде. Игенебез генә өлгергән иде, печән генә чабасы бар иде, йә үстереп кенә җиткергән идек. Булай булды инде диеп кырык нәрсәләрне Аллаһка тагырга маташабыз да, кайдан килгәнлеген, кимчелек хатасын үзебездән эзлибез. Аллаһ Раббуль Гыйззә әйтә күпме Аңарга ширк хаталар уйлый торган булсалар да, шуларның барысыннан Аллаһ Раббыгыз пак ди. Алай булган вакытта Көрьән Кәримдә ни бары бер генә урында Хәшер сүрәсендә Әл-Муһаймин дигән исеменең килеүенең сәбәбе дә. Башка берәүләр Аллаһның бу сыйфатында тарткалашырга, йә аңарда катнашырга өметләре дә белгәнгә

күрә, булмаса гыйззәттә, кодрәтле, көчле булырга, мәрхәмәт-шәфкатле булырга, сабыр булуда, башкаларда катнашыуы мөмкин. Абдуллаһ ибн Аббас р.г.дан риваят ителә: Аллаһнын бу Әл-Муһаймин дигән исеменең мәгънәсе бөтен халыкларның, бөтен **очратканнарының** нәрсә эшләгәннәрен күзәтеп торучы, үтәли күрүче, синең аяк-үрә нәрсә эшләгәнеңне дә, утырганыңны да, ятканыңны да, ни уйлаганыңны да, этнең кайда чыкканын, кырмысканың җир астында нәрсә эшләгәнен, кошларның кайда очканнарын, бөтенесен күзәтеп торучы, күзәткәчтән соң, аның тәкдирен дә билгеләүче Ул, чын хуҗа Ул дигән сүз ди, дигән дүрт хәрефле фигыл, күбесенчә гарәп телендә өч кенә хәрефле була тамыр, аннары гәҗәп, мондагы хәрефтә م -"Мим" бар, **م –"Мим"** кайда катнашты исә, шунда йөмшаклык, мәрхәмәт-шәфкат бар дигән сүз. Монда **ی - "ЙА"** сы да искиткеч йөмшак хәреф, ямле диеп тә әйтәбез. Аллаһка... кылган вакытыбызда да Йә Аллаһ диеп дәшкән вакытыбызда да

**يا - "Йә"**әйтелә, шуның үзендә йөмшаклык, мәрхәмәт-шәфкатлеге бар, монда бераз

**ه -"Һә"** хәрефе. Хуҗа, чын хуҗа Аллаһ

**ن -"Нун"** хәрефе дә искиткеч.

**كن - "Кун"** дигән вакытында Аллаһы Тәгалә бөтен галәмнәрне бар иткән вакытында бригадалар чакырып, мастерлар чакырып аларга кушмады, Үзе генә **كن - "Кун"** диде дә булды бөтен дөньясы, бөтен барлыгы, шунда **"Кәф"** белән **ن - "Нун"** арасында, шушы ике хәреф арасында, бөтен гәләмнәрнең булуы, анда да **ن - "нун"**хәрефе бар, искиткеч мәрхәмәт шәфкат тулган буларга, шунарга күрә дә Ул чын хуҗа, барысын кайгыртып, бөтенесенә җиткереп, ризыгын да, яшәвен дә, бәхетен дә тутырып бирүче дигән сүз, Мәгънәсенә карый торган булсак саклау да, **кайгырту, барысының чамасын чамалаучы** дигән сүз була. Әл-Муһаймин шуңа күрә дә словарларда әйтелә гигимония дигән сүздә, анысы булган чагында анарга берсенең дә хуҗалыгы катнашмый, чынында исә Аллаһның хуҗалыгында беркемнең катнашыуы да мөмкин түгел. Менә бу Әл-Муһайминнең мәгънәсе алай була торган вакытта әүвәл-ахырына кадәр, гел һәр нидә хөкеме үткән, чын хуҗа дигән Аллаһның исеме була. Әл-Муһайминнең хәреф, саннарына карый торган булсак беренче **م - "Мим"** аның саны **40**, **ه -"Һә"** 5, **ی - "Йә" 10**, **م - "Мим"40**, **ن - "Нун" 50**. Җыенысы **145** була. Аллаһның шушы исемендәге саны **145** диеп кенә берәр кайда язып куя торган булсаң да, Аллаһнын исемен язып куйган буласың, хәрефләре белән язмыйча **145** кенә язып куйдың исә, шушы Әл-Муһаймин исеменең мәгънәсен язып куйган буласың. Аллаһның бу исемен зикр итергә теләгән кешегә Йә Муһаймину диеп **145** тапкыр әйтергә тиешле була. Бу Аллаһнын күркәм исеме зикр итү **145** булды Йә Муһаймину диеп һәм шушы исемне, җәмигәдәндер диеп әйтелгән, күп мәгънәләрне үзенә алган Аллаһның исеме, хуҗа булгачтын шулай була, моның зикренә берәү дәвәм итә торган булса, гыйлемгә дә Аллаһның күп яшерен серләренә дә бу бәндә ирешә алыр Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәгә сәбәп кылыр, һәм залимнарның явызлыкларыннан да, шайтанның вәсвәсәсеннән дә Инша Аллаһ бу бәндә имин булыр ди, чөнки үз хуҗасын исендә тоткан затның Аллаһ Раббуль Гыйззә бәла-хәсрәтләрдән саклый, бүтән вәсвәсә китерүчеләрдән саклый, бүтән вәсвәсә китерүчеләрне, йә бүтән монарга өстен хуҗа булырга маташкиннарны Аллаһ Раббуль Гыйззә себереп түгәр. Аллаһның шушы исемен әйтеп торган, шунарга даимчелек иткән кешегә зикренә Аллаһның Йә Муһаймин исеменә зикр иткән берәү. Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәне бөтен кешеләр арасында сөекле, сөйкемле кылып сүзе үтә торган булып үзенең теләгенә, морадына җитә торган булыр, дәрәҗә һәм кадере башка бәндәләр арасында өстен булыр ди.

Аллаһның шушы исеме белән зикр итә торган булса. Аллаһка ялвара торган булса, кешеләр арасында сөйкемле дә, морадына җитешә торган да, мәртәбе һәм кадере дә артыр ди. Тагын да бер сүз әйтелгән китапларда, берәү гөсел коенганнан соң Аллаһның

шушы исемен **100** тапкыр искә алып Аллаһка ялварды исә Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәнең күңелен Инша Аллаһ раушан кылыр ди, раушан кылыр дигәне бөтен нәрсә ачыктан ачык булыр ди. Кайсы кеше аптырап йөри кайдан килгән, ни эшли, хәзер ни эшлим, иртәгә ни эшлим, ни эшләргә белми. Аны беләсез ничек итеп давалаганны тегендә-монда йөртеп яткырып, даруны каптырып аның белән генә бетереп булмый. Менә китапларыбызда да әйткән, гөселдән соң, пакланганнан соң **100** тапкыр Аллаһның шушы исемен әйтеп, Аллаһка ялварды исә Аллаһ Раббуль Гыйззә бу бәндәнең алдына тота торган эшләрен дә, йомышларын да, бөтенесен көн кебек ачыр бу бәндәгә йә Аллаһ Раббуль Гыйззә сәламәт-акылын да насыйп итә, эшләрен дә уң итә. Бу исемнең бер догасы да бар, гаҗәп бер дога, шуны да кылып куйса тагын да яхшы, әгәр гәрапчәсен әйтә алса, һич булмаса зиһененнән мәгънәләрен үткерә торган булса да.

Йә, Раббым, Бөтен кимчелекләрдән Син пак, ни кадәр олы синең кадерең, дәрәҗәң, синең солтанатың, хуҗалыгың ни кадәр куәтле, синнән башка тәңре юк, бөтен хуҗаларның да хуҗасы, бөтен муеннарның да иясе Син, барысын тотасың муеныннан. Син үзең чын хуҗа, сорамый да бирүче Син.

Йә, Раббым Аллаһ, хикмәтеңнең агышы белән, күңелеңдә синең хикмәтеңнең агышы белән сорыйм Үзеңнән, серләреңнең агышы белән изге бәндәләргә нурыңны яудырганы белән сорыйм Йә Раббым Аллаһ, Син миңа хәйбәт насыйп итсәң иде, хәйбәт дигәне кадерне, һәм бәндәләр арасында сүземнең үтеүен, кабуллыгын, өстен булуын, дөньяда бөтен бәла-хәсрәтләрдән өстен булуын серләрен Йә Раббым Аллаһ насыйп итсәң иде, Үзең хуҗа булган шикеллек бу дөньяда миңа да хур булуын насыйп итмәсәң иде дигән сүз. Үткәнне барыбыз да белә, ләкин Син булачагын да белүче. Аңлауларны да, телләрне дә Йә Раббым Аллаһ Син авыштырдың, Әдәм баласы зиһене белән дә, теле белән дә Аллаһның кәмәлен, Кәмәл-совершенство менә аларны күрәбез: нинди шәп төзегән диябез юлларны, күкләрне күрәбез, күреп чамалый алабыз, ләкин Аллаһның кодрәтен, Аллаһның чын хуҗалыгын мәрхәмәт-шәфкатен гомер буе чамалаган вакытта да, чамалап бетерә алмыйбыз. Син Йә Раббым Аллаһ, безнең зәгыйф акылларыбыз аңлап җитүдән дә өстендә олы АРАБ.Йә Раббым Аллаһ үзеңнән сорыйм, бу Муһәймин дигән, чын хуҗа дигән мөбәрәк исемеңнең бер тамчы өлешеннән Йә Раббым Аллаһ миңа куәт бирсәң иде, һәм бу исемеңненң **хәдиме тальяинең** дә ярдәме белән куәтләндерсәң иде, Үзеңнең гыйлми **мүәниләрдән** дә өлешкә Йә Раббым Аллаһ җитешү өчен. Йә Раббым Аллаһ чын хуҗа диеп менә шушы доганы борынгы китапларыбызда да язылган. Зубаир р.г.тән риваят ителә: Пәйгәмбәребеә с.г.в. әйтте ди: Кайсы гына таң атты икән Әдәм балалары уянган вакытларында Аллаһ Раббыгыздан бер өндәүче өндәр. Хуҗагыз булган, изге булган Аллаһ Раббыгызны олылагыз, бөтен кимчелекләрдән пак диеп таныгыз ди.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМУМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә ияргүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәядү җомгаларны хормәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем
Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

***9 –нче ВӘГАЗ***

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ*** **ӘЛ- ГӘЗИЗ** ***ДИГӘН ИСЕМЕ***

Бу җомгада Әл-Гәзиз дигән исеменә килдек, шуның мәгънәсен аңнарга тырышычакбыз
وَ مَا تَوْفِيق إلاَّ بِالله العَل الغَظِيم!

Аллаһ Раббуль Гыйззә кадерле китабында

**Дөреслектә Аллаһ Раббыгыз сүзләрнең иң күркәмен китап иттереп индерде, бер-берсенә бәйле булган мәсәләләрне Ул индерде, аларны ишеткән вакытта Аллаһнын газапларыннан курыккан бәндәләрнең тәннәре дә, күңелләре дә тетрә, алар Аллаһның зикеренә ашкынырлар бу Аллаһнын хидәяте теләгән бәндәсенә бирә аны, теләгән бәндәсен хак юлга күндерә, кемне Аллаһ Раббыгыз саташтырган булса, ул бәндәне юлга күндерүче бер кем дә юк ди.**

Аллаһ Раббуль Гыйззә шушы сүзендә Коръән Кәримендә дигән сүзе икешәр икешәр дигәнне, җәннәт турында да сөйли, җәһәннәм турында да сөйли, изгелек турында да, гонаһчылыклар турында да сөйли Шушылай Аллаһ Раббуль Гыйззә бәйнә-бәйнә иттереп дөньның тормышын да, мәңгелекнең бәхетен дә аңлата торган аятләрен җиткергән китабын индерде аны ишеткән вакытта Аллаһ Раббуль Гыйззәнен газабыннан курыккан бәндәләрнен тәннәре тетрә, бөтен күңелләре дә Аллаһның зикренә ашкыныр ди, Аллаһны искә алырлар. Берәүне Аллаһны искә алу, Аллаһны онытмау насыйп булды икән, бу бәндә Аллаһтан хидәяткә ирешкән булыр, хак юлга күнелгән булыр. Берәүгә Аллаһ Раббул Гыйззә насыйп итмәде исә, ул бәндәне хак юлга күндерүче бер кем дә була алмас. Шуның белән бергә Аллаһ Раббул Гыйззә үзенен зикрен, үзен искә алуны, исемен дә искә алуны, Аллаһ Раббул Гыйззә Көфер белән иманнан арасыннан аерма кылды. Менә тыштан барган вакытыбызда да кәләпүшен күрдек, мәчеткә йөргәнен , аннан соң инде тормыш вакытыбызда хәләл-харамнарны аерганын күрдек, шуның белән мөмкин мөселман икәнен күрәбез, шуның шикелле кебек Аллаһ Раббул Гыйззә үзенен искә алуны да, көфер белән иман арасында аерма кылды.

Көръән Кәримдә Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә

**Аллаһ Раббыгыз ялгыз үзе генә искә алыны торган булса. Аллаһ дип берәү әйтә торган булса, йә сүзен Бисмилләһир-рахмәнир-рахим дип берәү башласа. Аллаһны исенә төшерә торган булса, ахирәткә, мәңгелеккә ышанмаган булса, Аллаһның хозурына кайтуга инанмаган кешеләрнең йөзәре чытылыр ди, чырайлары сытылыр ди.**

**Аллаһтан башкалар искә алынса берәр шагыйрләр, язучылар искә алына торган булса, алар шунда сөенешерләр:**

**Әйт Йә Хәбибем Мухаммәд Мустафа с.г.в.: Ий җирләрне дә күкләрне дә бар иткән Раббым Аллаһ Күңелләрдәгене дә, күренгәнне дә белүче дә Раббым Аллаһ Бәндәләрнең арасында хөкем итүче ялгыз Син хөкем итәсең бөтен тарткалашканнарны да урынына җиткерүче, хөкем итүче, хөкем итүче ялгыз Үзең.**

**Әгәр дә үз бәхетләреннән качкан, көферлек-динсезлекләрен давам иткәннәргә. Җирдәге булган бөтен байлыклары, алтын-көмешләре дә, газ-нефтлары да, бөтенесен дә тагын шуның кадәресе була торган булса да кыямәт көнендәге газаптан котылыр өчен җитми ди. Тик ахирәткә ышанмаганга күрә генә дөньядан киткәннән соң яңадан терелүгә ышанмаганга күрә генә ул көферлекләрендә йөрерләр**

**Ул көн җиткән чагында исәпләренә дә, чамаларына да китерәлмәгән нәрсәләр аларга ачык булыр**

**Ул көн җиткән чагында бөтен кәсиб иткәннәрнең, кылганнарның явызлыклары аларга ачылыр, нидән көлгән булсалар, аны хурга санаган булсалар, алар бөтенесе чорнап алырлар аларны.**

Аллаһ Раббул Гыйззә моны **Әз-Зөмәр** сүрәсендә әйтә. Менә шушы Аллаһнын зикере көфер белән иман арасында аерма икәнлеген исенә Аллаһ Раббул Гыззә төшерде ди. Аллаһны искә төшерәбез, зикр кылыбыз, гүзәл исемнәрен дә искә алабыз, сөйләгән сүзләребездә дә эшләгәен эшләребездә дә, алым бәрешләребездә дә бөтенсендә дә Аллаһ Раббыбызны онытмыйча чын гәмәл итүләребезне Аллаһ Раббул гыйззә нисыйп әйлсә иде, шулай булды исә иманлы икәнлегебез, тышыбызда ук нур булып чыга трган була Инша Аллаһ.

**Әл-Гәзиз** дигән Аллаһның изгеисеме Көръән Кәримдә бу мүбәрәк исеме **93** тапкыр төрле сүрәләрдә килде. Элеккеге исемнәрне күргән идек Әл-Мухаймин мәсәлән ни бары бер сүрәдә генә, бер тапкыр гына килгән иде, шундый исемнәре дә бар , чөнки Ул Әл-Мухаймин булган сыйфатында бүтән бер кем катнаша алмый. Әр-Рахмән, Әр-Рахим дигәннәре берничә сүрәләрдә килгән ибе, мәрхәмәт-шәфкатле кешеләрдә дә бар, хәтта хайваннарда да бар , мәрхәмәт-шәфкат бу сыйфатында катнашуы да мөмкин иде, ләкин Әл-Мухаймин дигән һәм исеме ни бары Көръән Кәримдә бер тапкыр куллана. Бу исеме исә Әл-Гәзиз, гәзиз дигәнне беләбез, гәзиз кардәшләр дип тә әйтәбез, гәзизем дип тә әйтәбез, кадерлем дигән сүз Көръән Кәримдә 93 тапкыр килгән, күп иттереп килеүе дә Аллаһ Раббул Гыйзәнең бу исеме башкалар гыззәттә, көчтә, куәттә өлешләр була торган булса да Аллаһ Раббул Гыйззә бу мәгънәләрен Көръән Кәримдә искиткеч күп урынарында бер ничә сүрәләрендә 93 тапкыр искә төшереп әйткән. “Бакара” сүрәсендә күрәбез

**Әй иманлы бәндәләр, тынычлык-иминлеккә һәм тынычлы-иминлек юлы исламга бергәләшеп керегез, шайтанның эзләренә эләгә күрмәгез, тынычлык юлыннан башка юл шайтан юлы икәнлеген Аллаһ Раббул Гыйззә искә төшерә**

Чөнки иблис шайтан ул сезгә ачык булган дошман.

Сезгә Аллаһ Раббыгыздан Көръән аятләрендә бәйнә-бәйнә иттереп килгәннән соң да хаклык сезгә ачылганнан соң да тагын абынып йөри торган булсагыз сугыш-чукмарлыкларына, шайтан юлларына ияреп йөри торган булсагыз абына-абына

Беләгез Аллаһ Раббыгыз гәзиздер, хакимдер ди . ни дигән сүз Соңындагы аятен карыйк.

Әллә көтәләрме әдәм балалары Аллаһ Рабыларының болытлар арасында бөтәрләнеп килгәннәрен фәрештәләр белән бергә. Аллаһны күргәч кенә, фәрештәләрне күргәч кенә Пәйгәмбәребез с.г.в.нең вакытында Мәккә кәферләре дә әйтәдер иде: Менә безгә Аллаһ төшсә күкләрдән фәрештәләр белән бергә, йә фәрештәләр төшсә алларында командир булып Җәбрәил төшә торган булса, ул вакытта ышаныр идек дип Аллаһ Раббул Гыйззә

әйтә әдәм балалары да Аллаһ Раббылырының килгәннәрен көтәләрме болытлар арасыннан фәрештәләр белән бергә күренер фәрештәләр

**Фәрештәләр күренә торган көн җиткән вакытында эш беткән булыр ул чагында Аллаһнын газабы килеп җир-күкләр тетелеп юкка чыга торган булыр**.

Ул вакыт җиткән вакытта да, һәр вакытта да бөтен эшләр Аллаһ Раббыңа кайтадыр.

Сездән элек булган яшәгән халыкларның олылыры бәни Исраилдән сорагыз. Сора син Хбибем Мухаммә Мустафа с.г.в.

Күпме аларга, күзлзренә күренерлек галәмәтләрен күрсәттек Аллаһ Раббул Гыйззә коткаруы да, сәхрәләрдә булган чагында да, күз алдына китер сәхрәдә генә түгел, урманда ут ягыр өчен бер шырпы да таба алмыйсың, яныңа китермәгән булсаң Аллаһ Раббул Гыйззә кыргар ел сәхрәдә дә **мәң белән сәлвә** ашатты, кошлар кулларына килеп куна торган булды, күктән татлы ризыклар төшә торган булды, алардан сора ди Аллаһ Раббул Гыйззә күпме аларга китергән идек

Кем килгәннән соң да Аллаһның нигъмәтен кадерен белмәсә Аны алмаштырырга маташа торган булса Аллаһ Раббул Гыйззә ул бәндәсенә газабында каты, шәрифәсендә каты, Аллаһ тота торагн булса тиешле йөмшак урыныннан да бик каты иттереп тотып ала дигән сүзе менә бу аят-кәлимәдә Аллаһның Әл-Гәзиз дигән исеме. Аның янында Хәким дигәнен дә күрәбез хикмәтле гәзиз, гәзиз дигән сүзе көчле, куәтле кодрәтле иде, кадерле дигән мәгънәсе дә, яки шуның янында хикмәтле дигән, хәким дигән сүзе дә Аллаһ Раббул Гыйззә Ул Көч, куәт, кодрәтендә хикмәт белән эш итүче. Башка тикмәгә генә бер эшне дә эш итүче түгел дигән мәгънәсе аңнашыла. “Ибрахим” сүрәсендә күрәбез Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә

Ул Аллаһның илчеләренә пәйгәмбәрләренә карышкан, тарткалашканнар хәйлә мәкәрләрен кылдылар, үзлзренчә төрле хәйләләрне корырга тырыштылыр

Аларның бөтен хәләсе Аллаһка билгеле. Аллаһ Раббул Гыйззә Эч-тыштан белүче

Аларның хәйләкәр хәйләләре тауларны урыныннан эретерлек була торган булса да аны көндә күрәбез күпме кораллар башкалары-башкалары шартлаткан вакытларында тауларны да урыныннан кузгатыр шикелле, мактанып, хәтта җир йөзен ничә тапкыр харап итергә көчебез җитә диеп торган чакларыбызда да

Аларның хәйлә фикерләре тайларны урыннарыннан кузгатырлык булса да

Аллаһ Раббыңны, пәйгәмбәрләр биргән вәгъдәсен бозыклык дип уйлый күрмә Аллаһ Раббың пәйгәмбәрләрнә биргән вәгдәсен урынына җиткерүче уйлый күрмә пәйгәмбәрләр әйткән сүзне үзгәртер дип

Дөреслектә Аллаһ Раббың гәзиздер, ачуның гына түгел, үчнең дә ияседер Ул ди. Көч-куәтендә кодрәтендә шундый берәүгә соңыннан буоса да тотып алып үзеңнен үчен Аллаһ Раббул Гыйззә алучы, кайчан

Аллаһ Раббул Гыйззә гел үчен алып тормый, чөнки Аллаһ Раббул Гыйззә мәрхәмәр-шәфкат иясе үзе юктан бар итте, сөеп-яратып бар итте, Үзе Әр-Рахмән дә, Үзе Әр-Рахим дә, үчен ала торган көне

Җир башка җиргә алмашкан вакытында, күкләр дә алмашкан вакытында, әле җирнең дә, күкләрнең дә алмаша торган вакытлары бар икән

Көч кодрәтендә кәхәрдән өстен булган, ялгыз бер генә булган, Аллаһның каршысында бөтенесе берәмтекләп тезелеп бвскан вакытта Аллаһ Раббыгызның көче-куәте белән үчен алучы Ул ди. Алай булган вакытта Көрьән Кәримнең башыннан ук килгән вакытта беренче Әл-Гәзиз дигән исеме янында Хәким дигән исеме килә хикмәт белән, ашыкмыйча урынына җиткереп эш итүче, көч-куәтен галәмгә тотучы түгел, шуның артыннан ук тагын үчен дә алучы дигән сүз, шунарга күрә дә Аллаһ Раббысына карышкан-тарткалашкан бәндә Аллаһның үченнән бер кайда да кача алмый, моннан соң Көрьән Кәримдә күрәбез бу исеменң Аллаһның хәким дигән, зөнтикам дигән исемнәре

янында янәшә килүдән сөң, яңадан да Гафур исеменнән килә
Мәләикә сүрәсендә дөреслектә Аллаһ Раббың гәзиздер, кәч күәт кодрәтендә өстен булган зат, бик тә ярлыкаучы, көче җитә торып та бәндәләрдә рәхмәтен дә ярлыкауын кимчелек хаталарын ярлыкаучы
Хаҗ сүрәсендә Аллаһ Раббул Гыйззә әлбәттә һич чиксез көчле, гыйззәтле зат Ул ди. Үзенең көчен үткәрергә беркемгә мохтаҗ булмаган
Зухруф сүрәсендә җир күкләрне бар итте Ул, Аллаһ Раббың гыйззәтле, көче-күәте, булүче, белеп эшләүче дигән сүз була, тагын да Көръән Кәримдә күрәбез Аллаһның Әл-Гәзиз исеме янында Әр-Рахим исемен, Өммәтләребезне арттыра, Духан сүрәсендә Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә
Дөреслектә Ул Аллаһ Раббыгыз Гәзиздер бик мәрхәмәт-шәфкатлкдер, иманлыларга зонтикам икәнлеген дә, шилтәсендә каты, үчен алучы икәнлеген дә аңлап була, ләкин Аллаһның гыйззәт күәте иманлы кешеләргә бер вакытта да зарар китермәс, аларга зыян өчен түгел. Аллаһның Әл-Гәзиз исеме янында Әл-Хәким исемен дә күрәбез.
Ибраһим сүрәсендә Аллаһ Раббул Гыйззә өнди гыйззәтле булган мактаулы булган Аллаһның юлына, көче-өүәте булгачтын кадере булгачтын һмч чиксез мактаулы була бәндәләрнең арасында да касы бер вакытта мактыйлар көче-күәте, байлыгы булганны, ләкин ул чын гыззәт түгел инде. Аллаһның гыйззәте, мактаулы буларлык Көръән Кәримдә күрәбез тагын да Әл-Гәзиз исеме янында Әл-Вахаб исемен дә, Карагыз Сад сүрәсендә
Әллә аларның Аллаһка ышанмыча көферлектә йөргәннәрнең сорамыйча да нигъмәтләрен яудыручы, көч-күәт, гыйззәтендә булган Аллаһ Раббыңнын хәзинәләре бармы ди Аллаһка ышанмыйсыз бу хуҗа дип йөргәннәрнең Аллаһ Раббыңнын хәзинәсеннән хуҗалык бармы,
Җир-күкләрнең байлыклары әллә аларныкымы, теләсә Аллаһ Раббың шуны бер минутында, секундында юк итә ала.
Сәбәпләрне үзе күтәрелеп карасыннар дигәне җир-күктә бүгенге көнебезгә кадәр миллиард иттереп яшибез, алты миллиардка якын кеше көн саен ашый машинасына заправка ясый, ул гына түгел көн саен бәдрәфкә дә бара, бер йөртның , квартирның гына чүбе ничәшәр чиләкләр була торган була, ташлаган вакытта. Без бу дөньяда кем, ничек чшибез, әгәр ашап, чүпкә генә чыгара торган булсак, бозаудан ул вакытта нинди аерма бар, бу дөньяда ни өчен яшәдең, шушылай иттереп, миллиардлаган кешесенә ризыгын да биреп торучы, әзер дөньясын да яратучы кеше икәнлеген дә уйламаса, аны искә дә аласы килми тора торган булса, ул кем ди Аллаһ Раббул Гыйззә. Утын да яндырырлык, электр чыгарырлык, бөтен заводлар да эшләрлек, газы, нефте дә чыгып торырлык кем аларны эзерләп торган
Шуларның сәбәпләренә күтәрелеп карагыз, кем эзерләп куйды боларның барысын, Гәзиз булган, Вахаб булган Аллаһ Раббыгыз, гыйззә кодрәтендә өстен булган, сорамыйча да бөтен бәндә мәхлүкәтләренә кирәген бирүче дигән сүз. Алай булган вакытта Аллаһның бу исемнәре янында без бу Хәким дә, Галим дә, Рахим дә, Вахаб тә исемнәрен күргән чагында Әл-Гәзиз дигән Аллаһның исеменең гыйззәлте, кодрәтле дигән исеменең төрлө-төрле мәгънәләренең аңнауын күрәбез. Көръән Кәримдә Гафир, Мөкмин сүрәләрендә Аллаһның Әл-Гәзиз дигән исеме янында гәҗәп тагын бер исем килә
Аллаһ Раббул Гыйззә Үзенең илчеләренең халыкларга, үзенең кауеменә сөйләгән сүзләрен китерә: Йи кауымым, Мин сезне котылырга чакырам да, сез мине утка чакырасыз
Сез мине Аллаһка кәфер булырга, динсез булырга дисез, Алардан дин дә булмаган, гыйлем дә булмаган потларга, таш-агвчларга табынуга, ширккә, мин сезне Гәзиз булган,

Гаффар булган Аллаһ Раббыма чакырам, көч-күәтендә, кодрәтендә өстен булган, җир-күкләрен дә бар иткән, көн саен да ризыгын биреп торучы, яшәү дәртен күәтен дә биреп торучы . Абынган яңлышкан вакытыбызда, хаталарыбыз-кимчелекләрне дә ярлыкаучы, абынган саен гафу итүче Аллаһ Раббыма өндим сезне ди. Менә шушының белән Аллаһ Раббул Гыйззә Әл-Гәзиз исеменең мәгънәләре ни кадәр нәзек, ни кадәр олы икәнлеген күрсәтә. Бу аят кәлимәләрдән Аллаһның Әл-Гәзиз дигән исеменең мәгънәләре бер аз булса да күз алдыбызга килә Аллаһка шөкер Әл-Гәзиз дигән Аллаһның исеме тәфсир китаплпрыннан карый торган булсак та мәгънәләре килә Сильный, Могущественный, Редкий, Ценный, Милый, Тяжкий дигән мәгънәләрдә килә. Бу Әл-Гәзиз дигән Аллаһның исеме

عِزَّ عواوة عزة

Дигән фигылдән алынган

дигән маздарлардан алынган.Үзебез беләбез бит гыйззәт дигән сүзне гыйззәтле була диеп әйтелгән китаплпрыбызда да әдәбиттә дә бар ул ни дигән сүз инде, беренче мәгънәсе عَزَّ يُعِزُّ быть славным дигән сүз , без гәзиз дигән сүзне кадерле генә диеп аңлыйбыз, бик гәзиз инде бу миңа, бик кирәкле, кадерле диеп кегә аңлыйбыз, ләкин гәзизнең беренче мәгънәсе көч күәтле булу, дан дәрәҗәле булу, икенче мәгънәсе быть редким не доступным, дорогим, дрогоценным

Диеп Аллаһ Раббул Гыйззә Көръән Кәримдә пәйгәмбәребез с.г.в. турында әйтә Сезгә нинди авыр мәшәкатләр төшкән булса ул Аллаһның илчесенә бик гәзиз бик авыр төшә дигән сүз. Өченсе мәгънәсе быть тяжелым, трудным, тыгостным мәгънәләрендә гыйззәт алай булган вакытта мәгънәсе عزت слава, честь, достоинство, гордость, мощь, величие, сила болар бөтенесе Аллаһка килешкән Аллаһның олы сыйфатлары.

Әл-Гәзиз исеменең саны 94 “ع” хәрефенең саны 70, “ز”-7,”ي”10, “ز”7. Шуның белән 94 була. Бу исемне берәүнең зикр итәсе килә икән 94 тапкыр Йә Гәзизу диеп әйтергә тиешле була. Йә Гәзизу “ع” тамагы белән чыгара торган була саны белән әйтә торган булса бу хәрефнең саннарын чыгарган була алдында хәрефе нидә янында әйтергә тиешле, китапларда языла, берәр дөньяда зур түрәләр, хуҗалар алдына, олы бер йомыш булса 94 не 94кә тапкырласаң, яки 94не 10га тапкырлап әйтеп кенә торган булсаң бу бәндә үзенең хәҗәтенә, моратына җитмичә чыкмас ди, теләгән бу бәндәгә Аллаһ Раббул Гыйззә хич чиксез үтәтер, олыларга, олы йомыш белән кергән вакытта. Икенче: йортыннан берәү сәфәргә чыкканда, юлга чыккан чагында, капкасыннанмы, ишегеннәнме чыккан вакытында Йә Гәзизу диеп искә төшерә торган булса, дин һәм доньясына Аллаһ Раббул Гыйззә һәр бер эшләрендә гыйззәткә ирүшегә дәрәҗәсенең артуына Аллаһ Раббул Гыйззә бу бәндәгә сәбәп кылыр, Йә Гәзизу диеп бер бәндә саннары белән яза торган булса көмешкә, йә алтынга язып йөртә торган булса. Аллаһның шуның белән бергә Йә Гәзизу диеп искә төшерә торган булса, дошманнарыннан өстен булуга гыйззәтле һәм хәйбәтле булуга Инша Аллаһ сәбәп булачак дигән. Тагын да 40 көн буена иртәнге намаздан соң 40шар тапкыр Йә Гәзизу диеп берәү Аллаһка ялварыр булса бу бәндәне Аллаһ Тәгалә гомере буена бер кемгә дә мохтаҗ кылмас ди, бер кемгә дә мохтаҗ кылмады икән, аның мәгънәсе икәнен һәр кайсыгыз да аңлыйбыз. Аллаһ Раббул Гыйззә эшләрен дә уң итеп, дошманнарның да вәсвәсәләреннән бәлә-хәсрәтләреннән дә явызларның явызлыкларыннан да Аллаһ Раббул Гыйззә бу бәндәне саклаячак дигән сүз. Аллаһ Раббул Гыйззә үзенең гыйззәтенә һич беркемне катнаштырмаган шикелле Аллаһ Раббул Гыйззә үзенә тулы иман белән яшәүләребезне, ширк һәм явызлыктан ерак булып, гыйззәтле Раббыгызның бәндәсе булып яшәүләрне, зикренә Аллаһ Раббул Гыйззә насыйп әйләсә иде. Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә

قال رسول الله صلى الله عليه وسلمّمن سَبَّحَ الله مايةً بِالغَدَاةِ وَ مايةً و بِالعشِى

Кайберәүләр кайдан алай бик җиңел юлларны күрсәттең диеп тә әйтүчеләр булуы мөмкин. Расул Акрам с.г.в. бу хәдис шәрифне әйтә: берәү Аллаһка йөз тапкыр тәсбих әйтсә. Сөбханаллаһ диеп өйзне иртә белән таң аткан чагында, йөзне кич белән кояш баеган чагында әйтсә

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم:كَانَ كَمَن حَجَ مابةً حَجَةٍ

Йөз тапкыр хаҗга барганның савабына ирешер ди. Берүләр Болгарга баруны нинди ул хаҗ булсын дип, берсе дә хаҗ дип әйтми, савабы әҗере турында. Аллаһка тәсбих әйтсә иртә-кичендә йөзәр тапкыр, йөз тапкыр хаҗ әҗеренә ирешер

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: وَ مَن حَمَدَ الله مايةًبِالغَدَاةِ وَ مايةً و بِالعشِى كَانَ كَمَن حَمَلَ عَلَى مائةً فَرَسٍفى سَبِلِ الله

Берәү таң аткан вакытында да, кояш баеган чагында да кичен дә Аллаһы Раббысына тәхмит әйтсә, Аллаһны мактаса Әлхәмдүлилләһ дип әйтсә, йөз тапкыр иртән кояшы чыкканда йөз тапкыр кояш баеганда, ул бәндә Аллаһ юлында йөз атка утырып, атланып чапкан булыр ди. Йөз атка атланган әҗеренә ирешер ди

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: وَ مَنْ هَلَّلَ الله مايةًبِالغَدَاةِ وَ مايةً و بِالعَشِى كَانَ كَمَنْ اَعْتَقَ مائةً رَقَبَةٍ مِنْ وُلْدِ إسْمَاعِيلَ

Берәү кем иртә һәм кичендә йөз тапкыр тәхдияне әйтсә Лә иләһе иллаллаһ дип, бу бәндә Исмагыл г.с.нең балаларының йөз баласын коллыктан сатып алган булыр ди Аллаһның хозурындагы савака, Расул Әкрам с.г.в.нең нәселеннән дигән сүз, берәүләр тәхлил әйтү безгә кирәк түгел үл, тиешсез ул, бидагат ул дигән сүзләрне җавап таба

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: وَ مَنْ كَبَّرَ الله مايةًبِالغَدَاةِ وَ مايةً و بِالعشِى لَمْ يَأْتِ فِى ذَلِكَ اليَوْمَ أحَدٌ بِأكْثَرَ مِمَّا اَتَى بِهِ إلاَّ مَنْ قَالَ مِثْلَ ذَلِكَ, أَوْ زَادَ عَلَى مَا قَالَ!

Кем тәкбир иә һәм кичендә йөз тапкырне әйткән булса Аллаһу Әкбәр диеп . Хич беркем анардан да артыграк әҗергә житә алмас, аның шикелле әйтмәсә, аның шикелле тәкбир әйтеп, йә анардан да арттыра торган булса шул вакытта гына моны үздырыр ди бу хәдис шәрифне Имам Термизи хәзрәте Гөмибиш Шугайб хәзрәтләре р.г. дан риваят итте Менә күрәбез бу хәдис шәрифләрдә дә, аят кәлимәләрдә дә Аллаһның зикрен күңелләрдә ни кадәр нур арттырылганын, доньяның бөтен мәшәкат авырлыкларын җиңеп чыгуга да Аллаһ Раббыбызның донья ахирәт рәхмәтләренә ирешеүебезгә дә сәбәп булачак нурыбызның артуына да. Инша Аллаһ сәбәп булачак. Әл-Гәзиз булган көче-күәте кодрәте булган, хикмәтле булган, сорамыйча да нигъмәтләрен яудырып торган. Кимчелек хаталардан да ярлыкаучы Аллаһ Раббыңнын бәндәсе булып зикрен давам итеп Аллаһ Раббул Гыйззә җөмләбезгә насыйп әйләсә иде.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГАТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәядү җомгаларны хөрмәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем
Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә,

кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

***10 –нче ВӘГАЗ***

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ ӘЛ- ҖӘББӘР ДИГӘН ИСЕМЕ***

Әл-Җәббәр дигән исеме. Аллаһ Раббул Гыйззә Көръән Кәримендә Рәхмәтенә, олы әҗерләренә җитешкән бәндәләрен, колларын сыйфатлаган вакытта болай ди.

Дөреслктә мөселман ирләр һәм мөселман хатыннар да, иманны ирләр, иманлы хаттыннар , эчендә дә тышында да Аллаһның газабыннан курыккан һәм эшен изгелек белән кылырга омтылган ирләр дә һәм хаттыннар да, сүзләрендә дөрес булган ирләр дә, һәм сүзләрендә дөрес булган хатыннар да, уразаларын тоткан ирләр дә, уразаларын тоткан хатыннар да, гәүрәтләрен саклаган , харамнан саклаган ирләр дә, гәүрәтләрен саклаган хатыннар да. Аллаһны бик искә алучы ирләр дә һәм хатыннар да боларның барысына да Аллаһ Раббың ярлыкыуын һәм олы әҗерләрен эзерләп куйды ди. Ирләр дә хатыннар да диеп әйтүнең сәбәбе бар үзебезнең телебездә.

Син дип ир кешегә дә хатын казга да әйтәбез, ләкин рус телен үтеүендә дә аермалар бар, гарәп телендә дә шулай ук Көръән Кәримнең аятләрендә дә күбесенчә ирләргә карата сүз әйтелгән. Бер вакыт Хатын-кызлар җыелып Пәйгәмбәр с.г.в.нең каршына киләләр Йә Расул Акрам с.г.в. дөньяның яртысы без, гәмәлләрне дә кылабыз, ләкин безгә ахирәттә бер нәрсә дә юк ахырысы. Нигә алай дигән чагында, гел ирләргә генә җәннәтләр дә бар, әҗерләр дә бар диеп әйтелә дигән чагында Аллаһ Раббул Гыйззә менә шушы аят кәримәне иңдерде. Иманлы ирләр дә, иманлы хатыннар да, ураза тотучылар Аллаһны зикр итүче ирләр дә, хатыннар да дип аерым аерым бер тапкыр менә шулай иттереп әйтте. Булмаса гарәп теленең кагыйдәсендә ирләргә карата әйтелә торган сүз әйтәбез мәсәлән Әссәләму гәләйкум “Кум”-сез дигән сүз, сезгә сәлам булсын дип хатын-кызлар гына була торган булса Әссәламу галәйкуннә. “Күннә” дигәне сез дигән, ләкин хатын-кызларга әйтә торган сүз, шул мең хатын-кыз арасында бер ир генә була торган булса бөтенесенә бер юлы Әссәләму гәләйкум дип әйтелә, ирләргә әйтелә торган сүз белән. Шуның өчен дә башка аятләрдә дә Аллаһ Раббул Гыйззә ирләргә карата әйтелә торган сүз белән әйткән иде. Монысыннан да бәйнә иттереп аңнатыр өчен ирләрне һәм хатыннарны аерым зикр иттереп Аллаһ Раббул Гыйззә итте. Йомгаклауче иттереп Аллаһ Раббул Гыйззә Аллаһны күп искә алучы ирләр һәм хатыннар аларга Аллаһ Раббул Гыйззә ярлыкывын да һәм олы әҗер савабын да эзерләде ди. Бу Әхзәб сүрәсендә Пәйгәмбәребез с.г.в. Аллаһны искә алуыны. Аллаһка зикр олылыгын исебезгә төшереп болай ди бер хәдис шәрифендә. Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә сәхәбәләргә Мин сезгә гәмәлләрегезнең иң хәерлесен әйтимме эшләгән эшләрегезнең, гәмәлләрегезнең, тырышлыкларыгызның иң хәерлесе кайсысы икәнлегеә әйтимме. Иң пагы да, иң чистасы да Раббыгыз Аллаһ хозурында Аның хозурына кайткан вакытыбызда иң

хәерлесе, иң пагы булыр, дәрәҗәләрне арттыруга, иң хәерлесе кайсы икәнен, алтын-көмешләр Аллаһ юлында садака иттереп биреүгездән дә хәерлерәк булган , ул гына түгел, дошманыгызга каршы югылып сез аларның муеннарын чалып алар сезнең муннарыгызны чалудан да хәерлеге кайсысы икәнлеген әйтимме ди. Аллаһ Раббыгызның зикре, Аллаһны искә ала торган булсагыз, дошман белән капма-каршы кан түгеп, сугыәуыгыздан да ул сезгә хәерлерәк булачак дип Пәйгәмбәребеә с.г.в. әйтте. Шуның өчен без җихад кылабыз дип Аллаһ юлында дигән булып бер-берсенең каннарың түгеп, йә бамбалар, нәрсәләр ташлап куеп хаксызга да кан түккәннән аннан соң бандитлык белән наркотиклар сатып үз үзләрен дөнья дәрәҗәләренә җитешәм дигән кеше дә бер кайда да Аллаһның юлыннан булачак кешеләр түгел ди. Бәлки хаклы булган вакытында да Аллаһның зикре нинди өстен дәрәҗәләре бар икәнлеген әйтә. **Әл-Җәббәр** Аллаһның исеме, нинди сүздән алынган, ул Көрьән Кәримдә Аллаһның сыфаты булып ни бары **бер** тапкыр гына килә, тагын биш тапкыр булай, Аллаһның сыйфаты булып түгел, башка берәүләрнең сыйфаты булып килә. Көрьән Кәримдә ни бары Хәшер сүрәсендә Аллаһның сыйфаты булып килә.

**Ул Аллаһ** Раббыгыз шундый зат Аннан башка тәңре юк, Ул хуҗа да, изге дә, тынычлык-именлек тә Анардан, **Мөъмин** – иманны бәндәләрнең иманнарын дөресләүче дип әйткән идек, **Муһаймин** хуҗалыгына бер кемне катнаштырмыйча чын хуҗа булган зат Ул, гыйззәт кодрәтендә өстен булган зат. **Җәббәр** дә, **Мутәкәббир** дә, Аллаһ Раббыгыз Аңарга тагырга маташкан бөтен кимчелекләрдән пак Ул ди.

Аллаһ Раббул Гыйззә **Җәббәр** дигән сүз алай булган вакытта кайдан килә. Бездә кайбер вакытта исем иттереп йөртәләр җәббәр абзый дип Әстәгафируллаһ. Җәббәр дигән сүз җәберләүче дигән сүз бик тә җәберләүче, җәберләрне ишеткәнегез бар, җәбер зөлем дип әйтәбез, җәбер зөлем мәгънәсе ничек Аллаһка була ди Җәбер зөлем кылма дип әйтәбез үзебез.

Пәйгәмбәребез с.г.в. шуны өйрәтте. Аннары аптырагансыздыр Көрьән Кәримнең үзендә шушы **Әл-Җәббәр** дигән исеме бер тапкыр гына килә Аллаһныкы булып, 4-5 тапкыр башка кешеләрнең сыйфаты булып килә. Карыйк ансысын алдан мәгънәсен аңнар өчен. Худ сүрәсендә Аллаһ әйтә.

Ул гад кевеме, тарихта үткән олы бер халыклардан Раббылырының аятләрен инкәр иттеләр, юкка санадылар һәрбер кире җәберләп йөрүченең артыннан аның кушывына ияреп йөрер булдылар, явызлыкта булган түрәләре хуҗаларырына, патшаларына ияреп йөределәр ди Аллаһ Тәгалә шул вакытында аларны ул явызлыкта түрә булганнарын Аллаһ Раббул Гыйззә явызлыгында, зөлемендә кире булганнар дип Аллаһы Тәгалә атады, **нуктаулы** түгел, челтәләп әйтте тагын да Ибраһим сүрәсендә күрәбез.

Динсезлектә, көфердә булганнар әйтәләр иделәр илчеләренә, аларның арасында булган Аллаһның илчеләренә әйтәләр иде дигән сүз. Монысы кәфер диючесе булсын, көфердә булганнар, Аллаһның илчеләренә, араларында булган илчеләренә әйтәләр иде.

Без сезне әлбәттә җирләребездән куып та чыгарырбыз,

Йә безнең шикеллек безнең арабызда йөрерсез, безнең милләтебездән булырсыз дип, таныш сүзме бу? Бик таныш, күптән түгел безгә дә шуларны әйтәләр иде, кешеләр кебек йөрисезме, салып ташла кәләпүшеңне, йөрисеңме иске калдыкларың белән кешеләр шикелле бул, булмасаң табырбыз сыңа урыныңны, табылды да. Себерләрдә, урманнарда утын кисергә, җир астына казып кертерлек булганнары аз түгел иде. Күптәнге түгел генә сүзләр, көфердән булган, Аллаһның илчеләренә тарих буенча шушылай сөйләделәр, йә җирләребездән куырбыз безнең арабызда булмассыз, йә безнең шикелле итеп, безнең милләтебезнең арасында булыгыз, кешедән аерылмагыз **АРАБ.**

Аллаһ Раббыбыз шул вакытта Аллаһның Пәйгәмбәрләренә куәт бирерлек иттереп, вәһи кылды аларга.

Золым кылган, үз бәхетләреннән үзләре качканнарны харап итәчәкбез әлбәттә күпме җирдә булабыз, без хуҗа диеп йөргән булсалар да, бөтен җәбер-золымнарны кыла торган булсалар да соңнары аларның һәләк булачак ди Аллаһ Тәгалә бөтен Пәйгамбәрләргә дә Без хәбәр иттек ди, вәхи белән ирештердек. Анардан соң рәхәтләнеп бу җир йөзендә бәхетле яшәүчеләрдә, яшәтәчәкбез Без сезне дип Аллаһ Раббул **Гыйззә.....** кылдык**.**
Бу минем урыннан да галәмнән дә хәуфтә булганнарга минем **минем** урынымнан да хауф булган, минем кисәтү вәгъдәләремнән, куркуда булганнарга дигән сүзе. Аллаһ Раббул Гыйззә кабат-кабат итереп әйтә. Һәм көнебездә дә күрдек түгелме җитмеш ел буена динсезлекне безгә генә түгел, безнең илгә генә түгел, бөтен дөньяга да тагарга маташканнардан соң Аллаһ Раббул Гыйззә себереп түкте, йә буяуларын икенче төскә буяды, меңләгән мәчетләр, чиркәүләр дә салынып ята Әлхәмбүлилләһ бүген, мәчетнең капкасында булса да, кайда барсаң, ни эшләп йөрисең, ник эшкә китмәдең, комсомолецмы, коммунистмы син дип сораныр торучылар да юк. Яшләр белмиләр аны, ләкин моннан 15-16 еллар гына мәчетнең капка төбендә, менә бу әбиләр урынына ул вакытында санап торучысы да, рәсемгә төшерүчесе дә торалар иде. Гәетләребездән соң да, җомгада юкка инде дә, ләкин гәетләрдән соң да, син мәчеткә бардың үзең комсомолец дип, йә үзең коммунист дип чакырып чиркәүләрендә, йә анарга мәшәкат китерүләрендә, бүген мәдрәсәләребездә кил инде дип шәкертләрне чакыра торган булсак авылдагы, шәһәрдәге бабайлар бар инде, бер имамыбыз булыр, без үлеп бетербез дә, бездән соң кем калыр дип төртә-төртә җибәргән булсалар, әле 60-70 нче елларда да мәдрәсәгә килгән кайсы шәкертләр дә бигрәк тә Узбекистаннан булганнан, милиция чакыртып, алдына пистолет куеп ни эшләп йөрисең, нигә барасың ул якларга диеп андый сорауларын да куйганнары да бар иде. Онытырга тиешле түгел моның берсен дә. Аллаһ Раббул Гыйззә әллә кайдагы меңәр-меңәр ел моннан элек булган хәлләрне генә түгел, бүгенге көнебезне дә, моннан 15-20 ел үткәннәребезне дә хәтеребездән чыгарарга тишле түгел. Аллаһ Раббул Гыйззә. Минем хозурыма кайтудан, карагыз аны дип читләреннән хауфта булган куркуларга шушылай иттереп дөньяда да тыныч-иркен яшәүләрне, әлбәттә Мин Аларга бирәчәкмен дигән вәгъдәсен күрергә Аллаһ Раббул Гыйззә насыйп итте.
Алар золым-җәберләрне күргәчтән соң да эшләре уң булды. Аллаһтан уң булуын сораганнар иде, һәм һәрбер явыз, җәбер, золым кылучы килгәннәрдә хур булдылар дип Аллаһ Раббул Гыйззә моны 1400 ел ук Көръән Кәримдә әйтте, шуның өчен бу иркенлекләрнең килмәүләре кинәт гәмәл гыйбәдәт кылучыларыбыз да мәчетләребезгә йөрүләребез **дә, ,** манараларыннан яңгырап азан әйтүләре дә Аллаһның вәгъдәсендә карата тик шуның карата тик шуның кадерен генә белүләребезне Раббым Аллаһ насыйп итсә иде. Менә монда Аллаһ Раббул Гыйззә тагын да **Җәббәр** дигән исеме янында **Гәмид** дип кире дип әйтте. Мактауларның түгел Аллаһның пәйгамбәрләренә карышкан кешеләрнең сыйфаты иттереп тагын да әйтә Гафир сүрәсендә монсы.
Аллаһның аятләре хакында һич бер дәлилләр йә таянычлары да булмый тарткалашкан кешеләр.
Аларның сөләгән сүзләре Аллаһ каршвында да аларга дошманлык йөзеннән аларга явызлык йөзеннән иманны кешеләр арасында да олы булды ди. Аллаһ та кабул итмәс, иманны кеше дә кабул итмәс Аллаһның аяте хакында Көръән хакындамы элек булган китаплар хакындамы кем тарткалаша торган булса аңардан Аллаһны гына үзенә дошман тотыр иманлы кешеләрне үзенә дошман тотыр.
Шушылай иттереп Аллаһ Раббул Гыйззә Һәрбер тәкәбер, явыз **җәлем** золымченең күңеленә каплар ди. Тик күңеле капланган кеше генә кирелегендә, динсезлегендә дә давам иткән генә Аллаһның аятләрен ялганга тотып аларның хакында сүз йөртүдә

мөмкин.
Әле күптән түгел генә Гариф Губайның 15-20 еллар элек чыгып Көръән Кәримдә серләре дигән китап чыгарып, шуның аятнең башын яза, ахырын язмый, ахыран яза башын язмый, һәрбер аятеннән соң мәгънәсенә язып көлеп куя торган була. Шуны атеистларга пособие иттереп таратып йөрткәннәр иде. Ахырында исә үзе үлеп ятып череп яткан вакытында да мәетен дә илтергә дә кешесе дә булмады, шуны ук Аллаһ Раббул Гыйззә күзебездә дә күрсәтте тик динсезлегенә тәкәберлегенә җиткән, йә бер золым белән башкаларны да, үзенә ияртергә, җәһәннәмгә ияртергә үзенә кисәтү ясарга, омтылганнарны Аллаһ Раббул Гыйззә менә бу аят Кәримәдә **Җәббәр Мүтәкәббир** дип сыйфатлады. Үзенең хак илчеләреннән булган Яхья г.с. хакында Аллаһ Тәгалә булай ди Көръән Кәримдә.
Һәм без анарга сабый чагында ук хөкемне бирдек хуҗа булуны Яхья г.с.гә күңеленә йөмшаклыклар бирдек, паклыкны бирдек, ул йөмшаклыкларны да үзебездән бирдек ди Аллаһ Раббул Гыйззә  мәрхәмәт-шәфкат кенә түгел, бәлки күңел йөмшаклыкларын да без анарга үзебездән бирдек, ул Аллаһның газабыннан куркып рәхмәтен өмет итеп изгеләрдән иде. Ата-анасына да искиткеч изгеләрдән булып, изгелеген күрсәтә торган булды, җәбер-золым гәнаһларны эшләп йөрүчеләрдән булмады ди.
Ди Аллаһ Раббул Гыйззә Яхья р.г. сыйфатланган вакытында җәберләрдән түгел иде ул диде, алай булган вкытында **Җәббәр** дигән сүз, тагын да начар мәгънәле явызлыкны, җәбер золымне бик тә куркыныч дигән сүз.
Аллаһ Раббыңнын сәламе рәхмәте анарга туган көнендә дә, тере булган яңадан кубарылган чагында да дип әйтә Аллаһ Раббул Гыйззә менә ду сыйфатларны китергән вакытында мактаусыз иттереп, саклана күрегез җәбер золымнән дип хәдис шәрифтә дә Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә.
Кәрдәшең залим буласа да мәзлүм булса да анарга ярдәм ит. Залим кем, җәбер золымне кылучы, кешене рәнҗетүче, йә хаксызга кыйный, йә хаксызга уч тота, бу золымнең үзе. Шуның белән бергә кешегә генә түгел, үз үзенә дә золыме булуы мөмкин, динсезлектә калучыларны да, акылын эшләтмичә акылын тик шешәнең кайсысында ничә йөлдыз бар икәнлеген генә караучыларны. Аллаһ Раббул Гыйззә аларны да залим дип әйтте, үз бәхетеннән качучы кешегә дә, рәнҗетү китерә, үзен дә рәнҗетә торган була.
Мәзлүме кем өстенә-бәла хәсрәт төшкән **кешенеңдер** явызлыгы төшкән, моның догасы Аллаһ хозурында кабул ди Пәйгәмбәребез с.г.в. Ата-ананың догасы, изгеләрнең догасы, мусафирларның догасы дигән чагында Пәйгәмбәребеә с.г.в. шуларны санаган вакытта. Берәүләрнең золыме аларның өстенә төште икән шул чагында дога кылды икән Аллаһ Раббул Гыйззә бу бәндәнең догасын кабул итмичә калдырмас ди. Шул сәгатендә үк тә кабул булырга мөмкин, тормышта да күренә, мәзлүмнәрнең бәддогасыннан сакланыгыз ди Пәйгамбәребезс.г.в. дә әйтә, чөнки аларга рәнҗегәнгә күрә Аллаһ Раббул Гыйззә шул сәгатендә , минутында догасын ишетә һәм кабул итә. Пәйгмбәребез с.г.в. әйтә залимга да, мәзлүмгә дә ярдәм итегез ди. Ничек? Йә Расул Аллаһ АРАБ. Бу мәзлүмгә ничек иттереп ярдәм итәсебезне беләбез Йә Расул Аллаһ диләр сәхәбәләр, йыгылып ята кемдер төртеп төшергән, йә кыйнаган йә җәрәхәтләнгән, йә малын талаган, анарга мал бирергәме, йә күтәреп больницага илтергәме икәнлеген беләбез. Залимгә ничек иттереп ярдәм итергә дигән чагында Расул Әкрам с.г.в. әйтә Кулларын тотыгыз ди, кыла торган явызлыгыннан кулларын тотыгыз ди. Туктатырсыз тукмый башласа тукматма, сүгә башласа сүктермә, йә бер золыменнән туктатырсыз, хәдис шәрифтә тә күрәбез.
Берәүегез җәбер золыменең кылынып торганын күрсәгез, ярамас эшне, үзгәртегез аны кулыгыз белән, йә телегез белән , йә һич булмаса йөрәгегез белән.
Ләкин күңел белән генә рәнҗеп калу ул иманның иң зәгыйфе, икенче бер сүзендә Пәйгәмбәр с.г.в. горчица онынннан да ваграк икән ди ул вакытта иманыгыз күңелдә ди.

Күңел белән генә рәнҗеп калу. Остановкада 15-20 кеше торып шунда ике-өч явыз килеп, берәүне канга батырып яткырыу мөмкинме, бер кем дә сүз дә дәшми. Автобус кайда икән дип икенче якка карый, мында карамый, исе дә китми, шушылай подъезд да квартирага берәүләр кереп яталар малын ташып ята торган була. Бу мы без әйтүебез мөмкин мәчет тулды дип, тулып ятабыз дип, ләкин Пәйгамбәребез с.г.в.нең шушы сүзе дә бар дөнья бетер алдыннан мәчетләр дә күп булыр, бик зиннәтле дә булыр, тулы да булыр ләкин ул тулылыгында да, берәүнең йөз дөясе шиккелле ди Пәйгамбәребез с.г.в. Юлга чыгам дисәң бусы аксак, бусысы туксак, бусысы бөкере, берсесенә дә утырып булмый ди. Әллә кайда китәсе юк, язлар җиткән вакытта, җыештырыйк әле дигән чагында вакытта субботникка күпме кеше килә, бөтенебезнең эше күп, мәчетне җыештырырга да, башка бер изге эшкә дигән вакытта да тотынучы бик эз була. Шул Пәйгамбәребезнең әйткән йөз дөя шикеллек, берсе дә эшкә ярамый дигән кебек була. Миллионлаган шәһәрнең ярты миллионы мөселминнар, шушында да ничә мәчетебездә җомгада булган кешеләрне санап карасак, йә башка төшләрдә килгәннәренә Аллаһның рәхмәте төшсен, башкаларга да Аллаһның рәхмәте дә һидәят булсын. Без сорыйк аны, әгәр шушысы да булмый тора торган булса, ул вакытта, турыдан туры Аллаһның челтәсе дә, Аллаһның газаплары төшеүе мөмкин. Күрәбез менә дигән игеннәребез өлгереп килә Аллаһка шөкер, менә дигән һавалар, менә дигән җәйләре булды, миллионлап бодайлар, игеннәр хәзер аптырадылар да кайда куерга урын да таба алмыйлар, тагын да аптыраштылар, тагын да Аллаһ Тәгалә арттырып бир, икешәр-икешәр өлеш иттер Аллаһ бир, шуның шөкранасын кылыйк та, Аллаһы Раббул Гыйззә мәчеттә генә, җомгаларда гына түгел, бәлки һәр көнебездә, һәрбер сәгатебездә Аллаһның зикрендә утырып, йә бу золымнән үзебез дә ерак булып башкаларны да җәбер-золымга бирмәслек иттереп чын Аллаһның бәндәләре булып яшәүләребезне Аллаһ Раббул Гыйззә насыйп әйләсә иде **Әл-Җәббәр** –җәберне кылучы бик тә дигән сүз, аның фыйгыле була, **мәгънәсе** чыккан сөякне урынына кую, төзәтү дигән сүз була, **икенсе** мәгънәсе җаена салучы дигән сүз, **өченче** мәгънәсе тәзәтүче була, **дүртенче** мәгънәсе көчләп булса да бер эшне эшләтүче дигән була. Әгәр дә Аллаһның бу исеме булмаса, сыйфаты эшләмәсә иде Аллаһ сакласын. Синең авызыңа капкан бер кисәк икмәгең дә, йә сарык ботыннан пешкән ике кисәк ите дә, күзеңә, колагыңа, йә чәчеңә үсергә ничек барып җитер иде син белмисең дә аны, өйдә краннан су акмаса ни эшләргә дә белмисең аптырап чабасың, бер аз тегеннән-моннан бора башлыйсың, булмаса тизерәк шылтыратасың слесар кайда кил әле, төзәт әле, эзерләп куясың анарга кирәкле әйберләрен.

Ә Аллаһ Раббул Гыйззә бернинди слесар чакырмаслык иттереп ниткән, Ашадың шушы бер урыннан бөтен төшеңә, монда да чәч үсә, кайда гына үсми, күзең дә күрә, колагың да ишетә торган була, бу бозыла башлады икән анысы да шушы Аллаһның яратканында нинди булса да кимчелеге килде дигән сүз. Аллаһ Раббул Гыйззә исенә төшерә торган була, аны дөньяда да күрәбез. Дом управлениеда слесарларның әзерәк баш төзәтергә акчалары юк икән, моннан кранны борып куя да чабалар безнең су килми дип, йә бүтән төрле төштә, шул ук әйбер килеп чыга, аннан соң җылыйсың майлыйсың, тагын урын да китә торган була, шуның өчен Аллаһ Раббул Гыйззә ул авырулары белән дә искә төшереп тора кем хуҗа икәнлеген. Монда да бу Аллаһның **Әл-Җәббәр** исеменең гамәлгә ашыуы, тагын да китапларыбызда күренә **Әл-Җәббәрнең** мәгънәсе хакында.

**Әл-Җәббәр** дигән сүз үзенең теләгәнен гамәлгә ашыручы, Аллаһ Раббул Гыйззә. Берәү дә Аллаһның тәкдиреннән чыга алмый, җир-күкләр дә, ай-кояшы да, Әдәм балалары да, микробы да, берсе дә Аллаһның теләгәненнән бер кайда да китә алмый.

Һәм теләгәннәренә бәндәләре мәҗбүр итеп үтәттерүче Ул, ягъни.

Җәбер, золым дә Әдәм баласына килешми Аллаһтан башка җәбере, явызлык иттереп

түгел. Колларына, бәндәләренә Аллаһ Раббул Гыйззә җәбер-золым куючы түгел, бәлки мәҗбүр итеп үзләренең файдасына дөнья-ахирәт файдаларына булган эшләрне Аллаһ Раббул Гыйззә кылдыручы, теләсәң теләмәсәң дә күпме күзеңне чыкырайтып йөргән булсаң да, һичкем беркем йокламасын выкыты җитә торган була барыбер йоклата Аллаһ Тәгалә, чөнки аннан соң син яңадан йөри алмыйсың, җәбер түгелмени бу, җәбер белән Аллаһ Раббул Гыйззә мәҗбүри тә торган була.
Бу тәфсир галимнәреннән монысы **Әл-Җәббәр** исеме бөтен бәндәләрен, барлыгын Үзе теләгәнчә мәҗбүр итеп йөртүче.
Ибн Җәлиф хәзрәтләре әйтә **Әл-Җәббәр** бөтен халкынын, халык дигән сүз кешеләр генә түгел бөтенесенең эшен төзек итүче, урынына җиткереп кылучы. Әдәм баласына гына Аллаһ Раббул Гыйззә ничек тели, шулай йөрергә мөмкинлек бирде, ләкин җир күкләре ничек тели шулай булган булса әллә кайчан чәлпәрәмә килеп беткән булыр идек.
Һәм аларның арасында өчен аларның яраргылыгына, аларның файдасына иттереп эш итүче эш ди. **Әл-Җәббәр** дигән Аллаһның исеме **дүрт** хәрефтән тора саны **206** **ج** **- “Җим”3**, **ب -“Бә” 2**, **ا -“Әлиф” 1** **ر -“Ра” 200** була, шуларның бөтенесе бергә **206**.
Шуның өчен дә Аллаһка бер ялвару дога белән омтыла торган булса **206** тапкыр **Йә Җәббәрү Йә Җәббәрү** дип әйтү тиешле була. Бу исемне әйтү бәрәкәтеннән әйтәләр берәүләр шушы Аллаһның Әл-Җәббәр исемен, яки йә Җәббәрү дип **21** тапкыр һәр көнендә әйтә торган булса Аллаһ Раббул Гыйззә бөтен явызларның залимнәрнең явызлыгыннан бу бәндәне саклар. Берәү шушы Аллаһның **Әл-Җәббәр** исемен үзе әйтүне гәдат иттереп торган булса, бәндәләрнең арасында мәххәбәт тә булыр, сүзе дә үтә торган булыр һәм көнчеләрнең көннәүеннән төшеүеннән явыз, кара күзләреннән дә Аллаһ Раббул Гыйззә ул бәндәне саклар ди . **Йә Җәббәрү, Йә Аллаһ** дип әйтүне үзенә гадәт итү Аллаһ Раббул Гыйззә һәр бер кеше явызлыгында танылган түрәләрнең янына керә торган чагында гәдәт итсен ди. Барып керер алдыннан ЙәҖәббәрү, Йә Аллаһ дип Аллаһка тилмереп сораган чагында Аллаһ Раббул Гыйззә тегеләрне йомшатыр ди бер золымнәрен кисер ди. Шушының белән менә без күрәбез Аллаһның зикренең олылыгын һәм **Әл-Җәббәр** исеменең олылыгын.
Абдуллаһ ибн Гусна р.г. әйтә Дөреслектә бер кеше Йә Расул Аллаһ АРАБ. Ислам шәригәтләре бик күбәйде ди, тәхәрәт тә, гөсел дә коен намаз да укы, ураза да тот ди, күбәеп китте миңа ди.
Йә Расул Аллаһ бер нәрсәне өйрәт миңа ди шуны үземә гадәт иттереп алыйм ди. Ни эшләтәсе килгән колыннан, сахрадан бер гарәп Пәйгамбәребез с.г.в. әйтә. Бик күбәйсә шунсы ди, Аллаһны искә алу, Аллаһка зикреннән синең телең китмәсен ди, гел әйтеп тора торган була ди. Аллаһның зикрен күп әйткән кеше намазын да үтәр, уразасын да тотар, гонаһ-азгынлыклардан да Инша Аллаһ сакланыр. Аллаһ Раббул Гыйззә анарга күңеленә салачак.
Абдуллаһ ибн Аббас р.г.дән риваят ителә, ул әйте Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтте ди.
Шайтан микроб шикелле итеп Әдәм баласының йөрәгенә барып җитәргә тырыша ди .Пәйгәмбәр с.г.в. әйткән иде бит шайтан ул тик кенә тормас кан тамырларыннан йөрер, ураза тотканнарның кан юлларын таррак итербез. Әдәм баласының күңеленә керергә маташыр, Аллаһны искә алса, хәннәсе хәннәсе дигән сүзе. Йомышыр ди, Бөрешеп китәр ди әгәр берәү Аллаһ дип әйтсә. Аллаһка ялвара торган булса, Аллаһны күңеленә төшерә торган булса, ул вакытында күңеленә йөрәгенә барып маташкан шайтан бөтеннәй бөрешер бетер вәсвәсәсен үти алмас.
Әдәм баласы Аллаһның зикрен онытса, Аллаһы искә алуны гәдат итмәсә, йә оныта торган булса, шайтан моның күңеленә керә торган булып, ялап куер ди Пәйгәмбәребез с.г.в. Аллаһ Раббул Гыйззә мәрхәмәтле-шәфкатле булган Аллаһның бәндәләре булып яшәүләрне, бөтен җәбер золымнәрдән дә һәр кайсысыннан остен булган **Әл-Җәббәр**

Раббыгыз үзенә тапшырсын яшәүләребезне насыйп имин кылса иде.
Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын. Әмин!

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ "ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ" МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреrgә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәяду җомгаларны хормәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем

Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

**السلام عليكم و رحمة الله و بركاته**

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

***11 –нче ВӘГАЗ***

**<u>Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)</u>**

## <u>*АЛЛАҺНЫҢ* ӘЛ- МУТӘКӘББИР *ДИГӘН ИСЕМЕ*</u>

**Әл- Мутәкәббир Җәләлү** дигән исеменә килеп ирештек һәм бүген җомгада Аллаһ насыйп итсә Аллаһ Раббының шушы исеменең мәгънәләрен аңлауга багышламакчы булам

وَ مَا تَوْفِيق إلاَّ بِ الله العَل الغَظِيم!

Аллаһ Раббыгызның шушы мүбәрәк исеме Көръән Кәримдә ни бары бер тапкыр гына кайсыбер исеменәре шикеллек 99нан кайберләре Көръән Кәримдә кат-кат әйтелгән булса да бу исеме Аллаһ Раббыбызның **Әл-Мутәкәббир** исеме Көръән Кәримдә ни бары бер тапкыр Хәшер сүрәсендә генә килде.

Ул Аллаһ Раббың анардан башка тәңре юк, ялгыз Узе, чын хуҗа да изге дә тынычлык именлекне дә бирүче, иманлы бәндәләрнең иманнарын да дөресләүче, бөтен барлыкка чын хуҗа булган эш-күәт кодрәтендә гыйззәтле булган җәбер белән дә явызлыкны туктатучы Әл-Муттәккәббир Ул Аллаһ Анарга тагырга матышкан кимчелекләрдән бөтенләй, бөтенсеннән пак Ул Аллаһ дип бу аят Кәримәдә әйтелә кайсы вакытта бу исем Көръән Кәримдә Әл-Кәбир дип тә килә. Менә Хаҗ сүрәсендә

Аллаһ Раббыгызның бу Мүттәккәббир дигән исеме Әл-Кибр дан алынган асылында өч хәреф бар “ ك” ”ب“ ”ر“. الكبر дигән сүзе кибар булса яшнең олылыгы булыр иде йә бер нәрсәнең олылыгы булыр иде йә бер нәрсәнең олылыгы Мында исә Әл-Кибр дигән сүз العَظَمَةُ وَ كَذَلِكَ الكِبْرياء

Олылык дигән сүз була, олылык الكِبْرياء дә шул мәгънәдә килә Асылда الكِبْر диеп без аны үзебезнең телебездә гел эшләтүебез тәкәберлек дип аңлыйбыз тәкәберлек дигәч барыбыз аңлыбыз нәрсә турында сүз баргынлдыкны бик тәкәбер була, кара нинди тәкәбер була дип әйтеп куябыз тәкәбер исә киблек масаю, мактану дигән сүз юк төштән дә үзен күрсәтергә маташу. Чынында исә Аллаһтан башка бу хур бер сыйфат сүгенә торган ярамас бер сыйфатлардан Пәйгәмбәребеә с.г.в. бер хәдис шәрифтә әйтә Аллаһ Раббыгыз әйтә ди алай булган вакытта бу сүз Аллаһның сүзе була Көръән Кәримгә кермәгән, бәлки хәдис күдси

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: يقول الله تعالى: الكِبْرياءُ رِدَائِى وَ اْلعَظَمَةُ اِزَارى فَمَنْ نَازَعَنى وَاحِدًا مِنْهُمَا أَقْذِفْهُ فِى النَار . رواه مسلم و ابو داود

Муслим , Абу Дауд риваят итә Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә тәкәберлек, олылыну Ул

миңарга хас ди, берәү шуны миннән алырга маташса ди сөйрәп ул бәндәне утка гына ташлаячакмын Мин ди. Берәүдән сөйрәп аласыңмы киемне талаган булып чыга тора Аллаһ Раббул Гыйззә дә Үземнеке дигән сүзе Минеке ул Миннән башка бер кемгә ярамый, бер кемгә дә килешми. Тагын да Аллаһ Раббул Гыйззә Көрьән Кәримдә

Җир йөзендә хаксызга тәкәберләнеп йөргән бәндәләрне Мин үземнең аятләремнән читкә тайпылдырырмын ди. Җир йөзендә тәкәберләнеп, мин ким дип мактанып йөргән олыланырга маташканнарны аларга Үземнең хак аятләремне Көрьәнемне дә аңламаслык итермен ди Аллаһ Раббул Гыйззә, чөнки тәкәберләнгән бәндә олылана-олылана хаклыкны күрмәс була торган була Әле Әбсәләм авылында мәчетебезне ачкан вакытыбызда да бер абыстай сөләде иң олы апалардан Гөлчирә апа искиткеч сүзләрне сөйләде Бик күп сез мында җыелгансыз, мәчеттә салдык Аллаһка шөкер, университетлар, институтлар бетергәнсез, зур дип үзегезне саныйсыз, үзегез бәрәңгедән кортны да бетерә алмыйсыз диде. Аллаһ бар ди, менә чыннан да шушылай Әдәм баласы җир йөзендә күпме укыса да үзенең наданлыгын гына белә укыган саен белгән саен, йә шушыны да белмәгәнмен дип үзенең кем икәнлеген аңларга тикле һәр вакытта да кылган эшләре белән белгән белемнәре белән, салган биналары белән тәкәберләнергә чамадан узырга тиеш түгел Аллаһ Раббул Гыйззә кисәтеп Көрьән Кәримдә

Шушылай иттереп Аллаһ Раббың җир йөзендә җәбер золым кылып йөрүче мин ким дип олыланып тәкәберләнеп йөрүче бәндәлрнең күңеленә Аллаһ Раббул Гыйззә тамгасын каплар ди, каплап куер хаклыкны күрмәс булыр үзенең кем икәнлеген аңламас булыр

Искиткеч кисәтү сүзен дә әйтеп куя, шуның шикеллек, тәкәберләнеп, тамчы кылган хезмәтләре белән мактанып йөргәнләренә дөреслектә безнең аятләребезне, гәләмәтләребезне ялганга тоткан, безнең аятләребездән олыланган бәндәләргә күкнең капкалары да ачылмас күкнең ишекләре дә ачылмас, җәннәткә дә кермәсләр, дөя энәнең күзенә кергәнчегә кадәр ди, дөя энәнең күзенә керә алмаган шикеллек, җәннәткә дә керә алмаслар, шулай иттереп азгынлык бозгынлык кылып йөрүчеләргә җәзәсен бирербез дип Аллаһ Раббул Гыйззә кисәтә, рәхмәтеннән мәхрүм булуына, дөньяда хәттә үзенең юлын табуга да Аллаһ Раббул Гыйззә мәхрүм итүгә Әдәм баласының тәкәберлеге мин ким дип борынын чиеп йөрүне Аллаһ Раббул Гыйззә сәбәп иттереп күрсәтә. Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә

قال رسول الله صلى الله عليه وسلملاَ يَدْخُلُ الجَنَّةَ اَحَدٌ فِى قَالْبِهِ مِثْقَالُ حَبَّ ةِ خَرْدَل مِنْ كِبْر

Берәүнең күңлендә горчица орлыгы, йә икмәк орлыгы дип әйтик ди, кадәр генә тәкәберлек булса ул бәндә җәннәткә кермәс ди Пәйгәмбәребеә с.г.в. тәкәберләнү, мосаю, үзен олыга санап маташу йә үзен башкалардан үзен олыгы санатып маташу булды икән горчица орлыгы кадәр генә ул бәндә җәннәткә кермәс

وَ لاَ يَدْخُلُ النَّار اَحَدٌ فِى قَالْبِهِ مِثْقَالُ حَبَّةِ خَرْدَل مِنْ يمَان

Дип Пәйгәмбәребез (с.г.в.) әйтә һәм күңелендә горчица орлыгы кадәре генә бөртек кадәр генә иман чаткысы булды икән ул бәндә утка да кермәс ди. Бу сүздән шунсы аңлашыла тәкәберлек белән иман икесе бер йөрәктә җыела алмый иман булганда тәкәберлек булмый, тәкәберлек булган күңелдә иман урнашуы мөмкин түгел. Шунарга күрә дә иманлы кеше һәр вакытта тәкәберлектән, тамчысыннан да арынарга тиешле Шуның өчен Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтте

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم:

Кем Аллаһ хакында түбәнчелекле булса, үзен түбән тота торган булса, ул бәндәне Аллаһ Тәгалә Күтәрер, берәү тәкәберләнә торган булса, аны Аллаһ Тәгалә аяк астына калдырыр ди күпме җир йөзенә җәберлек золымлык, явызлыкка маташучы, бөтен дөньяны басып алам да, бөтен дөньяга хуҗа булам дигән дигәннәр әллә кайчан гына гасырлар буена түгел күз алдыбызга да хур булырдылар түбән булдылар Аллаһка шөкер. Тагын да Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: َالأ ا ُخبِرُكُمْ بِأهْلِ الجَنَّةِ؟

Җәннәт әһеле кемнәр икәнне әйтимме сезгә ди пәйгәмбәребез с.г.в.
Әйт Йә Расүлу Аллаһ әйт җәннәт әһеле кем ул.

قَالوا: بَلَى

وَ يَقُول: كُلُّ ضَعِيفٍ مُتَضَعِيفٍ لَوْ أ َقسَمَ عَلَى اللهِ لأبَرَهُ.

. Һәр бер зәгыйф, мескен генә булып йөрегән көче була торган булса да күкрәк киерелеп йори торган , башкаларны тапап йөрмәгән, шул Аллаһ хакы белән Аллаһ исеме белән ант итә торган булса Аллаһ Тәгалә аның сүзен дә Аллаһ Раббул Гыйззә изгегә чакыра, менә шулардыр җәннәт әһеле дип Пәйгәмбәребез с.г.в. Үзен түбәнчелектә тоткан. Моннан соң Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә

ثُمَّ قَال: َالأ ا ُخبِرُكُمْ بِأهْلِ النار؟

Утта кемнәр икәнлеген әйтимме сезгә. Ут әһеле кем, җәһәннәмнең әһеле кем

قَالوا: بَلَى

وَ يَقُول: كُلُّ عُتُلٍ جَوَاظٍ مُتَكَبِّر!. كتفق عليه

Расулу Аллаһ әйте. Киереләнеп кәҗәләнеп, мактанып, масаеп йөрегән мүтәкәббирләрнең бөтенесе җәһәннәм әһеле булачак дип Пәйгәибәребез с.г.в. әйтә. Шуның өчен ул халык арасында да, йортында да, Аллаһ каршында да бер вакытта да тәкәберлек, мактану сыйфаты булу мөмкин түгел. Үз кабереңне белү ул аерым, гордость дип әйтәләр аны, үзен гыйззәте нәфес, үзеңнең кадерен белү. Ләкин гордыня була торган булса, масаеп, мактанып борынын чыю була торган булса Аллаһ каршында да, бәндә каршында да хур булган бер сыйфатлардан . Хәзрәти Абу Бакр р.г. дан бер сүз риваят ителә, ул әйтә

و روى عن ابى بكر انه قال: لاَ يَحْقِرَنَّ اَحَدٌ اَحَدًا مِنْ اْلمُسْلِمِين فَاِنَّ صَغِيرًا اْلمُسلِمِينَ عِنْدَ اللهِ كَبِير

Һич берәүгез, мусулманнардан берәүне хур итә күрмәсен, чөнки мусулманнарның иң түбәне, иң кечкенәсе Аллаһ каршында олы ул ди, күңеле белән иманы белән, калган изгелекләре белән ул Аллаһ каршында олы, шуның өчен дә беркемне дә, аның кара киеме нинди генә, нинди фәкир генә, мының дәрәҗәсе шул гына дип бер кешене дә кимгә саный күрмәгез ди Хәзрәти Абу Бакр р.г.

قال الاحنف ابى قيس: عَجَبًا لِاِبْنِى آدَمَ يَتَكَبَّرُ وَ قَدْ خَرَجَ مِنْ مَجْرَى اْلبَوْلِ مَرَّتَيْنِ!

Ахнаф Абу Кайс әйтә Әдәм баласына исең китерлек ди. Тәкәберләнә, масая ди. Бавыл чыккан урыныннан ике тапкыр чыккан ди үзе дөньяга килде ди. Бавылне беләсез инде кайдан чыккан, шул урыннан ике тапкыр дөньяга чыкты, берсе атасыннан туганда, берсе анасыннан туганда, анда да мин ким дип масаеп йөри, борнын чия әле ул ди.

و قيل: مَا لِاِبْنِى آدَمَ وَ اْلكِبْرِ! تَقْتُلُهُ شِرْقَةً, وَ تُنْتِنُهُ عِرْقَةً وَ تَقْتِلُهُ بَقَّةً

Һәм бер мисалда әйтелә, Әдәм баласы ничек итеп тәкәберләнә ул ди. Ничек үзен олыга санап, үзене борынын чиер ди. Бер тыгылса шуның белән үлеп китә. Сөяк тә түгел, хава гына ялгыш урынга китә торган булса да. Шуның белән үлеп тә китә, тирләре белән сасый, бер кандала белән рәнҗи. Арыслан да түгел, кандаланы беләсез канын эчә торган, шул кандала бер төшенә тия торган булса, йоклый алмый, астын өскә әйләнеп йөри торган була, шулай була торып та әдәм баласы ничек иттереп тәкәберләнер ди, шуның өчен тәкәберләнү, олылану тик Аллаһка гына килешле булган бер сыйфат. Шуның өчен дә Әл-Мүтәкәббир

المُتَكَبِّر – هُوَ المُتَعَالى عَنْ صِفَاتِ الخَلْقِ المُنْفَرِدَ: العَظَمَةِ وَ الكِبْرِيَاء وَ لاَ يَلِيقُ بِغَيْرِهِ تَعَالى

Олыланучы дигән сүз була, олылык һәм тәкәберлек белән тик Ул гына остен булган зат Аллаһтан башка бер кемгә дә килешмәс дигән сүз. Бу исемне зикр иткән вакытыбызда Йә Мутәкәбиру Йә Мүтәкәббирү дип әйтергә тиешле була, Әл-Мутәкәбиру, Йә-Мутәкәбиру диеп әйтергә була., боларның саннарын санаган вакытыбызда **“م”- хәрефе 5**, **“ت” хәрефе 400**, **“ك” – хәрефе 20**, **“ب” – хәрефе 2**, **“ر” - хәрефе, 200**, **627** тапкыр

әйтелә торган була, китапларда күренә бу исемнең ни кадәр олылыгын. Бер йортка, бер илгә, авыл-шәһәргәме зур зәхмәтме, сугыш-золыме, килә икән, шулардан саклык өчен, я бакчаңның, йә йортыңның **94** төшенә җомга көн таңда Аллаһның шушы Әл-Мүтәкәбир исемен язып чыга торган булсаң дошман керә алмас ди. Шул кадәр тапкыр Аллаһка тапшырып, Аллаһка ялвардың исә Аллаһ Раббул Гыйззә Мутәкәббир Ул, дошманга остенлекне бер кайчан да бирмәс ди. Яңадан да берәү йөзегендә бер өй почмаклы көмеш йөзеккә шушы Аллаһның исемен язып янында йөртә торган булса, йә баш киемендә йөртү бик тә хәерле Аллаһ Раббул Гыйззә бер залимнең, җәбернең дә золыме, җәберлегенә бу бәндәне битараф кылмас, бу бәндә һәр вакытында да өстен булыр ди. Әл-Мутәкәббир дигән Аллаһның исемен көмеш йөзеккә язып янында йөртә тоган булса, әмма кәгазгә язып ансын **101** тапкыр язылa, Әл-Мутәкәббир, яки Йә Мутәкәббир дип **101** тапкыр язылa да һәм баш киемендә йөртелә торган була. Аллаһ Рабул Гыйззә бу бәндәнең дәрәҗә һәм кадерен арттырачак, бу бәндәнең сүзе дә үтер, явызлыкның, залимнәрнең зөлеменнән Аллаһ Раббул Гыйззә саклар ди. Зикр иткән вакытыбызда һәр көн иртә намаздан соң **264** тапкыр әйтү киңәш ителән бәндәне явызлыклардан, золымнәрдән саклау сабәп булыр ди. Аллаһ Раббыбызның рәхмәт, ризасына ирешүгә сәбәп булыр ди. Бу әйтелгәннәре ләкин әйткән вакытыбызда да ул язуга таянып түгел, бәлки Аллаһ Раббабазның Үзенә таянып, Үзенә ялварып, чын ихлас белән, тулы иман белән язган вакытта булсын, йә аны зикр иткән вакытында булсын Аллаһның Үзенә тапшырылган вакытта АРАБ. Хуҗам да Раббым, Аннан өстен хуҗам юк дип Аллаһка тапшыру була һәм һичшиксез Аллаһка берәү тапшырды икән ул бәндәнең эше уң булуында тамчы кадәр дә шик юк. Аллаһ Раббул Гыйззә Әл-Гәзизу Җәббәрү Мутәкәббир булган Аллаһ Раббы һәркайсыларыбызга иманнарыбызның ныклыгын әйләсен, гәмәлләребезнең кабуллыгын кылсын.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәядү җомгаларны хөрмәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем
Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме

шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җомга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

### *12 –нче ВӘГАЗ*

### <u>**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**</u>

## <u>*АЛЛАҺНЫҢ* ӘЛ- ХАЛИК *ДИГӘН ИСЕМЕ*</u>

**Әл-Халик** исеменң мәгънәсен аңлауга тырышачыкбыз

وَ مَا تَوْفِيق إلاَّ بِالله العَل الغَظِيم!

Тәүфик Аллаһтан. Көрьән Кәримдә Аллаһ Раббыгызның Әл-Хәлик дигән исеме күп сүрәләрдә кат-кат иттереп киләләр. Кайсы бер исемнәр Аллаһның ни бары бер тапкыр гына килә Көрьән Кәримдә. Әл-Хәлик дигән Аллаһның сыйфаты менә бу исеме Көрьән Кәримдә менә шкл хәтле сүрәләрдә кат-кат итеп килә. Шушысының берсендә Әнгәм сүрәсендәгесен мәгънәсен кары торган булсак. Әл-Хәлик дигән сүз ни дигән сүз?

Ул җир-күкләрне ис киткеч төзеклек белән бар итүче Аллаһ Раббыгыз. Аның бит җәмәгәте дә булмады.

Һәр нәрсәне Ул юктан бар итте, һәр нәрсәнең ни икәнлеген дә Ул белүче, менә Ул Аллаһ. Җик-күкләрне дә бар иткән, һәр нине дә бар итүче, һәр нәрсәнең яратылганынң серләрен дә белүче, нигә яратты, ни булачак, ничек үрчиячәк, соң нәтиҗәсе ни белән булачак, шуның төрлесен белүче, менә Ул сезнең Аллаһ Раббыгыз тәрбиячегез. Раббәкүм дигәне тәрбиячесе дигән сүз була, юктан бар итте дигән генә түгел, көн саен сиңа су-хавасын да бирүче, ашарлык ризыгын да бирүче, яшәтүче дә, тәрбиясен дә бирүче АРАБ. Аннан башка тәңре юк яглгыз Үзе

. Һәр бер нине юктан бар итүче, яратучы Ул

Анарга бәндәчелекне күрсәтегез, сезне юктан бар иткән булгач хуҗа икәнлеген танып аңарга бәндәчелек күрсәтә күрегез. Анаң бәндәсе икәнлегегезне танытыгыз

Һәр нигә вәкил Ул да, вәкил дигәне таянычы да, юктан бар итеп суга ташлаган йөмышка шикелле иттереп кенә агызучы түгел, һәр минут-секундында һәр көнендә, гомер буена шуның вәкилендә булып торучы

Анарга күзләр ирешмәс, Ул бөтен күзләргә ирешер.

һәр нәрсәгә мәрхәмәт-шәфкат белән хәбәрләрен белеп торучы Ул. Аллаһ Раббул Гыйззә ди. Менә мында күрәбез Аллаһ Раббыбызның Әл-Хәлик сыйфаты һәр нине яратуга, һәр дигәннән соң кукләрне дә, җирләрне дә, анда булган әдәм балаларын да, хаываннанрын да, үсемлекләрен дә, бөтенесен дә бар итүче Аллаһ . тагын да Зөмәр сүрәсендә күрәбез

Һәм Аллаһ Раббың коткарыр Үәзенең рәхмәтен өмет итеп, газабыннан куркып, бәндәләре котулу белән

Аларга начарлык та ирешмәс һәм алар кайгырмаслар да.

Аллаһ Раббыгыз һәр нине яратучы, һәр бер нәрсәне яратучы Ул ди.

Һәр нинең вәкиле дә Ул Яратып кына ташлаучы түгел, бәлки шуны тәрбия итүче дә Ул.

Күкләрнед дә, җирләрнең дә ачкычы Аныкы.
ләкин кәфердә булган Аллаһның берлегенә ышанмаган, Аллаһның аятләренә, көфердә булганнар, ул бәндәләр үтенеч хәсрәттә генә калачак ди. Хәлик дигән сүз менә мында Аллаһ Раббул Гыйззә бөтен әйберләрне яратучы ди. Таган бу аят кәлимәнең дауамында да, вәкил дә һәр нәрсәгә диде, берәү урындыкны ясады йә көрәк сабы, сатты да бетте дә, иртәгә үк сабы сынып чыга торган булса, китерсә, мин ни эшлим, бар ди. Соң моны эшләгән вакытта көрәкнең сабында ботагы да булган, шуннан сынды чыкты карап алырга иде инде, күзең бар ди. Аллаһ Раббул Гыйззә алай гына түгел, бар итеп аннан соң да тәрбия итүче. Аллаһ Раббул Гыйззә үрчеүен дә, үсемлеген дә, микробын да, хайванан да, кешесен дә бар иткәннән соң шуның давамын кыямәт көненә кадәр үрчеүен дә Аллаһ Раббуо Гыйззә тәкдир итте. Шулай иттереп булдыручы бармы, магнитофон, йә телевизор аласың да, бер аз торды эшләде, бер нәрсә булды да, сүнде, алмаштырырга булмый, яңасын алырга кирәк, яхшы булыр иде, 5-6 ел эшләгәннән соңяңа модельга әйләнә торган булса бер кнопкасына бастың да, экраны зуррак булды, йә шәберәк булды Аллаһ Раббул Гыйззә шушылай иттереп яратты һәр бер нәрсәне. әдәм баласының булдырган чамасы шушы, шуның өчен дә Аллаһ Раббул Гыйззә Ул һәрбер нигә вәкил дә
Аныкы җир-күкләр ачкычы ди. Аллаһ ачмаса, җирнең астындагы байлыгына да бер кем ирешә алмый күкләргә дә оча алмый космосларга оча башлаган вакытта кайберәүләр Гагариннар очкан вакытта менеп төште безнекеләр, күрмәделәр анда Аллаһны диләр, хәзрәтләр әйтә нигә син анда  йолдызда аягын салып утыра диеп уйлаган идеңме ди. Алай түгел анда да чыга алмыйсың Аллаһның ризалыгымы, рөхсәтеме булмый тора тоган булса.
Җирнең күкнең бөтен якларына чыгыгыз очыгыз
Бер кайда да чыга да алмассыз , бара да алмассыз Аллаһ Раббыгыз сезгә көч-күәт бимәсә, ул көч-күәт ясаган ракеталары, спутниклары башкалары булсын, Аллаһ биргән зиһене беләән , Аллаһның булган җиреннән ясалган нәрсәләрдән дип әйткән. Шуның өчен дә үзә дә һәм булдырган әдәм баласының Аллаһның яратканы санала, шуңа күрә дә җир-күкләрнең ачкычы Аллаһның Үзенеке боларны күрмәгән бәндә хәсрәткә үкенечтә калуы генә калачак шиксез хәсрәттә үкенечтә калуы бу доньяда ук да кәферлеге белән барыбер бер көнне чәчләрнең агарганнан билгеле күргәнлеге җитә торган була анда да сизә, әдәм үткән икән гомер, бу үзеннән үзе генә булган дип уйлаган ибем. Үзгәрешләр бар икән, акыл да үзгәрә, тән дә еллар үткән саен , ярый әле Аллаһ Раббул Гыйззә, 60-70ендә булса да тәүфикка басып, тәүфик юлыны барып, намазына бөгелеп, Аллаһның кушканына ахыр гөмерендә генә булса да түбәләрен кылып калырга насыйп иткән була. Ул бик хуш, ләкин соң минутында гына, тамагына килеп терәлгән вакытында гына әҗәле җиткән вакытындаисә ни булыр, шуның өчен дә андыйларны Аллаһ Раббул Гыйззә
Алар үкенечтә калачаклар, банкротка чыгачаклар ди Аллаһ Раббул Гыйззә, чөнки анда кайтканнан соң икенче донья бар әле дип, күрмәгән, белмәгән, ишетәсе дә килмәгән доньясы бар  Аллаһ хозурында хисабы бар. Ул вакытында көфер дә булганмы. Кыяммә сүрәсенең ахырында күрәбез Аллаһ Раббул Гыйззә бөтен әдәм балаларын, Бөтен хайваннарын , бөтенесен тергезә дә хисапны ала, гонаһлары өчен кимчелеклә өчен ул генә түгел, бер-берсенә булган үчләре дә, кешеләрнең әгәр дә изгелегең җитмәсә, берәү сине рәнҗеткән булса, гәйбәтеннңне чәйнәгән булса Аллаһ Раббул Гыйззә анардан изгелекләрне алып бирә ди, чөнки анда башка түләүе дә юк, әгәр дә ул изгелекләре булмаса, әҗер саваплпры, синең гонаһларың аңа яздырыла торган була кыямәт көнендә, әдәм баласына гына түгел, хайванарга да кайсысы кемне сөзгән, типкән, хайваннар да барберсеннән үчләрен алырлар, чөнки Аллаһ Раббыгызның Әл-Гадел дигән сыфаты бар,

гаделлек белән хөкем итүче. Хайваннар бер берсеннән үчләрен алганнан соң Аллаһ Раббул Гыйззә әйттерер, күнү турада, инде туфрак булыгыз дип, чөнки хайваннарга җәннәт-җәһәннәме юк. Доньяда әдәм бмлаларына хезмәткә яратылды, анда да гаделлек белән хөкем ителде бер берсеннән үчләрен алдылар да, соңыннан күнү турада түфрак булыгыз дигән чагында кәферләр әйтерләр ди.

Доньяга туып әдәм баласы булып яшәгәнче, хайван гына булсам хәзер менә шушылай иттереп туфрак кына булган булыр идем дә беткән булыр иде шул вакытта диеп өмет итер ди, ләкин ул көндә Аллаһның хозурында хич чиксез хисабы бар, Хиҗр сүрәсендә Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә

Дөреслктә яратып без әдәм баласын, балчыктан-туфрактан, тигезләнгән туфрактан, туфрак ни? Әле генә аны килалап сата башладылар

Әдәм баласыннан алдан җеннәрне дә яраткан идек без кайнар уттан

Аллаһ Раббың фәрештәләгә әйткән иде ич, дөреслектә Мин әдәм баласын балчыктан, тигезләнгән туфрактан яратырмын дип аны тигезләп бар иткәннән соң анарга сүҗдә кылучылардан булыгыз дигән идек

Бөтен фәрештәләр сәҗдә кылдылар иблистән башка, ул сәҗдә кылучылардан булучыны булучыдан баш тартты ди Аллаһ Раббул Гыйззә. Аллаһ Раббул Гыйззә кешенең яратылышын, нәрсәдән яратылышын да сөйли Көръән Кәримдә балчыктан, туфрактан яраттым ди. Фәрештәләргә шуны алдан ратканчы сөләгәнне әйтә Көръән Кәримдә хәттә шул вакытында

Йә Раббыбыз Аллаһ ул җир йөзендә бозыклык кылып, кан түгеп йөрүчеләрне яратасыңмени диеп фәрештәләр соранганлыгын да Көръән Кәримнең икенче аятләрендә күрәбез, әйтерсеңдә аннан элек шундый хәлләр булган шикеллек, шул вакытында Аллаһ Раббул Гыйззә җеннәрне мин, кешеләрдә дә алда уттан яраткан идем, бөтен фәрештәләргә сәҗдә кылырга куштым иблис баш тартты сәҗдә кылмады, шул вакытта әйтте Син аны туфрактан яраттың, мине уттан дип тарткалаша башлады ди, анда кайсы берәүләр әйтәләр ничек иттереп Аллаһ Тәгалә үзеннән башкага сәҗдә кылырга кушмай, ә бөтен фәрештәләргә Әдәмгә сәҗдә кылырга кушкан ди. Бу ничек дип әйтә торган булса, ә һәркем нәрсәне булдырган булса, шуны ярата, бер коймак кына пешерсәң дә, әллә нинди пешкән бәлешләр булса да, үзеңнеке яхшырак шикелле. Бер көрәк сапласаң да, бер балтаның сабын сапласаң да, бакчаңны казып чыксаң да, зур эшләр эшләгән шикеллек үз күзеңә күренә торган була, чөнки үзең эшлисең аны, синең хезмәтең, булдырганың ул. Аллаһ Раббул Гыйззә безне нидән булдырганын әйтә һәм шуның олылыгын күрсәтеп бөтен фәрештәләргә сәҗдә кылырга боердым ди, кешегә сәҗдә түгел, Аллаһның боерывын үтәү, Аллаһның яратканын олылау, бөтенесе сәҗдә кылды иблистан башка, ул баш тартып сәҗдә кылучылардан булудын тартынды. Аллаһ Раббул ГЫйззә тагын да этте

Әллә алар бернәсәсездән яратылдылармы?

Әллә үзләре бар ителделәрме? Кайдан килдегез алты миллиард. Кайдан килдегез, кайдан үрчедегез бу доньяга. Күктәнме газданмы нидәнме. Аллаһ Раббул Гыйззә Мин сезне балчыктан, туфрактан яраттым ди. Нинди балчыктан булыйк, ит булып туабыз бит әйтәбез дә, Ул ит кайдан килә ди. Хәзер дә кайдан килгән 60-70 гысырлар 120гә кадәр дә җитә торган була. Шул ук җир туфракта үскән икмәк тә, шул ук үләнне ашаган малны ашап, шул ук иттән гәүдәләребез үскән була. Бүген дә шул ук туфрак, шул ук туфрактан

Әллә үзләре бар итүчеләрме алар ди Аллаһ Раббул Гыйззә

Әллә ул бир-күкләрне Аллаһ юк дип йөргәннәр бар иттеләрме, алар яраттылармы

Бәлки алар иманның чынына ирешә алмыйлар

әллә аларның хәзурындамы, әллә аларныкымы Аллаһ Раббаның хәзинәләре, әллә алармы анарга хуҗалар ди Аллаһ Раббул Гыйззә шул ук газлары, нефтләре, алтын-

көмешләре ничәшәр меңләгән-миллионлаган еллар җир астында яткан Аллаһтан билгеле бер сәгаттән соң гына әдәм баласы анарга файдалану мөмкин

Әллә Аллаһка ышанмаган, Аның Халик икәнлегенә юктан бар итүче, ярату икәнчелегенә ышанмаганнар, әллә аларның баскычлары бармы Аллаһтан хәбәрләрен ишетергә ди, күтәрелделәрме алар әллә күкләргә

Ишеткән булсалар, үзләренең кайда бар ителгәннәрен, җир-күкләрнең ничек яратылганын белгән булсалар, алар үзләре бер ачык дәлмлләр белән китереп карасыннар ишеткәннәрен. Мынысын Аллаһ Раббул Гыйззә Тур сүрәсендә әйтә менә монда ул Аллаһ Раббыгызның Әл-Хәлик дигән исеменең мәгънәсен аңлауга чамалар бар. Аллаһ Раббул Гыйззә тагын да әйтә Фатыр сүрәсендә монсы

Йә әдәм балалары, бөтенегез, нинди генә милләтләр булсагыә да бөтенегез дз Аллаһ биргән нигъмәтләрне искә төшерегез

Аллаһтан башка сезне җир-күкләрдән ризыкландыручы бармы? Бүген дә көз җиткән чагында чабабыз, бүгенгегә бәрәнгесе дә, ите дә, башкасы да, ризыларны кышка әзерләү кайдан килде. Бүген дә Аллаһ Раббул Гыйззә шул ук җирдән, шул ук күктән ризыкларын биреп тора, тамчы кадәр тырышканыбыз белән, юу мин заводта эшлим токар булып дип, бер болванкыны куеп анарда пироҗкиларны ясап булмый, ясысаң да аны ашап булмый, күзләрең дә күрерлек, колагың да ишетерлек итеп Аллаһ Раббул Гыйззә күкләрдән яңгырларын яудыра, җирләрдән шул туфрактан Аллаһ Раббул Гыйззә орлыкны җиткерә торган була, шуның өчен дә әйтә:

Аллаһ Раббыгыздан башка бүтән яратучы бармы? Сезне ризыкландыручы җирләрдән-күкләрдән

Аннан башка тәңре юк, Ул бер, сезне туфрактан бар да иткән, Аннан бышка тәңре юк. Кайда гына Аллаһтан йөгереп качырсыз ди Раббы Аллаһ. Менә бу аят кәлимәләрдә Аллаһ Раббул Гыйззә җир күкләрнең дә яратун күрәбез. Аллаһ Раббыбыә бар итүче. Әдәм баласының бар итүче белән бер түгел. Әдәм баласы бар итте аннан соң инде кайбер фирмалар гарантия бирә башлады аоты ай, бер, ике, өч ел гарантия биргән була. Шул вакытта сынса, ватылса кире алып барасың да, алмаштырысың, я төзәтерсең. Аллаһ Раббул Гыйззә яшәгән саен һә көннән күәт бирә, чөнки Аллаһ Раббыбызның яратканы яратуы әдәм баласыннан аерыла. خَلَقَ дигән сүз خَلْق дигән масдардан алынган русчасында создавать, творить, выдумывать

خَلَقَ -يَخْلُقُ булса, ул вакытта тузды дигән сүз, износилось اِلخَالُقَ -يَخْلُقُ! Сүзе дә бар - лаеклы булу, яраклы булу дигән сүзе дә бар, шуның өчен дә Көръән Кәримдә.

Дигән сүзне “خ”не чыгырмыча йомшак “ح”әйтә торган булсаң, ул вакытында чәчне үтәде дигән сүз Аллаһ Тәгалә җирләрне күкләне, чәчне кырдырды дигән сүз була Аллаһ Халик урынына Аллаһ һәлик дип әйтә тарган булсаң Аллаһны парихмахер дигән була, шул чагында, шуның өчен дә тәҗвид белән урынына җиткереп укуның тиешлеген Расу Акрам с.г.в.гә Җәбрәил г.с.дә өйрәтте һәм бүгенге көнебезгә кадәр без анарга Әлхәмдүлилләһ давам итәбез. Аллай булган вакытта Әл-Халик Аллаһның исеме творец создатель , юктан бар итүче дигән сүз Карагыз Әл-Халикнең шәригаттә кабул ителгән мәгънәсен

الخَالِقُ – الفَاطِرُ المُبْلِكُّ شَيْاء, المُقَدِّرُهُ, المُوجِدُ لِلأَشيَاء مِنْ العَدَم فَهُوَ خَالِقُ كُلِّ صَانِعٍ وَ صَنعَتِهِ

Аллаһның Әл-Халик дигән исеме бөтеннән юктан бар итүче дигән сүз, анарга тикле алай иттереп яратылмаган, кемдер Анарга чертеж-план бирмәгән, менә шушылай булсын ташлары менә шушылай булсын, агачлары менә булайрак булсын дип, кәкрерәк дип. Юк, Үз чамасы белән бар итүче бер нәрсәгә охшатмаслык иттереп

المُقَدِّرُ لَهُ

Анарга бөтен тәкдирен дә билгеләүче күпме ул доньяда була. Кайчан бетә аның давамы ничек иттереп булачак, ризыгы кайдан булачак, барысын да билгеләүче

المُوجِدُ لِلأَشيَاء مِنْ العَدَمِ

Бар иткән вакытында да бөтеннәй юктан бар итүче хәттә материалына да Аллаһның хәҗәте, туфрактан әдәм баласын яратканиде, Анарга кадәр туфракны кем яраткан иде, Анарга кадәр кадәр кем бар иткән, бөтеннәй югыннын

فَهُوَ خَالِقُ كُلِّ صَانِعٍ وَ صَنعَتِهِ

Шунарга күрә дә Аллаһ Раббул Гыйззә бар итүче Ул, доньяда бүген без бар итәбез дип әйтүчеләрне дә бар итүче, аларның булдырганнарын да бар итүче Аллаһ Раббул Гыйззә, шунарга зихенен дә, шунарга материалын да, бөтен мәттәрен дә бирүче. Үзебезчә әйткәндә бар итте дигән сүз, мәгънәсе бераз аңлашыла, ләкин яратты дип әйтте икән, яратучы Ул Аллаһ. Шул вакытында Аллаһның ни өчен яратканлыгының да мәгънәсе ыңлашыла. Ничек иттереп яратканлыгы да аңлашыла. Әгәр дә Аллаһ Раббул Гыйззә бар иткән вакытында бөтен доньяны, хайваннарын, әдәм балаларын, үсемлекләрне бөтен барлыкны, сөеп яратмаган булса, тегеләй-булай гына булыр иде, бөтенесенең яртысынан артыгы брак булыр иде. Күпме заводларда әле тикшершлшр, эшләнгәннән соң да, эшләүсезе ул эшләгәнең яхшылыгын тикшерүчесе, качествосын тикшкрүчесе була, Аллаһ Раббул Гыйззә әдәм баласына карасың сокланып торырлык, бер кошының сайрауын ишетш торган булсаң, урыныңнан егылып китәрлек, шаулаган урманнары гөлләре. Ул гөлләрнең яфракларына карап торган булсаң, яныннан китә алмаслык, ничек иттереп пөхтә иттереп урынына җиткерелгән. Сокланырлык диңгездәге төрле балыклары, берсе-берсеннән олы, төрле чуарлар, берсе-берсенә ризыкка ярыйлар, тегесеннәр зуррак монсын ашый, монарга да, бөтенесенә дә ризыгын җиткерә торган була, шул кадәр тәртибе белән бар итүче Аллаһ Раббул Гыйззә хич чиксез яратып яратты, сөйгәнгә күрә яратты Аллаһ Раббул Гйззә иң дөрес мәгънәсе дә, сөгәнгә күрә дә доньяда нәрсәне генә гаеп итә башласаң, бер эт бар кара, мының колагы асылынган, кара моның койгыгы кайда борган дип әйтәсең икән Аллаһка гаеп итеп тотынысың шул вакытта Аллаһның яратканында тамчы кадәр генә гаеп юк. Берүнең эшләгән урындыгын, йә бер сызган рәсемен, йә эшләгән хезмәтен гаеп итә торган булсың, аның ачуы чыккан шикелле, бер кешегә карап күзеннән моның күзе булайрак, моның колагы болайрак диеп гаеп итә башласың, Аллаһның Әл-Халик сыфатына тагыларга маташып Аллаһның яратуын гаеп итергә маташкан булса, Аллаһның каршында гонаһлы булыр ди. Шуның өчен дә һәр кемгә әдәм баласына да хөрмәт-мәххәбәт белән, хайванына да үсемлегенәдш шуның өчен иманлы кеше, бөтен доньясына, бөтен нәрсәсенә изгелек кенә итергә тырышырга тиешле. Шуның өчен дә намазыбызны берегән чагыбызда да Әс-Сәламу галейкум вә рахматуллаһ. Миннән сиңа Аллаһның рәхмәтләре, сәләмнәре булсын уң ягыңдагы фәрештәгә дә, уң ягыңда синең белән намазда утырганнарга да, доньяда да уң ягыңда кем бар, уң ягыңда бөтенесенә синнән сәлам, тынычлык иминлек теләргә тиешле. Шуның өчен мусулман шул, аның теленнән дә, кулыннан да башка беркемгә дә зыян күрмәгән кешеләр дип Пәйгәмбәребеә с.г.в. әйтте, Шул чагын да без Аллаһның бәндәләре, юктан да бар иткән, сөеп яраткан, һәм Аллаһның мәхәббәтенә, Аллаһның рәхмәтенә дә Инша аллаһ алардан булачакбыз Аллаһ Раббул Гыйззә насыйп әйләсә иде. Әл-Халик исеме Аллаһның сан буенча 731 була. “خ” хәрефе сан буенча 600, “ا” 1, “ل”30, “ق”100 бөтен санын карап чыгабыз да 731 була.. Бу исеме белән Аллаһны зикр итәсе килгән кеше Йә Халику, Йә Халику диеп зикр итергә тиешле. Яки Әл-Халику, Әл-Халику диеп зикер итергә тишле була. Моның искиткеч олы мәгънәләре дә бар бит әле галимнәр берәүнең доньядан никадәр мөшкеллек авырлыкларны, бәлә-хәсрәтләре булды исә шулардан котылырга теләде исә 5315 тапкыр шушы Аллаһның исемен зикр итеп Йә Халику Йә Аллаһ дип искә алып Аллаһка ялвара торган булса

Аллаһ Раббул Гыйззә ул мөшкиллегеннән бу бәндәне котылудан насыйп итәчәк ди. Бәндәләрнең балалары юк икән. Аллаһтан олы өмете бар икән ул кеше шушы исемнең аерым бер таблицасы бар, көмеш йөзеккә язып янында йөртә торган булса Аллаһ Раббул Гыйззә бу бәндәгә, бу гаиләгә изге бер баланы да насыйп итәчәк

дигән аят кәлимәсе да Көръән Кәримдә бар. Аллаһ Раббул Гыйззә яратканнарына, теләгәннәренә Үзе теләгәнчә ярата, чөнки Аллаһ Раббул Гыйззә булдыруы безнеке шикелле , тукта йорт салам дигән вакытында да раствaор кайда, ком кайдан алырмын, кайдан булыр дип чабып йөресе юк, Аллаһ Раббул Гыйззә Көръән Кәримдә Үзе әйтә

Әллә ул җир-күкләрне бар иткән Аллаһ Раббыгыз әдәм балаларының үзләре шикелле үк яңадан бар итергә көче, кодрәте җитсә дип уйлыйлармы

Әйе, Ул Аллаһ Раббың бар итүдән дә иң өстен дәрәҗәсендә белеп бар итүче, яратучы Ул Аллаһ

Аллаһ Раббың берәр нәрсәне бар итергә теләде исә. Аның Әмере белән теләгән чагында “Күн” диеп кенә әйтүе “Бул” Шул Сәгатендә була, шуның өчен дә галимнәр әйтә, Аллаһның булдыруы каф белән нун арасында, җир-күкләрнең булдыруы хакында да Көръән Кәрим дә дә күрә без, Тәүрәт, Забур, Инжилдә дә зикр ителгән бу көнендә җир-күкләр, аннары үсемлекләр, хайваннар фәләннәр дип әйтелгән булса ул яратылганның тәртибе, ләкин Аллаһ Раббул Гыйззә берәр нәрсәне яратам дигән чагында анарга материалы да, бер нәрсәсе дә кирәк түгел. Аллаһ Раббул Гыйззә кайчан теләде исә “бул” дигәне җитә

Аның кодрәт янендә, бөтен барлыкны, молкәте булган. Аллаһ Раббың бөтен кимчелекләрдән пак Ул

ышанмасагыз, бөтенегез Аның янына кайтарылачаксыз ди, аннан тикшерерсез доньяда ышанып бетмәгән булсагыз  кайда Ул дип Йәсиндә күрәбез. Пәйгәмбәребез с.г.в. янына бер Мәккә кәфере килә дөянең калак сөяген ботып килә

Йә Мухаммәд ди без үлгәннән соң да яңадан тереләбез дип әйтәсең син ди. Менә бу дөянең калак сөяге бар ди. Шуны тота да ул сынып китш. Шушы сөяк калакларыннан да яңадан дөя чыгамы ди.

Пәйгәмбәребез с.г.в. әйе ди. Ул дөяне дә калак сөягеннән яраткан сине дә утка кертә Ул ди. Сите дә утка кертәчәк шикләнә торган булсаң, шуның өчен доньяда ышанып бетмәдең исә

бөтенегез Аллаһ хозурына кайтарылачаксыз ди ,Аллаһ Раббул Гыйззә Әл-Халик Аллаһ Раббыгыз шушы кадәр ямле доньясын яратты, шушы доньясына Аллаһ Раббул Гыйззә безне бәндәсе иттереп яратканнарының кадерләрен белеп яшәүләребезгә Аллаһның мөхәббәте белән яратуларыбызны исебезгә төшереп изгелектә, хәер догада яшәп, кешеләргә таяныч та булырга Аллаһ Раббыбызның рәхмәтенә дә ирешергә язсын.

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә иярергә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә иярүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып кучүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәяду җомгаларны хөрмәтләп

Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җомга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

***13 –нче ВӘГАЗ***

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ*** **ӘЛ-БӘРИ** ***ДИГӘН ИСЕМЕ***

Бәндә арасында сер булган бер кем дә аны тикшерә алмаган бер кем дә төзәтә алмаган иман пакьлыгы белән Аллаһның үзенә тапшыра торган олы бер гыйбәдәт шуның өстенә ай буена үтәдек олы гыйбәдәт Аллаһ Раббул Гыйззә Коръән Кәримендә дә
Рамазан ае, бүтән айларның исемнәре бармы Корьән Кәримдә Аллаһ Раббул Гыйззә бу айны хөрмәтләп Коръән Кәримдә исемен дә атады Рамзан ае анда Коръән иңгән ай әдәм балаларына бүләк булып иңгән ай, Корьән Кәримнең иңдерелгән ае адәм балаларына ак-караны, хәләл-хәрәмне, туры юлдан йөрүне аңалатырлык аятләре белән тулган Коръәннең ае ул кем бу айда шәһид булса ураза тотсын, кем авыру булса , йә сәфәрдә булса башка көннәреннән тотып бирсен Аллаһ Раббыгыз сезгә җиңеллекне тели, Аллаһ авырлыкне сезгә теләми көннең саннарын тутыру өчен Аллаһ Раббыгызны хак юлгы күндергәненә, олылавыгыз өчен, шаятъки сез шөкерана кылырсыз дип Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә алай булган вакытта бу аебыз Коръән ае, нинди ай бу башкалардан аермасы нидә дигән вакытыбызда бу ай Коръән ае Коръән Кәримнең иңдерелә башлаган ае, дөнъя ахирәтебезгә шатлыкка сәбәп булган Аллаһның мөбә0рәк китабаның ае бу шуның өчен дә Пәйгәмбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)гә Җәбраил (г.с.) һәрбер Рамазанда килеп Коръән Кәримнең иңгәннәрен укыта торган булды дөнъядан китәсе елында Пәйгәмбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)гә Җәбраил (г.с.) Коръәнне ике кат укып чыкты шуның белән бу Аллаһның бүләге Коръән Кәрим безгә Кыямәт көненә кадәр олы бүләге булып калды бу айда сәу-сәламәт булган һәрбер кешегә үзен Аллаһның бәндәсе дип санаган кешегә ураза тоту тиешле булды Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә:
Ий иманлы бәндәләрем безнең иманыбызга карата Аллаһ Тәгалә мөрәҗәгать итә, сездән элек булган халыкларга фарыз ителгән шикелле сезгә дә ураза тоту фарыз ителде. Аллаһның кушканын үтәп, тыйганнарыннан тыелып гадәтләнерсез Аллаһ Раббул Гыйззә Рамзан аен тәҗрибә итеп иманнарыбызны куәтләндерер өчен бирелгән мүбәрәк ае. Пәйгәмбәребез (с.г.в.) Рамазан аеннан сак булыгыз ул Аллаһның мүбәрәк ае ди.рамазан шәрифкә әзерләнүдән шунсы да керә ниятләребезне дә яңартабыз йортларбызны да чистартабыз, пакълыйбыз ашамаган вакытта бик җыештырасы килмәс алдан ук җыештырып куясың бөтенесен дә тагын шунсы да бар Рәсүл Әкрам (с.г.в.) исерткеч эчүләр кебек кенә әйберләр түгел йортыңда шмшада, яки шиша төбендә булса да

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم:

Әл-Бәри дигән Аллаһның исеме, Әл-Бәри яки Йә Бәри дип әйтелә, яки Йә Бәриү дип әйтәбез. Бу Көрьән Кәримдә бары ике сүрәдә генә килгән, берсесе хәтта Бакара сүрәсендә бер аяттә ике тапкыр килә, икенче урыны Хашр сүрәсендә Бакара сүрәсендәге болай дип әйтелә.

Йә Хәбибем Мухаммәд Мустафа с.г.а. исеңә төшер Муса г.с. үз халкына әйткән иде йи каемем , йи халкым дөреслектә үз үзегезгә җәбер зөлем кылдыгыз, ул алтынна булган бозауны үзегезгә тәңре итеп тотып, юктан бар итүче Аллаһ Раббыгызны тәүбәләрегезне кылыгыз, нәфесләрегезне диеп тә әйтеп була, үзегезне үтерегез бу сезнең өчен юктан бар итүче Аллаһ хозуында хәерлерәк булыр, тәүбәләрегене кабул итүче иманлы бәндәләре мәрхәмә-шәфкатиясе.

Әле әйткән идегез дә Йә Муса без сиңа ышанабыз Аллаһ илчесе, hһпәйгәмбәр икәнлегенә Аллаһтан челтәсе, газабы тотты, сез күрә тордыгыз

Үлгчтән соң да сезне яңадан терелтеп, бәлки сез шөкрана кылырсыз

Аннан соң без аларны болытлар белән күләгәләдек аларгга күкләрдән ризыкларны, мән белән сәүәләрне, очкан кошлар да татлы күктән яуган мәнне дә индердек Аллаһ Раббыгыз, без ризык биргәннәрен иң хушыннан ашагыз, Безгә рәнҗү, безгә зөлем кылмадылар алар. Үз үзләренә зөлем кылдылар дип әйтә Аллаһ Раббул Гыйззә. Кем турында әйтә. Бәлки Исраил г.с. яхудләр хакында Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә Муса г.с. Аның әмере белән фараоннан Мисрдан аның рәнҗерүеннән аның газапларыннан коткарып чыгарганнан соң да Муса г.с. Аллаһның микатенә туры, Сина тавына Аллаһтан вәхине кабул итергә киткән чагында, кардәше Аәйгәмбәр г.с.не тыңламадылар алтыннан бозау ясап куеп шунарга гыйбәдәт кыла башладылар, бүтәннәрнеке бар ич, безнеке ник юк, күзебезгә күренми ди. Менә шушы чагында Муса г.с. халыкның зөлемлегенә аптырап торган вакытында юктан бар итүче Аллаһ Раббыгызга тәүбәләрегезне кылыгыз, үзегезне үтерегез дигән Аллаһның хөкемен сөләде хәтта тәфсирләрдә языла, тәүбә кылдык, булды үкендек дигзн генә сүз түгел. Аллаһ Раббул Гыйззә шул вакытында шартын кылган бер берегезне кырыгыз, ничек иттереп кырсын, үз атасын, баласына ничек иттереп коралын күтәрсен Аллаһ Раббыгызның әмере шул булды тәүбәгезнең чынлыгы шул булыр өчен Аллаһ Раббул Гыйззә Тәүбәгезне кабул итер өчен бер берегезне кыру кирәк Шул акытында кем кылыч, пычак, кем ни тотты өсләренә томан шикеллек болып төште, бер берсен күрми тәфсирдә кайберсендә 70000 кадәр кеше шушы вакытында кырдылар бер берсен шуннан соң гына Аллаһ Раббул Гыйззә тәүбәләрен кабул итте дип тә языла. Ә безнең Пәйгәмбәребез с.г.в.

**Үкенеч үзе дә тәүбә** диде, теге халыкларга Аллаһ Раббул Гыйззә ул вакытында күзләренә күренеп диңгезләр ярылып, шуннан котылып чыкканнарны да күреп торып та Аллаһка карышып яңадан да мәҗүселеккә ул алтыннан ясаган бозауларга табынуларга җиткәннән соң Аллаһ Раббул Гыйззә тәүбәнен шартларын хәттә үзлрен дә үтерүгә дә иттереп куйган иде, менә шушы аят кәлимәдә күрәбез Аллаһ Раббул Гыйззә бер аятнең эчендә ике тапкыр Бәриикум ул дип Аллаһ Раббул Гыйззә. Аллаһ Раббыбызның исеме зикр ителде. Хәшр сүрәсендә

Ул Аллаһ Раббыгыз Халик Ул, яратучы, Әл-Бәри юктан бар итүче, Әл-Мусавир бар иткән вакытында да, һәр кайсысына төсен китереп бирүче. Аныкыдыр бар күркәм исемнәр. Аллаһ Раббыгызга тәсбихләрегезне олылый җир күкиәгеләрнең бөтенесе

Көч-күәтендә, кодрәтендә өстен булган һәр өчен дә хикмәт иясе Ул ди Көрьән Кәримдә алай булган вакытта Аллаһ Раббыбызның Әл-Бәри дигән исемен өч тапкыр күрәбез ни бары, кай бер исемнәре бар иде Әл-Мутәкәббир шикеллек Көрьән Кәримдә нибары бер тапкыр гына әйтелгәне дә бар иде. Әл-Бәри дигән сүз

البارئ –فعله : بَرَأَ –يَبْرَءُ بَرْءٌ

Фыгылленнән алынган иде. بَرْء - масдары юктан бар итүче творить, создавать Юктан бар итүче خَلَقَ –يَخْلُقُ Яратучы дигән сүз , мәххәбәт белән бар итүче. Безнең телебездә генә бар ул, юктан бар итү, яратты дип әйтәбез يَبْرَءُ – بَرَأَтворить, создавать Булса ул вакытта быть не повинным, не причастным Бәррәәт кичәсе булды бит إنَّ الله البَرِئ Аллаһ Тәгалә пакдыр мөшрикләрнең үзләреннән дә, аларның кылган эшләреннән дә, кирәксез хәҗәте дә юк дигән сүзе يَبْرَئُ - بَرِئَ Булса, ул вакытында ауыуда котылу дигән мәгънәсендә, шушы фигылләрдә караган вакында Аллаһ Раббыбызның Әл-Бәри исеменең юктан бар итүче, юктан бар итүче дигән сүз анарга материалы, чертёж планы да кирәк түгел, хазер бәдрәфне дә беркем дә чертежсыз төзи алмый кәгазе, документы кирәк. Әл-Бәри дигән сүзе юктан бар итүче бер кемгә хәҗәте төшмәсә, Үзенең теләгәненчә бар итүче, кемнендер күрсәтүенә һәм ярдәменә мохтаҗлыгы юк булган зат, Аллаһ Раббыбызның бу исеме хәрефләренең саны 213 була “ ب” – 2, “ ا” – 1, “ ر” – 200, “ي” - 10 Шуның өчен бу исемгә зикр давам иткән кеше 213 тапкыр аны әйтүе тиешле, Китапларда әйтәләр, шушы исемне зикр итү бер кеше авыруларга төшкән вакытта бигрәк тә берәр төше сызласа, авыртса, шушы исем белән Аллаһка ялварып шафасын сорасын, бигрәк тә табиб булып эшләгән кешеләр Аллаһ Раббыбызның шушы Йә бәри дигән исемебелән давасын да бирсә, авыруны да карый торган булса, аның кулыннан анаң баргән даваларыннан иң тиз төзәлүчеләр булачак, әҗәленә тимәгән булса бу кеше авыруыннан котылачак дип тә әйтелгән, берәр кеше авырса, башы авыртса, шушы Әл – Бәри исемен көмешкә язып баш киемендә йөретергә киңәш ителгән. Бар әйтерне юктан бар итүче дигән сүз Әл-бәри. Бар бүтән исемнәре дә, Әл-Мугым, кайтарып бар итүче дә шунарга күрә дә берәү әсирлеккә төшкән зинданга төшкәнме, шуннан котылуны тели торган булса Аллаһ Раббысына ялварса 45360 тапкыр әйтсен дә Аллаһ Раббысыннан сорасын хич чиксез Аллаһ Раббы ул бәндәне зинданнан, әсирлектән коткарыр дип әйтелгән, күп дип әйтерсеү 45360 анда вакыт җитәрлек Аллаһ Сакласын котулуны теләгән кешегә уйлана торганы да, чөнки Пәйгәмбәребез с.г.в. әйтә бармагыгызга кергән шырыны да Аллаһтан икәнлеген белегез ди. Тикмәгә генә бер нәрсә дә булмы, бәлки уйланарга үткән гомергә күз салырга биргәндер Аллаһ Раббул Гыйззә иманлы кеше шушылай булырга тиеш. Ни өчен булды бу хәсрәт, ни өчен төште миңа бу кайгы, ни өчен абынып егылдым, башыма чүп төште, таш төште дип һәр вакытта уйланырга тиешле. Көфердә булса, йә мунафик булса, әдәм баласы Пәйгәмбәр с.г.в. әйтә ул кеше дөя шикелле ди нигә бәйләделәр, тошауладылар, җибәрделәр аңламыйда белми дә, нигә авырды, сыркаулады, нигә анда төрмәгә төште, нигә анда бу хәсрәт булды икәнлеген аңламыйда белми дә. Иманлы кеше үлчәсен иман үлчәсендә үлчәсе дә аңлысын, аңнады мсә Аллаһ Раббул Гыйззә бу бәндәгә атабыз Әдәм г.с. ничек иттереп җәннәттә иблисның тоткылары белән Аллаһның тыйган җимешеннән дә, авыз иткәннән соң да Аллаһ Раббул Гыйззә аның күңеленә тәүбә кылуларны салды шуның шикелле Аллаһтан өмет булган кеше Аллаһ Раббул Гыйззә кайгы-хәсрәтеннән дә коткаруны да насыйп итәчәк, ләкин Аллаһка ялварган вакытыбызда менә шушы да исеменнәнин урынынна төшкәннәреннән, ялваруларыннан Аллаһ Раббул Гыйззә рәхмәтенә, ризалыгына ирүшүләрне насыйп әйләсә иде.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреләргә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәламнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә ияруләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәяду җомгаларны хөрмәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем

Ерак, якынлардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм җомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җомга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

*14 –нче ВӘГАЗ*

**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ ЭЛ-МУСАВИР ДИГӘН ИСЕМЕ***

Әл-Мусавир дигән исем. Әл-Мусавир, Әл-Халик бар ди, аннан соң Әл-Бәри бар ди,әле Әл-Мусавир килә, Әл-Халик юктан бар итүче, яратучы дигән сүз иде, Әл-Бәри бер кемнән сорамыйча чертеж планнарын да сорамыйча үзе теләгәнчә бар итүче дигән сүз, менә аннан соң Аллаһ Раббул Гыйззәнең Әл-Мусавир исеме килә. Ул Көрьән Кәримдә ни бары бер тапкыр гына килгән, шушы кыяфәтендә Хашр сүрәсендә. Ул Аллаһ Раббыгыз яратучы да, юктан бар итүче дә, сүрәтләрен дә бирүче, аныкы дар бөтен исемнәр, җир-күктәгеләр бөтенсе Анарга тзсбих әйтә, Аны бөтен кимчелекләрдән пак итеп таный һә өчен дә хикмәт, гыйззәт иясе, хикмә иясе Ул дигән аят кәлимәдә, һәм шушында килгән вакытында да Аллаһның Әл-Халик Әл-Бәри дигән исеме белән янәшә килә яратучы да, бар итүче дә сүрзтлзүче дә, сүрәтләүсе дигән сүзнең мәгънәсен Әл-Мусавир дигән мәгънәсенә килсәк бу исем белән исмулфәгил белән килә торган булса, башка сърщлщрдщ Аллаё Раббыгыз Ул сезгә җир йөзендә карарланырлык кылды җир йөзеп тора күкләрдә кояш тирәсендә дә Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә җирне какшамаслык иттереп Ул сезгә яратучы Аллаһ Раббыгыз. Күкне дә сезгә бина иттереп куйды, сезне дә сүрәтләде, төс-кыяфәтләрегезне бирде. Ул төс-кыяфәтләрне дә күркәм кылды АРАБ. Иң хуш булган ризыклардан да Ул сезне ризыкландырды. Менә бу сезнең Раббыгыз Аллаһ. Аллаһ Раббыгыз галәмнәр тәрбиячесе, мүбәрәк булган бер заттыр Аллаһы Раббыгыз яшерен түгел җирдәге дә, күктәге дә булганын берсесе дә. Ул аналарыгызның карынында сезне теләгәненчә төсегезне, кыяфәтләрегезне бирә. Аннан башка тәңре юк гыйззәт-күәт, көч-кодрәт иясе, хыкмәт иясе ди, җир-күкләр яратучы турында артык тукталмасак та, ләкин шушы кадәр җир йөзендә Аллаһ Раббул Гыйззә аякларыбыз карарланырлык, оеш бер тактага гына басып кара, я мунчада йөреп кара, тотыпнып кайда башым бәрелер икән дип йөргән белән Аллаһ Раббул Гыйззә шушы җирйөзендә ничәшәр миллиард әдәм балары йөрерлек иттереп Аллаһ Раббул Гыйззә бу җирне яраткан, күкләрне бина иттереп яратты ди, түбә, йорт салган кеше дә белә, түбә нинди мөһим икәнне, түбәсе булмый торган булса әллә ни кадәр хуш яхшы иттреп ясалган йорт булсын, ләкин ул берничә ел шулай ачык булса, ул бина юкка, әрәмгә чыга торган була. Түбәсе булмаса, бер кемдә эчендәге оттелкасына тотынмый. Аллаһ Раббул Гыйззә шул кадәр җир йөзенең күген яраткан, күпме анда мериорит, нәрсәләр төшә торган булсын, шуларның бөтенесе көеп бетерлек итеп Аллаһ Раббул Гыйззә яраткан, шунарга билгене атмосфера иттереп билгеләгәндә Аллаһ Раббул Гыйззә әйтә, шулар гына зур,

чамасы зур, әдәм баласы акылына китерә алмаслык, бер сарайның, гаражның түбәсен генә булдырам дигән вакытта да Аллаһ Раббул Гыйззә бөтен җир йөзен шушылай иттреп катлап куйды шуның өстенә Аллаһ Раббул Гыйззә әйткән. Йөзләрегезне Аллаһ Раббул Гыйззә бар иттем ди, бер берегезгә охшамыйсыз, кайбер рәссәм шикелле иттереп чылт-кылт иттереп кенә куйган булса, әдәм баласының кыяфәтен юк алты миллиардка якын, һәр кайсысыныкы аерым могҗиза иттереп кенш Аллаһ Раббул Гыйззә игзәкләрнең бер төсле иттереп яратуы мөмкин, анысы да Үзенең кем икәнлеген искә төшерер өчен әдәм баласына караган вакытында сокланып каралык, кәҗәгә караганда да исең китә, сакалына, я коөрыгына, я карыйсың күпме сөт бирер диеп, күпме кошлар хайваннар бар бар иң ис китергеч иттереп әдәм баласы. Аллаһ Раббыгыз сезнең сүрәтләрегезне дә күркәм кылды ди иң күркәм иттреп кылды ди, чөнка әдәм баласы Аллаһ Раббул Гыйззә хайваннарга да шул кадәр, хәттә соңгы көндә галимнәр сөйлиләр, телевизордә да карыйсыз китарның бит койрыгы, ниләре бар, шуның шикеллек хайваннарда да Аллаһ Раббул Гыйззә үзенә билгеләп кйган, койрыгындагы рәсем бер берсенә охшамаган, сирәк-сирәк иттереп. Аллаһ Тәгалә могҗиза иттереп кенә бирә торган булса, бармактагы рәсем донья яратылганнан кадәр, азагына кадәр беркемнеке бер кемнекенә охшамый Аллаһ Раббул Гыйззә шушы кадәр иттереп яратучы, әле бу атнада гына сабый балалар килгәннәр иде дә, Аллаһка ышанасызмы соң, бөтенесе, мусулман балалары да, башкалары да ышанабыз дип өченче класс балалары шулай итеп китә, күрдегезме соң Аллаһны, күрмәдек, кайдан беләсез, төрле сүзләр әйтә, эти-бабай да әйтте, ишеттек тә, укыдык та дигәннәре, бер гөл бар иде, янымда күрәсез дә аны, гөлнең яфрагы да торган өстендә тагын бер ботак кыяфәте бар шул яфрак уртасында шуның уртасында яшел яфраклары, әйтерсең дә зәйтүн агачының бер ботагы шикелле бусысын кем рәсемләде соң дип дәштем, бөтен балалар Аллаһ дип әйтте, күзеңне ачсаң Аллаһның рәссәм икәнлеген Әл-Мусавир икәнлеген үзеңнең бармакларыңда, тырнагың да да, борыныңда, кашыңда, бөтен тирәңдә дә күреп тора торган булсаң өйләрнең генә тәрзәсе, түбәсе була икән, ишеге була икән диеп искитеп түгел, ансына да ис китүгә әдәм баласы газапланган, күпмедер тырышкан, ләкин Аллаһның булдыруы шунарга күрә дә Аллаһ Раббул Гыйззә нибары бер тапкыр Әл-Мусавир дип, яратучы да, бар итүче дә, бар иткән вакытында бөтенесенә дә төс-кыяфәтен дәбирүче Ул Аллаһ Раббул Гыйззә Үзе. Бөтен галәмнәрне тәрбия итүче Ул Аллаһ Раббыгыз мүдәрәк зат Ул, бу Раббыгыз хуҗагыз сезнең, бүтән хуҗа ала сине вакытлы эшкә йә бәрәңге төбен өяргә, йә чөгендерне алып бетерергә, эшләдең ул вакытта ашата, түли анрга, киләсең дә эш бетте, бар кит ди .Мондый хуҗа да бар бик шәп була торган булса да, олылайдың, картайдың менә сиңа трудовой книжкә, картайдың бар пенсия вакытың җитте, йөдә утыр, шундый хуҗа да бар, ләкин Аллаһ Раббул Гыйззә донья-ахирәтендә дә хуҗа Раб дигән сүзе гел тәрбияләүче, Аллаһның мусавиру анагызның карнында Аллаһ сезне ярата да, бетте түгел, 30-40 елга җиткәннәрендә дә, 50-60 җиткәннәрне дә атна саен, я көненә атлаган саен көзгеңә караган саен күреп торасың Аллаһ Тәгалә әле дә сине сүрәтли, кайчан гына чәчләр кара иде, хәзер агарып бетә язды, шоп-шома иде битләр, хәзер җыерчыклар чыкты, моннан да бөтән төшләрдә дә акланган, башкалары да чыгып тора Аллаһ Раббул Гыйззә шушыңың белән күрсәтеп тора бер минутка, секундка Аллаһ Тәгалә безне яратудан туктамый һәм ташламый, бу Аллаһның рәхмәте түгелме, Аллаһ Раббыбыз берәү генә, ата-анаң да бәпкә диеп куйса 40-50 гә җиткән вакытта йөрәгеңә сары май төшкән кебек балкып куйган шикелле була. Аллаһ Раббул Гыйззә бер секундка да Үзенең яратуын да, сөеүен дә әдәм баласыннан кәмими, шуның өчен дә Аллаһ Раббул Гыйззә хуҗагыз сезнең ди. ризыкларыннан иң хушларыннан сезгә ризыкланыны сезгә насыйп итте. Ул аерым мәсәлә, анарга тукталып тора торган чакта, шуннан да күренә, бәрәңге кабыгын әрчеп хайваннарга бирәбез, аннары сөт ичәбез, эчендәгесен үзебез

ашыйбыз Аллаһка җир-күкләрдә бер нисе яшерен түгел Ул сезнең анагызның карынын да да теләгәнчә ярата ди. Бүген үзенчә яратырга маташычулар да бар, пробиркаларда, я ДНКларны алып, баласы булмаса да, бар итргә маташып шушылай газапланучылар бар, күз алдына китерегез, әле үзенең ата-анасы булган баланы да каручы юк, бозау шикелле ясли детсадка куып. ә ул пробирка, ДНКларда яратылганнарны кем карар кемгә кирәк ул. Ишәк урынына эшләргә, конвеерларга куерга шунарга ярый торган була, бүтән бер нигә ярамый торган була, бүгенге көндә ятимнәр йортында йөзләгән балалар, шуларның 75% ата-аналары бар, я алкоголик беткән, я тулган бөтеннәй, әле ә вакыты-вакыты белән ишетеп күреп торабыз, мусорный яәикларда 2-3 айлык баларны туңган полителенга төргәннәр дә ташлаганнар, анаң турында ишеткән-күргәнегез юк иде мени, бүген менә пробиркалар белән Аллаһ белән узышып, Аллаһтан да өстен булырга, моны бер кемгә дә булырга алмады һәм булдыра да алмаячак, түгел мәңгелекне күпме генә запчастка гына ясыйбыз дигән булалар запчастка гына, кеше иттереп булмаса да бөерен-баурларынмы, ул запчастка калган гомер кемгә кирәк? Мәңгелекне доньяда кем яшәде ди барыбер бер көнне Аллаһның хәзурына кайтачак вакытыбыз җитә. Шуның өчен дә Аллаһ Раббыгызның Әл-Мусавиру исеме АРБ фигыле аның кыяфәтне бирү, сүрәтне бирүче дигән сүз мының саны 336. “мим”40, “сад”90, “уау”6, “ра” 200 җыенысы Аллаһка бу исем белән зикр итәсең килсә 336 тапкыр әйтергә тиешле була Йә Мусавиру диеп Аллаһның исемен, яки Әл-Мусавиру дип. Бу исемне зикр итү дә анарга давамчылык кылу мәгнәләреннән шуның белән дүшәмбе көнне берәү язып куя торган булса, баласы төшә торган хатынга эчертү файдалы, Аллаһ насып итсә баласы төшмәс булыр, Аллаһ Раббул Гыйззә доньяга китерер дип әйтелгән китапларда, әллә ни маташасы юк, шушы исемен яздың да, йә янында йөртә торган булса, икенче һәр бер эш иясе бигрәк тә бизнесменнар, хөнәр ияләре Аллаһның шушы исемен гел телләренә ала торган булсалар Аллаһ Раббул Гыйззә эшләрен уң итәр ди, чөнки эшне төс-кыяфәтенә китерүче Аллаһ Рабул Гыйззә. Аллаһ Раббыгызның ул исемен искә ала торган булса ярдәмгә Аллаһ Раббысына таянган шикелле була торган була. Бигрәк тә Көръән Кәримдә дә һәм мәгънәсе буенча да Халик, Бәри, Мусавир исемнәре якын булганга күрә буларның хасиятләре муштәрәк була бер берсенә якын була. Бер хатын-кызның баласы булмый торган булса, әйтелгән китапларда да җиде көн ураза тотып авыз ачкан кичендә шушы исемне 21 тапкыр суга өрсен дә эчсен Аллаһ насыйп итсә Аллаһның тәкдирендә була торган булса Аллаһ Раббул Гыйззә бу хатынга изге җәмәгат насыйп итер ди. Суга өрү дигәне кияүдә булу дигәне әлбәттә, суга гына өреп утырган дигән сүз түгел. Менә бу Аллаһ Раббыгызның күркәм исемнәрененең ни кадәр мәгънәләре бар. Һәр көнендә, минутында, секундында тәэссире дә бар икәнен күрәбез.

Аллаһ Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә һәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаһ Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!

**ГОМҮМ РУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ УЗӘК ДИНИЯ НАЗАРАТЫННАН ӘҺЛЕ ИСЛАМ ҖӘМӘГӘТЕНӘ “ҖӨМГА БӘЙРӘМЕ” МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ БАШ МӨФТИ, ШӘЙХЕЛЬ – ИСЛАМ ТӘЛГӘТ ХӘЗРӘТ ТАҖЕДДИННЫҢ ҖӨМГА ВӘГАЗ ҖЫЕНТЫКЛАРЫ ТӘКДИМ ИТЕЛӘ!**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**

**Бөтен барлыкны** юктан бар итеп һәр кайсысына тәкдирендә билгеләүче, Ул язмышны да күркәм итүче Аллаһ Раббыгызга һәмдә сәнә һәр мактау олуглауларыбыз булса иде.
**Бөтен гәләмнәрне** юктан бар итеп, бу доньясында бәндәсе иттереп яратучы Аллаһы Раббыгызга һәм дә сәнәләребез булсын.
**Дөнья – ахирәт** бәхетебәз өчен тырышучы хак илчесе, сөйгән бәндәсе, Пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мустафа с.г.в-гә хәер дога сәламнәребез, өммәтем дигән күңелләребездән туктаусыз салават – шәрифләребез дә булса иде .
**Аллаһның берлегенә,** Пәйгәмбәребезнең хаклыгына иман китереп, җан малларын кызганмыйча, иман ислам-нурын бөтен галәмнәргә ирештерер өчен тырышкан әһле-бәйте һәм сахәбәи икрамнарга шулай ук кыямәт көненә кадәр аларга бөтен изгелектә ияреpгә омтылган бәндәләргә дә бездән хәер дога сәләмнәребез булса иде.
**Аллаһтан башка мәгъбуд биль Хак юк**, ялгыз Үзе генә икәнлеккә, тиндәше юкка гуаһлыкны бирәм. Җөмләбезгә иманнарыбызны хәерле изге гәмәлләр белән нурландырып яшәүләрне Аллаһы Раббул Гыйззә насып әйләсен.
**Мөхәммәд с.г.в.Аллаһның** чын бәндәсе Хак илчесе, сөйгән бәндәсе икәнлеккә гуаһлыкны бирәм, җөмләбезгә өммәте булып яшәүләребезне, Росуль Әкрам с.г.в.-ның сөннәте сәниясенә ияpүләребезне Аллаһ Раббым дөньядан иманлы бәндәләр булып, өммәте булып күчүләребезне һәм мәһшәр мәйданында да өммәте булып, кубарылып Аллаһның рәхмәтенә Һәбибе Мөхәммәд с.г.в. шәфәгәтенә ирешүләрне Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.
**Телләребезгә ансат булган**, Аллаһның үлчәүендә олы булган бу мүбәрәк сүзләрне бергәләшеп иман кәлимәләрен яңадан кабатлыйк, күңелләребездә нык калсын, белмәгәнләргә Инша-Аллаһ өйрәнү булыр, белгәннәргә кабатлау-иманнарны яңартыу булыр, һәм ахыр сүзләребез дөньядан үткән чагыбызда да бу шәһәдәт кәлимәләре булса иде.

**اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمدا عبده و رسوله**Ерак, якынлардан сәяду җомгаларны хөрмәтләп Аллаһның изге йорты мәчеттә газиз кардәшләрем

Ерак, якыннардан Иман өндәвен кабул итеп, Сәйдүль - әйәм жомга көне бәйрәме шатлыгын җөмлә мөэмин кардәшләрем илә уртаклашыйм, бергәләшеп җомга фарзын үтик һәм рәхмәт, ризалыкка ирешик дигән Аллаһы Раббыма буйсыну һәм зикердә, кыйблага юнәлгәннәрнең сафында тезелүдә күңел карары табыйм дип, иң гүзәл, нурлы йорт-мәсҗидләрдә җыелышкан мөхтәрәм, газиз кардәшләрем!

Үзәк диния назарате һәм аңа баглы мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне – бөтен әһле Ислам кардәшләребезне, **Җөмга бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәм һәм дә бу сәгадәтле мөнәсәбәт илә самими сәләм һәм иң изге теләкләремне юллап калам!

السلام عليكم و رحمة الله و بركاته

Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт, бәрәкәтләре, һәр ике дөнья сәләме барчабызга булып, бу кадерле йортына килүләребезне мөбәрәк һәм дәвамлы кылса иде.

***15 –нче ВӘГАЗ***
**Әсмаул-Хуснә (Исми Әгзәм)**

## ***АЛЛАҺНЫҢ ЭЛ-ГАФФӘР ДИГӘН ИСЕМЕ***

Әл-Гафар исеменә килеп җиткән идек. Үткәнебездә Әл-Халик, Әл-Бәри, Әл-Мусавир булды, буларның сүз ияләре дә бер берсенә якын икәнлекләре турында да ишеткән идек. Көръән Кәримдә Әл-Гаффар берничә сүрәләрдә килә Аллаһның бу исеме, Таха, Саф, Зәмәр, Гафир һәм Нух сүрәләрендә килә, ләкин Нух сүрәсендә кигән вакытта һәм Сафада да бар “Әл” юк, Гаффарун, Гаффаран дип тә килә. Аллаһка сыйфат иттереп Гаффар дигән исүзе Аллаһ Раббыбызның исеме авыз ачкан вакытыбызда да АРАБ дип Аллаһка ярварабыз, безне ярлыкасын дию Әй бик тә гонаһларны кичерүче, бу сүрәләрдә килгән мәгънәләрне бер аз карыйк. Аллаһ Раббыбызның Гаффар сыйфатын мәгънәсен аңлар өчен таха сүрәсендә 82 аятендә Дөреслектә Мин бик тә ярлыкаучы, кем тәүбә кылса, иман китерсә изгелеген эшләсә аннан соң хак юлга, хидәяткә күнелсә ди. Мин кичерермен дигән Аллаһ Раббыгызның сүзе кем тәүбә кылса иман китерсә, изгелекләрен кылса, аннан соң хидәят юлына китсә бер генә тәүбә кылды да бетте түгел, ышанам дип кенә, аннан соң да хидәят юлыннан, Саф сүрәсендә. Әйт Йә хәбибем Мухаммәд Мустафа с.г.в. Дөреслектә Мин кисәтүче Аллаһдыр, Пәйгәмбәребезгә әйтергә куша Мин сезне кисәтүче генә, исегезгә салучы гына Аллаһтан башка тәңге барыбер юк. Ул бер генә теләгәнен әгәр дә Аллаһка карышты исә кәхәрләп-кәхәрләп тә аны туктатучы кәхәрләп бетерәчәк әгәр дә карышты исәкирелеге белән әдәм баласы күкләренң дә, җирләрнең дә хуҗасы Ул күкләрдә дә, җирләрдә дә Аның хөкеме генә үтә. Күктә дә Ул хуҗа, җирдә дә Ул хуҗа, ә космоста кем дип уйлый торган булсагыз. Җр-күкләренң арасында да Ул хуҗа ди. Аннан башка хөкеме юк Ул Гәзиз, Ул Гаффар, көч-куәтендә, кодрәтендә өстен булган, ярлыкауы да өстен булган Аллаһ Раббыгыз. Әйт Йә Хәбибем с.г.в. бу олы хәбәр, сез Анардан да йөз чирәсез дип әйт ди әдәм балаларына, аңлашыламы бу, җир-күкләрнең хуҗасы Аллаһ, аның арсында да хуҗа Аллаһ, Аннан башка тәнре юк, гонаһ кылып кайда барасыз сездән өстен Ул, тәүбә кылыуызызда да моһтаҗлыгы юк, шундый зат була торып та Ул Гаффар Ул, Үзенең мәхлүкләренә, яраткан бәндәләренә мәрхәмәт-шәфкатле, гонаһ кылган саен гафу итәм дип торган зат Ул. Әйт шуны Хәбибем Мухәммд Мустафа с.г.в. Зөмәр сүрәсендә Аллаһ Ул бар итте күкләрне һәм җирне халык белән бар итте. Көнен төнгә чорный, чорнап куйган шикелле иттереп, көн бетәр вакытында ялганып китә торган була, кырт итеп кисми АРАБ шул көннең, төннең галәмәтләреннән булган кояшын да, аен да Аллаһ Раббыгыз сезгә буйсындырды ди, сезнең кирәгегезгә, яктылыгын биреп тора, үләне дә үсеп чыга, үлән

үсеп чыкмас бәрәңгедән күрәсез подвалда нинди булганын, ап0пак иттереп үсеп чыккан, үзең кояшы күрмәсәң ни була? аллаһ Раббул Гыйззә күәтен дә илттереп бирерлек, аен да, нурын да , йолдызларын да тәмен дә бирерлек иттереп Аллаһ Раббул Гыйззә яраткан. Һәр кайсысы орбитасында билгеләнгән вакытына кадәр, әҗәленә кадәр йөри. Шуларның бөтенсенә хөкемен куючы Аллаһ Раббул Гыйззә Ул Гаффар исеме янында, алдында Гәзиз килә, Гәзиз дигән сүзнең мәгънәсен онытмадыгызмы, кадерле генә дигән сүз түгел, бер кемгә хәҗәте төшми. Шундый кеше гәзиз була ала. Сәлпенәеп төшкән булса, бәлки сәлам бирерләр иде артыннан төкереп тә калырлар, йә тибеп тә куярларю Аллаһ Раббул Гыйззә Гәзиз дигән сүзе гыйззәтле, кадерле генә дигән сүз түгел һәр нигә көче-күәте җитүче шулай була торып Әл-Гаффар ярлыкаучы, бик ярлыкаучы  гафу итүче генә түгел бу, Әл-Гаффар дигән сүзнең мәгънәсенә киләбез Аллаһ Раббул Гыйззә монысын дә әйергә куша. Әй каемем Миңа ни бу булды соң, Мин сезне котлуга чакырам, сез мине утка чакырасыз аллаһ Раббыгызның Пәйгәмбәре с.г.в. сөйләгәнне Аллаһ Раббул Гыйззә исенә төшерә Аллаһ Раббыма кәфер булырга өндисез, Анарга булмаган ширккә өндисез, мин сезне кадерле булган, гыйззәтле булган, гонаһларны ярлыкаучы Аллаһ Раббыма өндим. Анарга чакырам. Тагын да Аллаһ Раббул Гыйззә Нух г.с.нең монда да күрәбез, Әл-Гаффар белән Гәзиз икесе янәшә килде Нухг.с. бар иде, олы пәйгәмбәрләрдән, хәттә Нух г.с.не җир йөзендә икенче Әдәм дип тә йөртәләр, аныд заманында бөтен дөньяны су басты да кешелек дөньсы бетте, батты, исән калганнары Нух г.с. белән булганнары аннан соң җирдәге кеше халыклары үрчи башлады Карагыз Нух г.с.не Йи Раббым Аллаһ мин халкымны көнк-төне чакырдым Аллаһ юлына ышаныгз дип.  Минем өндәүм, минем чакырыуым аларга качудан башка бер ни бирмәде, качтылар гына, мин килегез дигән саен колакларына бармакларын тыктылар, киемнәрен өсләренә каплпдалар да, кирекләрен. Гонаһларын давам итеп анда да борын чиеп, без ким дип йөрделәр. Ишетәсезме мыны Аллаһның пәйгәмбәре үзенең халкы турында шулай иттереп сөйли, шәхидме бу, болай иттереп Аллаһның Пәйгәмбәре үз халкы хакында сөйләгәннән соң алар ничек исән калсын, ничек иттереп аларга Аллаһның газабы төшмәсен. Пәйгәмбәребез с.г.в. җан биргән вакытында да. Өммәтемне сакла йә Раббым, өммәтемне ярлыкагыл диеп Пәйгәмбәребез с.г.в. өчәр тапкыр, җан биргән чагында да, баласы-җәмәгате түгел, өммәте турында кайгырып Рәсүл акрам с.г.в. әйтте. Нух г.с. дә шәфкатсез идемени, мәрхәмәтсез идемени, күргәннәрен шул кадәр күргән, тугызйөз ничә ел яшәгәннән соң, күпмеләрен күргәннән соң, шушыларын сөләде үзенең халкына гуаһ булды. Йә Раббым, аннан соң мин халкымны ачыктан иттереп чакырдым. Ачыктан да алрга хәбәр иттем, яшереп тә сөйләдем Һәм әйттем аларга Аллаһ Раббыгыздан гонаһларыгызның ярлыкаун сорагыз, дөреслектә Раббыгыз Аллаһ бик тә кичетүче Ул дидем бөтен хатыкның азгынлыкка төшкәнен күргәннән соң, иманлы булганнарына әзерләнегез аллаһ Раббыгыз кушуы белән менә бу кәмә булды, кимчелек гонаһ хаталарыгызга ярлыкау сорагыз дип аларга сөйләде. Гәҗәп менә шушында аллаһ Раббыгызның Әл-Гаффәр сыйфаты һәм безнең әдәм балалрының истикфар кылыубыз, тәүбә кылыубыз, гонаһларның гафу ителеүен Аллаһтан сораыбыз, Аллаһның кәхәреннән, ачыуынан котулуга олы сәбәпләрнең берсе, әгәр әдәм балалары истикфар кылмаса, дөнья ике көн дә тормас иде, ул вакытында атабыә Әдәм г.с. дә җәннәттәге булган хәлләрдән соң да иң беренче Хава анабыз белән истикфары булды, шуның өчен кыямәт көнкнә кадәр, менә шушылай истикфар кылып, тәүбә бәрәкәтендә тормыш давам итә. Әл-Гаффар дигән Аллаһның исеме аның фигыле гафу итү , ярлыкау, тагын бер мәгънәсе бар каплау, өртү Әл-Гаффар дигән Аллаһның исеме бик тә каптучы, нәрсәне каплый? Әдәм баласынң гонаһын гафу итү генә түгел, булмаган шикелле иттереп бетереп куя Аллаһ Раббул Гыйззә, бөтеннәй юк итә, үл гына түгел, Аллаһ Раббул Гыйззә ярлыкаса, Аллаһ Тәгалә кмчерә торган булса, күпме кылган гонаһларың

бар, шуларны бетереп, каплап, юк шикелле, булмаган иттереп бетерә, шуның урынына кылган изгелекләр язылa, кәффәрәт була. Дип Үзеннән сорарга да өйрәтте. Йә Раббыбыз Аллаh безне ярлыка, кичер бу гына җитә безгә, гафу итсә дә җитә, аллаh Раббул Гыйззә тагын юлын өйрәтә,безнек кимчелек, хата-гонаhларны кәффәрәт кылсаң иде, изгелек иттереп яздырсаң иде, булмый да былай дөньяда, менә нииндидер җинәятләр эшләде, суд булып утырды, амнистияга эләкте, чыкты китте, сөенәме? Җир күге белән сөенә, чыкты котылда, туганнары сөенә, ата-аналары, гаиләләре. Юк тагын аның урынына судка барып мин күпме утырдым, шуны трудодень иттереп язсагыз иде дип, шундый рәвеш бирсәгез иде төрмәдә утырганым өчен дип барса буламы. Аллаh Раббул Гыйззә шундый кылган гонаhларын гафу итү генә түгел, изгелек иттереп язылганын да, ким дигәндә ун өлеш язылa бит. Ни өчен бу, кайдан килгән бу. Аллаhның Гаффар сыйфатыннан. Аллаhның мәрхәмәт-шәфкатләреннән hәм менә шушысында бер нәрсәне оныттык бит. Аллаh Раббул Гыйззә шул кәффәрәт дәрәҗәсенә дә җиткерә, кылган гонаhларны онытмасаң, изгелегеңне онытт, булды бетте ул, фәрештәләр язды бетте, бергә ун иттерепме, бергә җидейөз иттерепме, бергә миллион иттерепме язылды бетте, ләкин синң гонаhыңны онытма, шунардан тәүбәңне кыл, шуннан аллаhтан ярлыкауны сора Аллаh Раббул Гыйззә синең гонаhыңны онытканны белә. Аның хуҗа икәнлекне онытмаганыңны күрә.Һәм аллаh Раббул Гыйззә шул бәрәкәтендә hәр бер гонаhларыңны ярлыуау гына түгел, Гаффар дигәнне каплап бетерә, бөтеннәй юк итә, аның урынына менә бир кәгаздә язган кара бар икән әз генә замазать итеп куйдың икән күренә барыбер, яхшысы аны бөтеннәй ак иттреп кенә куясың да өстенә тагын язып куясың, беленми торган була, шулай иттереп Аллаh Раббул Гыйззә ул гонаhларны бетереп, аның урынына изгелеген дә яза торган була, менә шул аллаh Раббыгызның Әл-Гаффа сыйфаты, Әл-Гаффарның санын 1281. Йә Гаффару диеп бу зикерне әйтергә була. “гайн”100, “фә”80, “әлиф”1, “ра” 200, шуларның җыелмасы 1281 була, китапларда язылуына караган вакытта берәү Аллаh Раббыгызның шушы Йә Гаффар дип исемен зикр итә торган булса бу бәндәнең гомер буена туры юлдан йөрүгә сәбәп була, чөнки өстенә гонаh язылмый дәфтәренә ул вакытта, иманында дөресләрдән, сүзләрендә дә дөресләрдән була, ул гына түгел, күпме фитнә, күпме тавышлар дөньяда була торган булса әдәм балалары, дошманнар арасында күренмәс булыр. Шушы исеменең зикренә данлыкны берәү үти торган булса, нинди генә мөшкиллекләрдән Аллаh Раббул Гыйззә арынуны насыйп итәчәк, икенчесе берәү Аллаhның Әл-Гаффар исеменең зикр итүен давам итә торган булса, гонаhларның ярлыкауына, күңеленә Аллаhның рәхмәте урнашуына да сәбәп булыр, шушындый ***уефкы*** бар, таблица саннары язылулары белән шуны берәү кургашына язып Рамазан аемы, башка айларның иң соңгы төнне хиҗри айларының соңгы төнендә язып, язганнан соң да 1321 тапкыр укый торган булса Аллаhның ярдәме белән, явызлыкларның дошманнарның бөтен зөлеменнән имин булыр Аллаhның рәхмәте белән дип әйтелгән

Аллаh Раббуль Гыйззә авыруыбызга хәер итүче, саташканнарыбызга тауфик-истикамәтләр, илебезгә hәм бөтен галәмгә тынычлык насыйп әйләсә иде, тынычлык-иминлек өчен тырышыучыларга Аллаh Раббуль Гыйззә хәерле эшләрендә хәер кылсын.Әмин!